# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2020 3(27)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ХӘМИДОВА Ч.И.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ


*Сабитова И.И., Муктат Ф.И.* Халык авыз иҗаты әсәрләрендә соматизмнар *(Добруҗа татарлары әкиятләре мисалында)* . . . . 7

*Сәгъдиева Ф.К., Абдуллина Ч.З.* Татар телендә лексик лакуналар . . 15

*Гатауллин Р.Р.* Көньяк Урал һәм Урал арты төбәгенең төрки-татар ойконимиясен өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . 19

*Хөсәинова А.Я.* Иркутск өлкәсе татар күчмә сөйләшләре үзенчәлекләре һәм аларны төркемләү мәсьәләсе . . . . . . . . . . 25


## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


*Төхфәтова Г.Ф.* Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре: басылу тарихы һәм тәрҗемә тәҗрибәләре . . . . . . . . . . . . . . 32

*Нәбиуллина Э.Р.* Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясендә көнкүреш детальләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39

*Яруллина Йылдырым Р.Ә.* Төрек прозасында милли идеал буларак татар кызлары *(Халидә Әдип Адывар романнары үрнәгендә)* . . . . 46

*Ганиева А.Ф.* Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» роман-трилогиясендә «шәхес һәм җәмгыять» мәсьәләсе . . . . . . 55

*Чугунов А.С.* Ш. Идиатуллинның «Брежнев шәһәре» романында милли мәсьәләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62


## ФАТЫЙХ КӘРИМИГӘ – 150


*Закирҗанов Ә.М.* Фатыйх Кәрими әсәрләрендә мәгърифәтчелек эстетикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

*Гатин Ә.А.* Татар дөньясына Европадан бер караш: Арминий Вамбери һәм Фатыйх Кәрими . . . . . . . . . . . . . . 74


## МӘҖИТ ГАФУРИГА – 140


*Абдуллина Д.М.* Мәҗит Гафури иҗатының идея-тематик үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80


## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ


*Мортазина Л.Р.* Булат Салиев – үзбәк тарихын язган татар галиме . 90

*Зиннәтуллина А.Ә.* Дин һәм дәүләт эшлеклесе Мансур әл-Борындыкый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96


## ХАЛЫК ИҖАТЫ


*Сафиуллина Р.Ф.* Габделҗаббар Кандалыйның «Рисаләил-иршад» поэмасында фольклор һәм суфичылык шигърияте традицияләре . . 101


## МИЛЛИ МӘГАРИФ


*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Татар телен укытуның яңача куелышында М.Х. Корбангалиевнең эшчәнлеге (1917–1941 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

*Зарипов Ф.Ш., Вәлиев И.И.* Лингвистик төрлелек шартларында математик белем бирү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

## СӘНГАТЬ

*Донина Л.Н.* Һәрвакыт сафта *(В.А. Попов иҗаты турында)* . . . . 128
*Борһанова А.Ф.* Нырты челтәр бәйләү традицияләрен яңадан торгызу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
*Горюнова Н.М.* «Татарстанның нефть төбәге пейзажы» сериясеннән. Талантлы осталарның өч буыны . . . . . . . . . . . 144

## ЭПИГРАФИКА

*Усманов В.М.* Көньяк Урал ташъязмалары: Оренбург өлкәсе Мостафа авылындагы эпиграфик һәйкәлләр . . . . . . . . . . . . 150

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Шәйхелова С.Ф., Фахруллина Г.Ф., Нигъмәтҗанова Л.Р., Фахруллин Р.Ф.* Карамай таркатучы *Alcanivorax borkumensis* бактерияләре һәм *Turbatrix aceti* суалчаннарының «хуҗа – микрофлора» системасындагы мөнәсәбәтләре . . . . . . . 158

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Мостафа Чокай углы.* «Милли юл» . . . . . . . . . . . . . . . . 164

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Галимҗанова Э.М.* «Миргазиз Укмасый. Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» (төзүче З. Рәмиев) китабына бәяләмә . . . . . . . . . 168

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Салихова А.Р.* Газиз Әлмөхәммәдов һәм аның милли музыка сәнгатен үстерүдәге роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
*Рәмиев З.З.* Күренекле әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче *(Хәсән Хәйринең тууына 110 ел)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Сабитова И.И., Муктат Ф.И.* Соматизмы в произведениях народного творчества *(на примере сказок добруджанских татар)* . . 7
*Сагдеева Ф.К., Абдуллина Ч.З.* Лексические лакуны в татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Гатауллин Р.Р.* Вопросы изучения тюрко-татарской ойконимии Южного Урала и Зауралья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Хусаинова А.Я.* Особенности татарских переселенческих говоров Иркутской области и проблема их классификации . . . . . . . . . . 25

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Тухватова Г.Ф.* Стихотворение Габдуллы Тукая «Родной язык»: история публикаций и опыт переводов . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
*Набиуллина Э.Р.* Детали повседневного быта в рассказе «Сөннәтче бабай» Г. Исхаки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
*Яруллина Йылдырым Р.А.* Образы татарских девушек как национальный идеал в турецкой прозе *(на примере романов Халиды Адип Адывар)* . . . . . . . . . . . . 46
*Ганиева А.Ф.* Освещение проблемы личности и общества романе-трилогии Ф. Садриева «Счастье несчастных» . . . . . . . . . 55
*Чугунов А.С.* Проблема национальной идентичности в романе Ш. Идиатуллина «Город Брежнев» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

## ФАТИХУ КАРИМИ – 150

*Закирзянов А.М.* Вопросы просветительства в произведениях Фатиха Карими . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
*Гатин Ә.А.* Татарский мир глазами европейца: Арминий Вамбери и Фатих Карими . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

## МАДЖИТУ ГАФУРИ – 140

*Абдуллина Д.М.* Идейно-тематические особенности произведений Маджита Гафури . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Муртазина Л.Р.* Вклад Булата Салиева в развитие науки и просвещения Узбекистана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
*Зиннатуллина А.А.* Религиозный и государственный деятель Мансур аль-Бурундуки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Сафиуллина Р.Ф.* Фольклорные и суфийские поэтические традиции в поэме «Рисаляи-ль-иршад» Габдельджаббара Кандалыя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Деятельность М.Х. Курбангалиева в области разработки новых методик преподавания татарского языка (1917–1941 гг.) . . . . . . . . . . 108
*Зарипов Ф.Ш., Валеев И.И.* Преподавание математики в условиях языкового многообразия . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

## ИСКУССТВО

*Донина Л.Н.* У времени в строю *(о творчестве В.А. Попова)* . . . 128
*Бурганова А.Ф.* Возрождение традиций ныртинского кружевоплетения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
*Горюнова Н.М.* Из серии «Пейзаж нефтяного региона Татарстана». Три поколения талантливых мастеров . . . . . . . 144

## ЭПИГРАФИКА

*Усманов В.М.* Эпиграфические памятники села Мустафино Оренбургской области . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

## ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ

*Шайхулова С.Ф., Фахруллина Г.Ф., Нигаматзянова Л.Р., Фахруллин Р.Ф.* Бактерии *Alcanivorax borkumensis* и нематоды *Turbatrix aceti* в модельной системе взаимоотношений «хозяин – микрофлора» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Мустафа Чокайоглы.* «Милли юл» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галимзянова Э.М.* Рецензия на книгу «Миргазиз Укмаси. Сочинения, статьи, воспоминания» (составитель З. Рамеев) . . . . 168

## ПЕРСОНАЛИИ

*Салихова А.Р.* Газиз Альмухамедов и его роль в развитии национального музыкального искусства . . . . . . . . . . . . . . . . 170
*Рамеев З.З.* Видный литературовед и критик *(110 лет со дня рождения Хасана Хайри)* . . . . . . . . . . . . 175

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145’373

***И.И. Сабитова,***
***Ф.И. Муктат***

# ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ СОМАТИЗМНАР
## (Добруҗа татарлары әкиятләре мисалында)

В статье анализируются соматические термины, которые являются древнейшим слоем основного лексического фонда татарского языка. Анализ корпуса текстов масалов (сказок) татар Добруджа Румынии показывает консервативность и устойчивость названий частей тела. Выявленные соматизмы имеют параллели в современном татарском литературном языке, что позволяет судить о заимствовании, взаимовлиянии и взаимопроникновении контактирующих языков.

**Ключевые слова**: народное творчество, сказки, татарский язык, крымско-татарский язык, лексика, соматизм, этимология, диалект, говор.

The article deals with somatic terms, which are the oldest layer of the main vocabulary of the Tatar language. The analysis of the texts of masals (fairy tales) of the Dobruja Tatars (Romania) shows the conservatism and stability of the names of body parts. The revealed somatisms have parallels in the modern Tatar literary language, which makes it possible to talk about the borrowing, mutual influence and interpenetration of contacting languages.

**Keywords**: folk art, fairy tales, Tatar language, Crimean Tatar language, vocabulary, somatism, etymology, dialect, sub-dialect.

Халык авыз иҗатының иң бай һәм борынгы жанрларының берсе булып әкиятләр санала. Билгеле булганча, әкият – могҗизалы һәм маҗаралы вакыйгаларга, шулай ук көнкүрешкә бәйләнешле хәлләргә корылган фантастик әсәр, реаль һәм фантастик алымнар белән сурәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша халыкның үткән тормышын, киләчәккә хыял-омтылышларын чагылдыра торган фольклор әсәре.

Халык әкиятләре лексикасы төрле пландагы сүзләргә бай. Барлык фольклор жанрларындагы кебек, аларда да семантик үзгәрешләргә дучар булган, пассив катламга күчкән, хәзерге татар телендә инде кулланылмый торган лексик берәмлекләр, искергән сүзләр (архаизмнар) саклана. Шуңа да әкият текстлары төрле лексик катламнарны өйрәнүдә әһәмиятле чыганак булып тора.

Әкиятләрдә соматизмнарның күп кулланылуы табигый: кешене, хайваннарны сурәтләгәндә төп вазифаны соматик лексика үти, вакыйгаларны тасвирлаганда да халык тән әгъзалары атамаларын куллана. Мисалга «Каракош» әкиятеннән өзек китерәбез: *Бара-бара карт килеп чыга сахрага. Ашарына бетә моның. Барырлык рәте калмый. Шул вакыт кесәсендәге өч бөртек чәч исенә төшеп, берсен алып җилгә очыра. Җилгә очыргач, моның алдында иксез-чиксез күп*

*ризык барлыкка килә* [Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр, 1994, б. 122].

Соматизмнар татар теленең төп лексик фондына керә һәм иң борынгы катламны тәшкил итә. Алар борынгы язма истәлекләрдә чагылыш тапкан. Телдә кулланышта йөргән әлеге сүзләрнең күбесен башка төрки телләрдә генә түгел, монгол, тунгус-маньчжур, фин-угор телләрендә дә очратырга мөмкин. Соматик лексика күләмле булуы белән дә аерылып тора. Татар теленең аңлатмалы һәм диалектологик сүзлекләренә теркәлгән күпсанлы атамалар шул турыда сөйли. «Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «кеше» тематик төркеменә караган лексика» хезмәтендә соматизмнарның 178 сүзьясалыш оясы күрсәтелә. Аларга 3325 лексик берәмлек тупланган [Сабитова, 2015]. Әгъза атамалары консерватив һәм аеруча тотрыклы булсалар да, кайберләре төрле дәрәҗәдәге фонетик һәм мәгънә үзгәрешләре кичергән. Алар кулланылыш ягыннан да аерылып торалар. Күпчелек атамалар сүзлекләргә бернинди стилистик тамгасыз кертелгән һәм гомумәдәби нейтраль лексикага карый. Бер төркем соматизмнар халык сөйләм телендә генә йөри. Кулланылыштан төшеп калып, бөтенләй югалып барганнары бар.

Соматик лексика – теләсә кайсы тел системасында универсаль лексик төркемнәрнең берсе һәм ул чагыштырма-тарихи, структур-чагыштырма һәм лингвокультурологик аспектларда тикшеренүләрнең иң актуаль объекты булып тора. Татар тел белемендә әгъза атамаларының этимологиясе өйрәнелә [Әхмәтьянов, 2015; Габдрахманова, 1994, б. 61–67], сүзьясалыш потенциалы [Галимова, ... 2019, б. 162–165; Рамазанова, 2016; Сабитова, 2014, б. 1147–1150; 2017, б. 137–138], сөйләмдә башка сүзләр белән ярашу үзенчәлекләре ачыклана [Федотова, 2013, б. 195–197], сүзлекләрдә теркәлү тарихы [Юсупова, 2012, б. 124–137] һәм синонимик берәмлекләр [Сабитова, 2019, б. 14–18] һ.б. карала. Д. Рамазанова «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» дигән хезмәтендә татар теле диалектларында таралган кешенең рухи халәтен, холкын белдерә торган сүзләр белән бергә соматизмнарны да, башка телләр белән чагыштырып, синхроник һәм диахроник аспектларда тикшерә [Рамазанова, 2013].

Алда билгеләп үткәнебезчә, әгъза атамалары борынгы катламны тәшкил итә. Шуңа күрә дә соматик терминологияне төрки һәм башка телләр белән чагыштырма планда өйрәнү хәзерге татар тел белеменең мөһим бурычларыннан берсе булып кала. Атамаларның аерым регионнарда яшәүче татарларның авыз иҗатында кулланылыш үзенчәлекләрен, семантик үзгәрешләрне, шулай ук сүзьясалыш процессында катнашуын чагыштырып өйрәнү дә әһәмиятле мәсьәләләрдән санала. Чөнки аерым текстларның лексик корпусларын тикшерү, билгеле бер чорда телнең гомуми торышы турында гына түгел, ә лексикасы формалашудагы төп тенденцияләр, үзара аралашкан телләрнең бер берсеннән сүзләр алуы, телләрнең үзара йогынтысы турында да фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Бу мәкаләбездә Румыния татарлары әкиятләрендәге соматизмнарны хәзерге татар әдәби телендәге тән әгъзаларын атаган сүзләр белән чагыштырып, янәшәлекләр, ягъни параллельләр табу максатын куйдык. Румыния татарлары – Румыниянең рәсми танылган милли азчылык халыкларының берсе. Алар, нигездә, Добруҗа өлкәсендә һәм Констанса (Күстәнҗә) шәһәрендә яши. Румын татарларының күбесе – чыгышлары ягыннан, XVIII гасырда Россия империясе басып алган Кырым ярымутравыннан һәм Төньяк Урта диңгез буеннан күчеп килгән Кырым татарлары. Ул чорда алар татар теленең Казан (урта) диалектына якын булган кыпчак диалектында сөйләшә. Шуңа күрә Добруҗада җыелган әкиятләр җыентыгындагы соматизмнарны хәзерге татар әдәби телендәге параллельләре белән чагыштырып тикшерү татар теле лексик составының формалашу һәм үзгәрү процессын ачык күрергә мөмкинлек бирә.

Фәнни тикшеренү өчен соматик берәмлекләр 1991 елда Бухарестта басылып чыккан «Ayuw kulak batır: Dobruca Tatar Masalları» ‘Аюколак батыр: Добруҗа татарлары әкиятләре’ исемле җыентыгыннан тупланды [Ayuw kulak batır: ..., 1991]. Җыентыкта тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләр бирелгән. Барлыгы 49 әкият. Алар Румыниянең Добруҗа өлкәсендә танылган кырымтатар галимнәре доктор Недрет Мәхмүт һәм доктор, профессор Әнвәр Мәхмүт тарафыннан җыелган һәм басмага әзерләнгән. Кырым татарларында әкият төшенчәсе «масал» сүзе белән йөртелә. Бу сүз бүгенге көндә шулай ук азәрбайҗан һәм урум телләрендә кулланыла.

Әкиятләрнең лексикасын чагыштырма планда өйрәнү нәтиҗәсендә түбәндәге соматизмнарда тулы тәңгәллек булуы ачыкланды: *awız* ‘авыз’, *arka* ‘арка’, *ayak* ‘аяк’, *köz* ‘күз’, *tĭl* ‘тел’, *baş* ‘баш’, *tĭş* ‘теш’, *tĭrsek* ‘терсәк’, *tamak* ‘тамак’, *yanak* ‘яңак’, *karın* ‘карын’, *kaş* ‘каш’, *kökrek* ‘күкрәк’, *kabırga* ‘кабырга’, *mıyık* ‘мыек’, *sakal* ‘сакал’, *tĭz* ‘тез’, *ten* ‘тән’, *öt* ‘үт’, *şĭş* ‘шеш’, *ĭrĭn* ‘эрен’, *kan* ‘кан’, *yaş* ‘яшь’.

Кайбер атамаларның дериватлары да очрады: *awĭzlĭk* ‘авызлык’, *arkadaş* ‘аркадаш’ (иптәш, дус), *közleü* ‘күзләү’ (җентекләп карау, күзәтү), *közleü* ‘күзләү (төзәү)’, *tĭllĭ* ‘телле’, *tĭlsĭz* ‘телсез’, *şĭşü* ‘шешү’, *ĭrĭnleü* ‘эренләү’, *tĭzgĭnlĭ* ‘тезгенле’.

«Кеше башының алгы өлеше; бит» мәгънәсендә җыентыкка тупланган әкиятләрдә *bet* (бит), *yüz* ‘йөз’, *şıra*у ‘чырай’ сүзләре кулланылган. Әлеге лексик берәмлекләр татар теленең барлык норматив сүзлекләрендә теркәлгән һәм хәзерге чорда нейтраль, актив кулланыштагы сүзләр булып санала.

Фонетик вариантлар түбәндәге очракларда күзәтелә: *kulak* ‘колак’, *kol* ‘кул’, *koltık* ‘култык’, *kursaк* ‘корсак’, *tobık* ‘тубык’, *can baş* ‘янбаш’, *yürek* /*cürek* ‘йөрәк’, *morın* / *murın* / *burın* ‘борын’, *eñse* ‘иңсә’, *parmak* ‘бармак’, *et* ‘ит’, *şaş* ‘чәч’, *mañkay* / *mañnay* ‘маңгай’, *bel* ‘бил’, *bogaz* ‘бугаз’, *terĭ* ‘тире’, *kemĭk* ‘кимек’, *meñ* ‘миң’, *ĭş* ‘эч’, *sĭlekiy* ‘селәгәй’ һәм *moyn* ‘муен’.

«Dünya Güzelĭ» (Дөнья Гүзәле) әкиятендә *kekel* ‘кәкәл’ сүзе очрый [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 144]. Аны бер үк вакытта этнографизм һәм диалектизм дип санарга мөмкин. Бу сүз татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлегендә теркәлмәгән. Ә 2017 елда басылып чыккан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең III томында *какул* соматизмы «кайбер (төрки, монгол, тунгус, кытай һ.б.ш.) халыкларда ир-егетнең баш түбәсендә китәрелмичә калдырылган бер тотам чәче» мәгънәсендә урын алган [Татар теленең аңлатмалы ..., III т., 2017, б. 65]. *Кәкел* атамасының дүрт мәгънәсе китерелгән: 1) Ир-егетләрнең яшьтән үк баш түбәсендә кырылмыйча калдырыла торган чәч тотамы; какул; 2) Атның маңгай чәче; 3) Кошларда: бүрек; 4) Баш киеменә, ат дирбиясенә беркетелә торган чук [Татар теленең аңлатмалы ..., III т., 2017, б. 201]. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә *җакул* ‘атның маңгаена төшкән ялы’, *какул* ‘бүрек – кошларда’, ‘чук’, *күгел* ‘атның маңгай чәче’ сүзләрен табып була [Татар теленең зур ..., 2009, б. 268, 283, 381]. Диалектолог Д. Рамазанова *кикел* терминының *кекел, кекил, кәкел, кокил, когул* фонетик вариантларының нугай, казакъ, кыргыз, каракалпак һәм үзбәк телләрендә бүгенге көнгә кадәр сакланганлыгын яза [Рамазанова, 2013, б. 26]. Р. Әхмәтьянов та атаманың татар диалектларында, башка төрки телләрдә, Евразиядә күп телләрдә очраганын әйтә һәм аның фарсы теленнән таралган дип исәпләнүен билгеләп үтә. Этимолог фикеренчә, *хохол* сүзе дә шуннан килеп чыккан. Галим *какул* сүзенең асылында «ир кешенең яшьтән үк баш түбәсендә киселмичә-кырылмыйча калдырыла торган толымчык» мәгънәсе ята дип саный [Әхмәтьянов, 2015, б. 348].

«Cantemir Batır» (Җантимер батыр) һәм «Ongan kart» (Уңган карт) әкиятләрендә *el* ‘әл’ соматизмы табыла [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 199]. Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *әл* вокабуласы *иск.* (искергән сүз) тамгасы белән теркәлгән һәм аның борынгы төрки сүз икәне күрсәтелгән [Әхмәтьянов, 2015, б. 130]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә әлеге сүз *бор.* – (борынгы сүз) тамгасы белән кертелгән [Татар теленең аңлатмалы ..., I т., 2015, б. 329]. Алдагы елларда нәшер ителгән аңлатмалы сүзлекләрдә *әл* вокабуласы бөтенләй бирелмәгән.

Соматизм борынгы татар язма әдәбияты әсәрләре теленә хас. Мисал өчен XVIII гасыр ахырында билгесез автор тарафыннан язылган «Мансур Хәллаҗ кыйссасы»ннан өзек китерәбез: *Диде Мансур: «Уш Хакка сондым әлем, Иллә белең кем – бәңа юктыр үлем!»* [Татар әдәбияты тарихы..., 2014, б. 100]. Күренекле шагыйребез Г. Тукай шигъриятендә дә *әл* сүзен очратырга мөмкин: *Әл-аяк баглы, мөхаль кортылкаем, мәсхүреңем; Та әбәд дәрдең илә әүвараем, әүвараем.* [Тукай, 2011, б. 82]. Д. Рамазанова *әл* атамасының татар теленең урта диалектында *иләсә* ‘биятәй’ сүзе составында сакланып калуын әйтә [Рамазанова, 2013, б. 107].

Шунысы әһәмиятле: *el* ‘әл’ соматизмы җыентыкка тупланган әкиятләрнең икесендә генә күзәтелә, калган очракларда *kol* ‘кул’ атамасы кулланылган. Безнеңчә, бу Д. Рамазанованың Көнчыгыш әдәбияты-

на хас традицион *әл* сүзенең кулланыштан төшә барып, *кул* сүзенең активлашып, телдә ныклап урнашуы турындагы фикерен тагын бер кат раслый [Рамазанова, 2013, б. 107].

«Ayuw kulak batır» (Аюколак батыр) әкиятендә очраган *kükĭs* ‘күкес’ лексемасы татар әдәби телендә «күкрәк, торс, гәүдә» мәгънәсенә туры килә [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 73]. Аны шулай ук «Мешек алып» дастанында да табарга мөмкин [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 31]. Атама себер диалектларында очрый: *күкес* ‘күкрәк читлеге’, *күкеш* ‘мактанчык, борын күтәрүчән’ [Татар теленең зур ..., 2009, б. 348]. Бу сүзгә төрки параллельләр «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге»ндә, «Төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы»нда, «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә китерелә [Севортян, 1980, б. 55; Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 272; Әхмәтьянов, 2015, б. 488]. Галимнәр фикеренчә, соматик терминның беренчел мәгънәсе булып «гәүдәнең өске өлеше буларак күкрәк / арка» санала. Атама * *kōke-* ‘имәргә’ фигыленнән ясалган булырга мөмкин дип фаразлана [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 272–273].

«Üş tılsım» (Өч тылсым) һәм «Tapkır bala» (Тапкыр бала) әкиятләрендә мәгъәсе белән татар телендәге *тын, сулыш* сүзләренә туры килгән *solık* ‘сулык’, *tınış* ‘тыныш’ соматизмнары очрый [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 63]. *Тыныш* атамасы «Татарча-русча сүзлек»кә сирәк кулланыла торган сүз буларак теркәлгән [Татарско-русский словарь ..., т. 2, 2007, б. 458]. Татар теленең хвалын һәм әстерхан сөйләшләрендә – *тыныш*, касыйм сөйләшендә *тыныч* сүзләре «тын» мәгънәсендә кулланыла [Татар теленең зур ..., 2009, б. 672].

«Zöre» (Зөһрә) әкиятендә «йодрык» мәгънәсенә ия *cumırdık* (жумырдык) сүзе бар [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 101]. Атама кайбер фонетик аерымлыклар белән төрки телләрдә киң таралган [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 272; Әхмәтьянов, 2015, б. 321]. Р. Әхмәтьянов элеге соматизмны борынгы төрки *jumduruq* сүзе белән бәйли һәм *jum-* ‘йому’ фигыленнән ясалган дип саный [Әхмәтьянов, 2015, б. 321]. Галимнәр шулай ук *-m-* һәм *-d-* параллель формалар күзәтелгән телләрдә **jumur* ‘йомры’ нигезе белән контаминация булганлыгын әйтәләр [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 253]. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»нә дә *-м-* формалы *йомрыкъ* ‘йодрык’ сүзе теркәлгән [Татар теленең зур ..., 2009, б. 252].

Добруҗа татар әкиятләрендә «тән, гәүдә» мәгънәсендәге *vücüd* ‘вөҗүд’ сүзе дә кулланыла. Гарәп теленнән алынма атама элеге мәгънәдә «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге»нә *иск.* (искергән сүз), «Татарча-русча сүзлек»кә *кит.* (китап теле) тамгасы белән теркәлгән [Татар теленең мәктәпләр өчен ..., 2013, б. 78; Татарско-русский словарь ... Т. 1, 2007, б. 292].

Кайбер әкиятләрдә «күкрәк, корсак, гәүдәнең алгы өлеше» мәгънәсендә *bawır* ‘бавыр’ соматизмы очрый [Ayuw kulak batır: ...,

1991, б. 25, 42, 113, 140]. Татар фольклор текстларында да *бавыр* сүзе шундый ук семантикага ия. Мисалга түбәндәге мәкальләрне китерергә мөмкин: *Елан бавыры белән ил гизәр, койрыгы белән кое казыр; Баланы бавырга кысып күтәрәләр (үстерәләр)* [Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр, 1987, б. 158, 395].

Хәзерге вакытта татар теле сүзлекләрендә сүзнең бу мәгънәсе *иск*. (искергән сүз) тамгасы белән теркәлгән [Севортян, 1980, б. 181].

Әкиятләрдә «кендек» мәгънәсендәге *göbeg* (гөбәг) [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 17] соматизмын да күрергә мөмкин. «Татарча-русча сүзлек»тә атаманың «сап» семантикасы күрсәтелгән [Татарско-русский словарь ..., т. 2, 2007, б. 664.]. Р. Әхмәтьянов сүзне *иск*. тамгасы белән «кендек» мәгънәсендә терки. Галим *Аккүбәк* исеменең дә ак күбәкле «ак кендекле» дип сыйфатлануын әйтә [Әхмәтьянов, 2015, б. 85]. Сүз, нигездә, угыз телләрендә таралса да, баба төрки нигездән ясалган дип санала [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 280].

«Кул аркасының кире ягы; уч» мәгънәсендә «Sokır padişa» (Сукыр падиша) әкиятендә кулланылган *awış* (авыш) [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 43] сүзе, безнеңчә, **адуи-t/č* сүзе белән бәйле. Атама күп кенә телләрдә күзәтелә. Татар телендә – *уч.* Гагауз, азәрбайҗан, караим, тува, якут, башкорт, татар һәм кайбер башка телләрдә соматизм «уч» мәгънәсенә ия [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 252].

«Cantemir batır» (Җантимер батыр) әкиятендә «җилкә» мәгънәсендә кулланылган *omız* (омыз) [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 25, 26] атамасы да хәзерге татар телендә күзәтелми. Әмма кайбер телләрдә «җилкә», «арканың өске өлеше», «атның күрәк асты», «җиң төбе», «кайма, әдеп» мәгънәләрендәге лексик параллельләр табыла [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 240]. Галимнәр бу сүзне угыз-чуваш архаизмы дип табалар һәм төрки телләрдә **omuz* нигезеннән ясалган сүзләрне күрсәтәләр. Татар телендә: *umyldyryk* ‘нагрудник лошади’ [Сравнительно-историческая грамматика ..., 2001, б. 240–241].

«Ayuw kulak batır» (Аю колак батыр) әкиятендә *panca* (панҗа) сүзе бар. Ул аю тырнагын белдерә [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 68]. «Ay man Küneş» (Ай белән Кояш) әкиятендә *tırnak* ‘тырнак’ сүзе кулланыла [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 216]. Шул рәвешле, Добруҗа татарлары әкиятләрендә *панҗа – тырнак* синонимиясе күзәтелә. *Панҗа* атамасы – татар теленә ят сүз. *Kalaw* (калав) ‘урт’ [Ayuw kulak batır: ..., 1991, б. 164.] сүзенә дә татар телендә янәшәлекләр табылмады.

Шулай итеп, Добруҗа татарлары әкиятләрендә очрый торган тән әгъзаларын белдергән күпчелек исемнәрнең хәзерге татар әдәби телендә параллельләре бар. Фонетик вариантлар да байтак табылды. Кайберләре искергән, аерым диалектларда гына кулланыла яки бары тик фольклор текстларында гына очрый. Берничә сүзнең генә татар телендә янәшәлекләре булмавы ачыкланды. Бу исә кеше әгъзаларын атый торган лексиканың һәм мәгънә, һәм фонетик төзелеше ягыннан гаять тотрыклылыгын һәм бик борынгылыгын күрсәтә.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 1 т. (А–Л). Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. 543 б.

*Габдрахманова Л.Г.* Борынгы төрки соматизмнарның татар телендә саклануы // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Выпуск 2. Казань, Изд-во ИЯЛИ АН РТ, 1994. С. 61–67.

*Галимова О.Н., Сабитова И.И.* Отсоматические инсектонимы в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2019. № 5. С. 162–165.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан, 2013. 364 б.

*Рамазанова Д.Б.* Татар тарихи лексикологиясенә материаллар. Казан: Школа, 2016. 412 б.

*Сабитова И.И.* Татар телендә соматизмнардан ясалган микротопонимнар: уртак төрки катлам // Türk Dünyasında Sosyal ve Ekonomik İşbirliği. Kongre bildirileri. 2 Cild. İstanbul: Türk Dünyası Araştırmalar Vakfı: 2014. S. 1147–1150.

*Сабитова И.И.* Словообразовательный словарь татарского языка: лексика тематической группы «Человек». Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2015. 160 с.

*Сабитова И.И.* Фитонимы с сомокомпонентами в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2017. № 2 (68); в 2-х ч. Ч. 1. С. 137–138.

*Сабитова И.И.* Соматические синонимы в фольклорных текстах татарского языка (на примере дастанов) // Фәнни Татарстан, 2019. № 2. Б. 14–18.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на буквы «В», «Г» и «Д» / ред. Н.З. Гаджиева. М.: Наука, 1980. 395 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М.: Наука, 2001. 822 с.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 2 т. XV–XVIII гасырлар / [фәнни мөх. Х.Й. Миңнегулов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 471 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. Т. 1 (А–Л). Казань: Магариф, 2007. 726 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. Т. 2 (М–Я). Казань: Магариф, 2007. 728 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казан: ТӘһСИ, 2017. 744 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз. Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 415 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 383 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 591 б.

*Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. 1 т. : шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 415 б.

*Федотова Л.Н.* Осочетаемости соматизмов в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и пратики. Тамбов: Грамота, 2013. № 5. Ч. 2. С. 195–197.

*Юсупова А.Ш.* Тематическая группа «Части человеческого тела» и её отражение в двуязычных словарях татарского языка XIX века // Слово в пространстве языка // Материалы II международной заочной научно-практической конференции. Ульяновск, 2012. С. 124–137.

Ayuw kulak batır: Dobruca Tatar Masalları. Bucureşti Krition kitap üyi, 1991. 251 b.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 1. A–D. Köstence, 2011. 550 b.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 2. E–O. Köstence, 2011. 567 b.

Dobruca kırımtatar ağzı sözlüğü. T. 3. Ö–Z. Köstence, 2011. 565 b.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Муктат Флёра Исламетдин кызы,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 62 нче урта гомуми белем мәктәбе туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы*

УДК 81.27

***Ф.К. Сәгъдиева,***
***Ч.З. Абдуллина***

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЛЕКСИК ЛАКУНАЛАР

В статье при изучении вопросов лакунарности за основу берутся теоретические положения, изложенные в работах Л.К. Байрамовой. При анализе фактического материала описаны особенности внутриязыковых лакун татарского языка.

**Ключевые слова:** лакуна, лакунарная единица, внутриязыковая лакуна, лакуны татарского языка.

In the article, when studying questions of lacunarity, the theoretical provisions set out in the works of L.K. Bayramova are taken as a basis. The analysis of the actual material describes the features of intra-linguistic lacunae of the Tatar language.

**Key words:** lacuna, lacunar unit, intra-language lacuna, lacunae of the Tatar language.

Телнең, мәдәниятнең һәм телгә ия шәхеснең үзара бәйләнештә булуы нәтиҗәсендә килеп туган мәсьәләләрне өйрәнү – тел гыйлеменең әһәмиятле бер бурычы. Бу мәсьәлә яңа булмаса да, соңгы вакытта аңа әһәмият бирелүе бәхәссез. Тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнеше заман таләбенә туры килә торган гыйльми югарылыктан торып өйрәнелгәндә генә тиешле нәтиҗәләргә ирешү мөмкин. Дөнья күләмендә мәдәниятләрнең үзара йогынтысы, шул җирлектә телләрнең бер-берсенә йогынтысын өйрәнү, хәтта тугандаш булмаган телләрне дә чагыштырып өйрәнү, хәзерге тел гыйлемендә үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Телнең үз эчендәге һәм телара лакунарлык мәсьәләсен өйрәнгәндә дә без әлеге мәсьәләләр белән очрашабыз.

Лингвистика фәненә *лакуна* төшенчәсен Ю.С. Степанов кертә. Ул аны «бушлыклар», «телнең мәгънәләр картасындагы ак таплар» (белые пятна на семантической карте языка), дип атый [Степанов, 1965, с. 120]. Әлеге сүз француз теленнән алынган һәм термин буларак бушлык мәгънәсен белдерә.

Лакуналар мәсьәләсе билгеле бер дәрәҗәдә татар телендә дә өйрәнелгән. Бу уңайдан Л.К. Бәйрәмова, З.З. Гатиятуллина, Г.З. Садыйкова һ. б. галимнәрнең хезмәтләрен атарга мөмкин. Аларда күбесенчә телара лакунарлык мәсьәләләре яктыртыла. Лакуналарның табигате бик катлаулы. Алар телнең төрле тармагында күзәтелергә мөмкин. Ике яки берничә тел мисалында караганда, лакунарлык һәм эквивалентсыз лексика дигән төшенчәләрнең үзара бәйләнеше турында төрле фикерләр яшәп килә. Әйтик, тел белгече Л.К. Бәйрәмова лакунар берәмлек дигән термин кертергә тәкъдим итә. Аның фикеренчә, *лакунар берәмлек* һәм *лакуна* төшенчәләрен аерып карарга кирәк. Шундый очракта гына лакунар берәмлек һәм эквивалентсыз

берәмлек дигән төшенчәләр бер-берсе белән абсолют синонимнар булмый. Әлеге уңайдан ул болай дип яза: «Лакунарная единица является принадлежностью одного языка (условно языка *А),* а лакуна – принадлежностью другого языка (условно языка *Б).* Лакунарность – категория, составляющими которой являются 1) лакунарные единицы языка *(А)* и 2) лакуны (языка *Б)* – нулевые корреляты лакунарных единиц. Единица языка *А* может быть лакунарной, коррелируя с лакуной в языке *Б* и в то же время иметь в этом языке эквивалент» [Байрамова, 2004, с. 43].

Телдәге лакунарлык мәсьәләсенә тукталганда, иң элек, аның нинди материал яссылыгында каралачагын алдан ук билгеләп кую тиеш, дип искәртә Л.К. Бәйрәмова [Байрамова, 2011, с. 22]. Бу очракта ул бер тел эчендәге яки берничә телдәге, ягъни телара лакуналарны өйрәнүне аерып күрсәтүне таләп итүе белән бик тә хаклы. Әгәр әлеге шарт үтәлмәсә, ахырда ясалачак нәтиҗәләр дә дөреслеккә туры килмәячәк.

Без бу хезмәттә татар теленең үз эчендәге лексик лакуналарга киңрәк тукталырбыз.

Һәр телнең бай лексик составы булуга карамастан, шулай ук анда күпсанлы бушлыклар – лексик лакуналар барлыгы ачыкланган. Әлеге күренеш татар теле өчен дә хас. Телдә һәр сүзнең лексик мәгънәсе бар, сөйләүченең аңында ул теге яки бу фикри образ (концепт) хәлендә гәүдәләнеш таба һәм яши. Тик аерым очракларда фикри образ бар, әмма аны белдерә торган сүз юк. Бу очракта әлеге күренеш, предмет, хисне һ. б. белдерү өчен тасвирлама сүзләр кулланыла. Татар теленә хас булган шундый мисалларны карап китик: гашыйк түгел кешене белдерүче сүзләрнең булмавын без *гашыйк* сүзе аша аңлыйбыз. Кем яки нәрсәгә дә булса мәхәббәте уянган, яратучы кешене *гашыйк* сүзе белән атыйбыз. Мәсәлән: *Ул күрше кызына гашыйк. Ул сәнгатькә гашыйк. Сеңлем чәчәкләргә гашыйк.* Аңлашылсын өчен мисалларны янәшә куеп карыйк: *Ул күрше кызына гашыйк түгел (аңа карата мәхәббәт хисе юк) // ул күрше кызына битараф (барлыгын да, юклыгын да тоймый), кызыксынмый (игътибар бирми, аның турында белешергә теләге юк), исе китми (булса бар, булмаса – юк).* Шулай ук татар теленең лексик-фразеологик системасында *«дөресен сөйләүче кеше»* концепты белдерелмәгән, әмма *ялган сөйләүче кеше – ялганчы* бар.

Безнең фикеребезчә, әлеге лакуналарны кешенең психологик халәте аша аңлатып була. Гашыйклык халәте ул кешенең үзе өчен дә, янәшәсендәгеләргә дә ачык күренә торган вакытлы, әмма аерым игътибар уятырлык хис, мизгел. Гашыйклык халәте – вакытлы. Ул яратуга әверелә яки сүнә. Шул сәбәпле әлеге халәтне белдерә торган сүз бар. Ә калган күпчелек *ярата, хөрмәт итә, дус күрә, якын итә*, әмма бу инде гашыйклык түгел, гадәти халәт. Күпчелек өчен хас булган гадәти күренешне аерып күрсәтү телдә аерым ихтыяҗ тудырмаган, күрәсең. Нәтиҗәдә гашыйк түгеллек халәтен аңлатучы аерым сүз дә юк.

Дөресен сөйләү һәркем өчен тиеш, аны аерып атау таләп ителми, ә менә ялганчы аерып күрсәтелергә тиешле, ул күпчелектән аерылган зат. Шуның өчен аны атый торган аерым сүз дә бар. Бу, билгеле, бер караш кына. Әмма мисаллар шактый күп. Алар әлеге юнәлештә психолингвистик эзләнүләр алып барырга мөмкин икәнлеген күрсәтә.

Лакунарлыкның бер төрен омонимнар – язылышлары һәм әйтелешләре бердәй, мәгънәләре башка булган сүзләр билгели. Мәсәлән, *ай* (күк җисеме) һәм *ай* (вакыт берәмлеге), *яр* (елга яры), *яр* (сөйгән яр) һәм *яр* (фигыль: утын яр). Омонимнар да телнең эчке лакунарлыгы белән бәйле. Кеше бер телдә генә аралаша икән, лакунарлыкның бу төре бөтенләй сизелми, чөнки аралашу процессында сүзнең нинди мәгънәдә кулланылуы контексттан яхшы аңлашыла.

Телнең үз эчендә, гадәттә, халык тормышында кулланылышта булган әйберләрне, күренеш, гамәлне белдерүче лексика эчендә лакуналар чагыштырмача азрак. Бу татар теле өчен дә шулай. Әмма монда да мисаллар юк түгел. Мәсәлән, *кар базы өсте* – бу, гадәттә, бакчаның күләгә өлешенә җәй көне ризык саклау өчен кар тутырып калдырыла торган баз өстенә ясалган корылма. Ул аерым нәрсәләр саклау өчен дә файдаланылган. Әмма телдә аерым исем алмаган, тасвирлама характердагы сүзтезмә белән белдерелеп, лакуна тәшкил итә.

Шулай ук аерым хайваннарның баласын белдерү өчен төгәл атама бар, ә кайберләре өчен юк. Мәсәлән, *Атныкы – колын, сыерныкы – бозау, сарыкныкы – бәрән (бәти),* ә *дуңгызныкы, песинеке* – юк. Алар *дуңгыз баласы, песи баласы* рәвешендәге тасвирлама сүзтезмәләр белән белдерелә.

Билгеле булганча, һәрбер халык чынбарлык турында үзенчә фикер йөртә, һәр халыкның үз менталь кыйммәтләре бар, милли традицияләр, милли яшәү рәвеше, милли мәдәният, милли тел халыкның үзенә генә хас дөнья сурәтен тудыра. Телдә бу исә, иң элек, аның лексикасында һәм фразеологиясендә чагылыш таба.

Телдәге реаль предметны, күренешне яки эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзнең юклыгы – абсолют лакуна. Бертеллелек очрагында алар сизелми. Әгәр дә ниндидер концепт телдә белдерелмәгән һәм лакуна буларак кабул ителми икән, димәк аралашу барышында ул катлаулылык тудырмый.

Аерым очракларда телдәге лакуналар алынма сүзләр белән тулылана. Алынма сүзләр, гадәттә, яшәешкә килеп кергән яңа әйберләр, күренешләр тудырган бушлыкларны тутыра. Телнең эчке кануннарына буйсынып яңа берәмлекләр ясауда катнаша. Мәсәлән, *глобаль*, *компьютер* сүзләре татар теле кушымчаларын үзенә ала: *глобальләшү*, *компьютерлашу*. Урынлы булган, чынлап та бушлыкны каплый алган алынмалар телдә тиз арада үзләштерелә, телгә кереп китү белән, фразеологик берәмлекләр ясауда катнашырга да мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге *уҗым бозавы* дигән фразеологизм шундыйлардан. Бу фразеологизмның *уҗым* компоненты рус теленнән алынган һәм татар теле нигезендә фразеологизм ясалган. Телнең үз эчендәге

лакуналарны тикшерү, безгә алынма сүзләргә тиешле игътибар бирү кирәклеген күрсәтә. Алынмаларның телне үстерүгә яки, киресенчә, аңа тискәре йогынты ясауларын ачыкларга ярдәм итә.

Шулай итеп, лакунар берәмлекләр телнең милли үзенчәлеген билгели. Карап киткән мисаллар телнең лексик-фразеологик системасында лакунар берәмлекнең ничек барлыкка килүен билгеле бер дәрәҗәдә ачып бирәләр. Әмма телдәге лакунарлык бу очраклар белән генә чикләнми. Киләчәктә бу өлкәдәге эзләнүләр дәвам итәр, телдәге лакунарлыкның үзенчәлекләре дә тирәнтен ачыкланыр.

**Әдәбият**

*Байрамова Л.К.* Введение в контрастивную лингвистику. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. 116 с.

*Байрамова Л. К.* Лингвистические и лакунарные единицы и лакуны // Вестник Челябинского государственного унивеситета. Челябинск: Изд-во Челябинский государственный университет, 2011. № 25 (240). Филология. Искусствоведение. Вып. 58. С. 22–27.

*Степанов С.Ю.* Французская стилистика. М.: Высшая школа, 1965. 365 с.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Абдуллина Чулпан Зөфәр кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге II курс аспиранты*

УДК 81′373

***Р.Р. Гатауллин***

# КӨНЬЯК УРАЛ ҺӘМ УРАЛ АРТЫ ТӨБӘГЕНЕҢ ТӨРКИ-ТАТАР ОЙКОНИМИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

Статья посвящена вопросам изучения тюрко-татарской топонимии Южного Урала и Зауралья, на территории которых наряду с другими народами издавна проживали татары. Основное внимание было уделено исследованию лексико-семантических особенностей ойконимов, а именно компонентов, из которых состоят топонимы. Вычленение и анализ топооснов помогает определить главный мотив номинации, происхождение названия, что в свою очередь способствует выяснению связи топонимов с природными особенностями, историческими событиями, миграцией народов, их языками, мировоззрением, а также способствует установлению причин появления и распространения определенных наименований или их компонентов.

**Ключевые слова:** тюрко-татарская топонимия, ойконимия, апеллятивы, онимы, топонимы, ойконимы, гидронимы, оронимы, антропонимы, этнонимы, фитонимы, зоонимы.

The article is devoted to the study of the Turkic-Tatar toponymy of the Southern Urals and Trans-Urals, on the territory of which Tatars have long lived along with other peoples. The main attention was paid to the study of the lexical and semantic features of oikonyms, namely the components that make up the toponyms. The identification and analysis of topographic principles helps to determine the main motive of the nomination, the origin of the name, which in turn helps to clarify the relationship of toponyms with natural features, historical events, migration of peoples, their languages, worldview, and also helps to establish the causes of the appearance and distribution of certain names or their components.

**Keywords:** Turkic-Tatar toponymy, oikonymy, appellatives, onyms, toponyms, oikonyms, hydronyms, oronyms, anthroponyms, ethnonyms, phytonyms, zoonyms.

Фәндә топонимнар халыкларның таралу территориясе һәм чикләре, тарихи вакыйгалар, физик-географик үзенчәлекләр, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең эволюциясе турында мөһим мәгълүматларны үз эченә ала дигән фикер гомум кабул ителгән. Шуңа күрә аерым бер төбәк топонимиясен тикшерү әлеге регионда яшәгән халыкларның тарихын, этногенезын һәм мәдәниятен өйрәнүдә зур фәнни әһәмияткә ия. Бу яктан караганда, Көньяк Урал һәм Урал артының топонимик системасы меңнәрчә еллар дәвамында катлаулы географик, тарихи һәм лингвистик шартларда формалашкан. Регион территориясе даими рәвештә күпсанлы этник төркемнәрнең бер-берсенә кушылу, үзара керешү һәм бергә яшәү урыны булып торган. Бу халыкларның һәркайсы биредә үз топонимик катламын булдырган. Алар арасында төрки-татар асыллы атамалар аеруча аерылып тора.

Әлеге тикшеренүнең актуальлеге Көньяк Урал һәм Урал артындагы төрки-татар топонимнарын системалы тасвирлау ихтыяҗы белән билгеләнә. Ул, аерым алганда, регионның үткәндәге этнолингвистик картинасын торгызырга мөмкинлек бирә. Шуның белән бергә бу эш билгеле бер топонимикон эчендәге типологик универсалияләрне һәм географик атамаларның аерым бер төбәккә караган җирле системасы өчен хас үзенчәлекле берәмлекләрне ачыкларга да ярдәм итә.

Тикшеренү материалын бер фәнни мәкалә кысаларында гына колачлау мөмкин булмаганлыктан, ул ойконимнар, ягъни торак пунктларның атамалары белән чикләнде. Чыганаклар буларак Чиләбе һәм Курган өлкәләре буенча топонимик сүзлекләр, аерым алганда, Н.И. Шуваловның «От Парижа до Берлина по карте Челябинской области» (1989) һәм Л.Д. Вохменцеваның «Гидронимы водных объектов Курганской области» (2003) хезмәтләре, шулай ук автор тарафыннан әлеге төбәккә экспедицияләр вакытында җыелган материаллар кулланылды.

Тикшерү барышында Көньяк Урал һәм Урал артының төрки-татар асыллы авыл атамалары килеп чыгышлары буенча безнең тарафтан төп ике төркемгә бүленде:

– апеллятив чыгышлы ойконимнар;

– онимик чыгышлы ойконимнар.

Билгеле булганча, уртаклык исемнәр, ягъни апеллятивлар нигез булган ойконимнарга кеше эшчәнлеге, социаль-икътисади мөнәсәбәтләр, халыкның көнкүреше, әйләнә-тирә мохит белән бәйле, яшәү урыннары һәм торак типларын белдерә торган ойконимик терминнарны үз эченә алган атамалар керә. Әмма торак пунктлар һәм торак атамаларының характерына барыннан да бигрәк хуҗалык тибы һәм аны алып бару ысулы йогынты ясый. Нәтиҗәдә төрле халыкларда яшәү урыннары һәм торак пунктларының үз үзенчәлекле терминнары барлыкка килгән. Хәзерге топонимика фәнендә составларында билгеле бер территория өчен хас булган торак пунктларның типларын, кешенең яшәү урыннары һәм торагын белдерә торган апеллятивлар булган географик атамаларны этномәдәни апеллятивлы топонимнар дип атау кабул ителгән [Мурзаев, 1996, с. 151].

Өйрәнелә торган төбәктә безнең тарафтан түбәндәге төрки-татар асыллы апеллятивлар нигезендә барлыкка килгән ойконимнар теркәлде:

– *кышлак* ‘кышлау, кышлау, тукталыш урыны’ апеллятивы нигезендә: *Каштак авылы: каштак // кыштак // кышлак* (Увельский районы, Чиләбе өлкәсе); *Кыштым шәһәре: кыштым // кыштау // кышлау // кышлак* (Чиләбе өлкәсе);

– *кунчак* ‘төн куну урыны’: *Коншак авылы: коншак // кунчак* (Коншак районы, Чиләбе өлкәсе);

– *утар* ‘терлекләр өчен киртә абзар; йорт, хуҗалык’: *Утар поселогы* (Агаповка районы, Чиләбе өлкәсе). Торак пункт күчмә терлекчеләр туктаган урында барлыкка килгән.

Онимик чыгышлы ойконимнарга бер исемне икенче ономастик класска күчерү юлы белән барлыкка килгән торак пункт атамалары керә. Әлеге юл – яңа ялгызлык исемнәр ясалуның иң киң таралган ысулларыннан берсе [Теория и методика ономастических исследований, 1986, с. 46].

Өйрәнелә торган территориядә төрки-татар асыллы онимик чыгышлы ойконимнар барлыкка килү чыганаклары буенча өч төркемгә бүленә:

– антропонимнардан барлыкка килгән ойконимнар;

– этнонимнардан барлыкка килгән ойконимнар;

– топонимнардан барлыкка килгән ойконимнар.

Көньяк Урал һәм Урал арты ойконимиясендә иң күп санлы төркемне антропоойконимнар тәшкил итә. Мәсәлән, Көньяк Урал һәм Урал артындагы күп кенә торак пунктлар, нигездә, авыллар, беренче күчеп килүчеләрнең исемнәре белән аталган:

– *Әлмән авылы* (Әлмән районы, Курган өлкәсе). Атама балыкчы Әлмән исеменнән алынган. Әлеге кеше беренче булып булачак авыл урынында күл ярына йорт сала;

– *Әмин авылы* (Уй районы, Чиләбе өлкәсе). Архив документлары буенча, авылга Әмин Ибраһимов тарафыннан 1746 елда нигез салына. Җир аңа патша армиясендә хезмәт иткән өчен бирелә;

– *Канаш авылы* (Красноармейский районы, Чиләбе өлкәсе). Миас крепостенә караган беренче авыллар арасында XVIII гасырдан билгеле борынгы торак пункт. Биредә иң беренче булып яши башлаган кешенең фамилиясе буенча *(Канашев)* аталган. Архив документларында 1795 елдан башлап искә алына. Шундый ук исемдәге авыл Курган өлкәсе Шадрин районында да бар;

– *Мусакай авылы* (Коншак районы, Чиләбе өлкәсе). Борынгы торак пункт. Ул бирегә, көчләп чукындырудан котылу өчен, Кама ярларыннан күчеп килгән татарларның ыру башлыгы исемен *(Мусакай)* йөртә;

– *Шигай авылы* (Сосновский районы, Чиләбе өлкәсе). Чиләбе крепостенә караган беренче авыллар арасында XVIII гасырдан билгеле борынгы торак пункт. Ул биредә иң беренче булып яши башлаган кешенең фамилиясе буенча *(Шигаев)* аталган.

Төрки-татар асыллы антропоойконимнарның лексик-семантик анализы аларның күбесендә кайчандыр төрки халыкларда исем бирү белән бәйле булган төрле гореф-гадәтләрнең тирән эз калдырганын күрсәтә. Мәсәлән, шәхси исемнәр системасында теләк-исемнәр зур урын алып тора:

– *Байтук поселогы* (Бреды районы, Чиләбе өлкәсе): *Байтуг (< бай + туг // ту)* ир-ат исеменнән;

– *Бишкил поселогы* (Чибәркүл районы, Чиләбе өлкәсе): ‘бишенче булып туган’ мәгънәсендәге *Бишкилде (< биш + килде)* ир-ат исеменнән;

– *Тимер авылы* (Чибәркүл районы, Чиләбе өлкәсе): бала тимер кебек нык, сәламәт булсын дигән теләк нигезендә барлыкка килгән ир-ат исеменнән һ. б.

Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә кешенең социаль торышын һәм сословие титулларын белдерә торган исемнәр нигезендә барлыкка килгән ойконимнар да очрый. Мәсәлән: *Ак Бай авылы* (Еткүл районы, Чиләбе өлкәсе); *Кызылбай авылы* (Шатрово районы, Курган өлкәсе); *Морзабай авылы* (Сафакүл районы, Курган өлкәсе) һ.б.

Алда әйтеп үткәнчә, Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә төрле халыклар яшәгән һәм яшәвен дәвам итә. Төбәкнең ойконимик системасында кайчандыр анда таралган төрки кабиләләрнең атамалары (этнонимнар) чагылыш тапкан. Мәсәлән, *Катайск* (*катай* башкорт ыру-кабилә берләшмәсе атамасыннан) *шәһәре* (Катайск районы, Курган өлкәсе) һ.б.

Төрки асыллы этноойконимнарда Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә башка төрки халыкларның, шул исәптән татар халкының да, яшәве турында дәлилләр табыла. Мәсәлән, *Нагайбәк* (татарларның этноконфессиональ төркеме атамасыннан) *поселогы* (Нагайбәк районы, Чиләбе өлкәсе); *Татар Караболагы авылы* (Коншак районы, Чиләбе өлкәсе) һ.б.

Яшәү урыннарының атамалары географик атамаларның башка категорияләре – гидронимнар, оронимнар кебек географик терминнар йогынтысына да дучар була. Торак пунктка топонимның нинди төре исем бирүенә бәйле рәвештә, Көньяк Урал һәм Урал арты ойконимнары түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1) гидронимнардан барлыкка килгән ойконимнар;

2) оронимнардан барлыкка килгән ойконимнар.

Көньяк Урал һәм Урал артындагы күп санлы торак пунктларның атамаларында биредәге елгалар һәм күлләрнең исемнәре, шулай ук аларның үзенчәлекләре чагылыш тапкан. Әлеге атамаларны без ике төркемгә бүлдек:

1) гидрографик терминнардан барлыкка килгән ойконимнар;

2) торак пунктның елга тамагында яки чишмә башында урнашуын белдерә торган атамалар.

Көньяк Урал һәм Урал артының ойконимик системасын формалаштыруда түбәндәге төрки-татар асыллы гидрографик терминнар катнаша:

– *су*: *Карсы авылы: карсы // карасы // карасу > кара + су* (Троицк районы, Чиләбе өлкәсе); *Карасу авылы* (Юргамыш районы, Курган өлкәсе);

– *күл : Күлләр поселогы* (Чиләбе өлкәсе);

– *чишмә: Чишмә авылы* (Аргаяш районы, Чиләбе өлкәсе); *Чишмә авылы* (Сосновский районы, Чиләбе өлкәсе);

– *шар* ‘сазлык, камышлы урын’: *Шарлаш бистәсе,* (Катав-Ивановск районы, Чиләбе өлкәсе) һ.б.

Төбәктәге гидроойконимнарның икенче төркемен торак пунктның урнашу урынын белдерә торган атамалар тәшкил итә. Мәсәлән: *Алакүл күле – Алакүл авылы* (Әлмән районы, Курган өлкәсе), *Балакүл күле – Балакүл авылы* (Лебяжье районы, Курган өлкәсе), *Комкүл күле – Комкүл поселогы* (Коншак районы, Чиләбе өлкәсе) һ.б.

Билгеле булганча, кешеләр элек-электән үзләре яшәгән урыннарның өслек үзенчәлекләренә игътибар иткәннәр һәм еш кына аларны торак пунктларның атамаларында чагылдырганнар. Мәсәлән, Көньяк Урал һәм Урал артының ойконимик системасын формалаштыруда түбәндәге төрки-татар асыллы оронимик терминнар катнаша:

– *тау: Юкә Тау поселогы > юкә + тау* (Сатка районы, Чиләбе өлкәсе);

– *таш: Сукташ авылы > суык + таш* (Сатка районы, Чиләбе өлкәсе);

– *ялан: Ялан авылы* (Сафакүл районы, Курган өлкәсе);

– *сырт: Сыртинский поселогы > сырт + -инский* (Кизильский районы, Чиләбе өлкәсе);

– *яр: Югары Яр һәм Түбән Яр авыллары* (Далматово районы, Курган өлкәсе).

Географик объектларның номинациясендә үсемлекләр дөньясының атамалары зур роль уйный. Көньяк Урал һәм Урал арты фитоойконимнарында төбәк өчен типик булган үсемлек атамалары чагылыш таба. Биредә ойконимнарга нигез булган әлеге төр лексемалардан *камыш* сүзе еш очрый. Мәсәлән: *Камыш авылы* (Аргаяш районы, Чиләбе өлкәсе), *Камышлы поселогы* (Бреды районы, Чиләбе өлкәсе) *Алакамыс поселогы* (Варна районы, Чиләбе өлкәсе) һ. б.

Фауна турындагы мәгълүматны үз эченә алган зоонимнардан барлыкка килгән ойконимнарда төбәкнең хайваннар дөньясы, шулай ук җирле халыкның яшәү рәвеше үзенчәлекләре чагыла. Көньяк Урал һәм Урал артының топонимик системасында урын алган зоойконимнар ике төркемгә бүленә:

1) кыргый фауна вәкилләренең атамаларыннан барлыкка килгән ойконимнар: *Олы Кабан авылы* (*кабан* зоонимыннан) (Шадрин районы, Курган өлкәсе), *Бурино авылы* (*бүре* зоонимыннан) (Коншак районы, Чиләбе өлкәсе). *Каманкүл авылы* (*каман // кама* зоонимыннан) (Октябрьский районы, Чиләбе өлкәсе) һ.б.;

2) йорт хайваннары һәм кошларының атамаларыннан барлыкка килгән ойконимнар: *Куйсак поселогы* (*куй* зоонимыннан) (Агаповка районы, Чиләбе өлкәсе), *Кучкар авылы* (*кучкар* зоонимыннан) (Чиләбе өлкәсе) һ.б.

Шул рәвешле, Көньяк Урал һәм Урал арты төбәге төрки-татар ойконимнарының лексик-семантик үзенчәлекләрен анализлау нәтиҗәләре төбәк топонимиясенең билгеле бер физик-географик, тарихи һәм этнолингвистик факторлар йогынтысында формалашуын күрсәтә.

**Әдәбият**

*Вохменцева Л.Д.* Гидронимы водных объектов Курганской области. Курган, 2003. 100 с.

*Мурзаев Э.М.* Тюркские географические названия. М.: Вост. лит., 1996. 252 с.

Теория и методика ономастических исследований / А.В. Суперанская, В.Э. Сталтмане, Н.В. Подольская, А.Х. Султанов. М.: Наука, 1986. 256 с.

*Шувалов Н.И.* От Парижа до Берлина по карте Челябинской области: Топоним. слов. 2-е изд., перераб. и доп. Челябинск: Юж.-Урал. кн. изд-во, 1989. 158 с

***Гатауллин Радик Равил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Зеленодольск муниципаль районы 5 нче гимназиясенең*
*уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары*

УДК 81′282

***А.Я. Хөсәинова***

# ИРКУТСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР КҮЧМӘ СӨЙЛӘШЛӘРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТӨРКЕМЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

В данной статье рассматриваются фонетические и лексические особенности татарских переселенческих говоров Иркутской области. Исследуются история переселения и специфические особенности языка татарского населения Иркутской области. Новизна исследования заключается во введении в научный оборот новых диалектологических материалов. Рассматривается проблема классификации переселенческих говоров.

**Ключевые слова:** переселенческие говоры, материнские говоры, фонетические особенности.

This article discusses the phonetic and lexical features of the Tatar migrant dialects of the Irkutsk region. The article examines the history of migration and specific features of the language of the Tatar population of the Irkutsk region. The novelty of the research lies in the introduction of new dialectological materials into scientific circulation. The problem of classification of migrant dialects is considered.

**Keywords:** migrant dialects, mother dialects, phonetic features.

Татар теленең күчмә сөйләшләрен өйрәнү диалектологиянең актуаль мәсьәләләренең берсе булып тора. Төрле территориядә таралган сөйләшләр буенча материаллар шактый җыелса да, аерым сөйләшләрнең төрле телләр белән элемтәсе нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр һәм ана сөйләшләр (билгеле бер төбәктә таралган сөйләш, аның вәкилләренең бер өлеше күчеп, яңа урында күчмә сөйләш формалаштыра) белән чагыштырма анализ аспектындагы тикшеренүләр бик аз. Әлеге тикшеренүләр бик мөһим, чөнки кайбер күчмә сөйләшләргә (күчеп килүчеләр тарафыннан формалаштырылган, нигездә, башка диалект, чит тел мохитендәге сөйләшләр) тулы нивелировка (тигезләү) процессы яный. Шул сәбәпле җирле материалны җыеп, анализлап, дөрес классификацияләү диалектологларның мөһим бурычы булып тора.

Татар халык сөйләшләре гаять киң территорияләргә таралган. Әлеге территорияләрнең күбесенә татар халкы төрле вакытта һәм төрле юллар белән күчеп килгән. Алар төрле яклардан чыккан кешеләр булып, яңа җирләрдә үсешләре төрле шартларда бара. Боларның барысы да яңа территориядә формалашкан сөйләшләр үсешендә төрлелеккә китерә. Шул ук вакытта сөйләшләрнең барлыкка килүендә һәм үсешендә бер үк закончалыклар да күзәтелә.

Беренчедән, болар – икенчел, соңрак барлыкка килгән сөйләшләр, ягъни күчмә сөйләшләр, алар инде формалашкан диалекталь төрләргә нигезләнә. Икенчедән, яңа урында формалашкан сөйләшләрнең

нигезе беренчел сөйләшләрнең нигезеннән шактый аерылып тора. Өченчедән, соңрак формалашкан сөйләшләрнең үсеше көчле диалектара, телара контактлар шартларында бара. Дүртенчедән, күчмә сөйләшләрнең формалашуына йогынты ясаган экстралингвистик факторлар төрлелеге белән аерыла. Бишенчедән, икенчел сөйләшләрнең формалашуы чагыштырмача соңрак чорда була, шулай булгач, әдәби телнең йогынтысы күбрәк чагыла [Баранникова, 1975, с. 22].

Күчмә сөйләшләр формалашу үзенчәлекләрен классификацияләгәндә ике аспектны да исәпкә алу сорала. Сөйләш төрләрен аерып чыгарганда аларның структуралы үзенчәлекләрен генә түгел, экстралингвистик факторларны да исәпкә алырга кирәк.

Түбәндәге экстралингвистик факторлар аеруча әһәмиятле:

1. Сөйләш вәкилләренең күчү вакыты. Бу фактор ике аспектта мөһим: ул сөйләшнең яңа шартларда үсешен һәм күчеп утыручылар сөйләшенең үзенчәлекләрен, аның тотрыклылык дәрәҗәсен, башка сөйләшләрдән аермасын билгеләргә мөмкинлек бирә. Кайбер очракларда күченү вакытын белү аша ана сөйләш белән уртак диалекталь үзенчәлекләрне аерып чыгарып була.

2. Күчү характеры. Бу аспектта, беренчедән, күчешнең бер вакытта яки төрле вакытта булуын һәм күчешнең киң таралуын яки сирәк очравын аерырга кирәк. Күләмле күчешләр, гадәттә, чагыштырмача бер вакытта булалар; соңрак аларга берешәрләп күчүчеләр кушыла. Әмма бу күчмә сөйләшләр формалашуга зур йогынты ясамый.

3. Тирә-як территориядә яшәүче кешеләр белән мөнәсәбәт. Гадәттә кешеләр яшәгән территорияләргә күчеп утыралар. Һәм нәтиҗәдә җирле халык белән төрле мөнәсәбәтләр туарга мөмкин.

Югарыда әйтелгән кклассификацион билгеләрдән тыш, турыдантуры лингвистик билгеләр дә бар:

1. Диалекталь нигез характеры күчмә сөйләштә аның бөртөрле булуы белән бәйле. Шул рәвешле өч төр сөйләш аерыла:

– монодиалект нигезле сөйләш вәкилләре, нигездә, бер яки берничә, бертөрле, якын сөйләшләр таралган пунктлардан күчеп киләләр;

– бидиалект яисә полидиалект нигезле сөйләшләр вәкилләре төрле урыннардан күчкәннәр, төрле сөйләш вәкилләре булганнар;

– башлангыч күптөрлелек яки яңа территорияләрдә барлыкка килгән шактый үзгәрешләр нәтиҗәсендә диалекталь нигезе аерылмый торган сөйләшләр катнаш нигезле сөйләшләр дип атала.

2. Сөйләш нигезләренең мөнәсәбәт үзенчәлекләре. Бу билге күчмә сөйләшнең диалекталь нигезе һәм тирә-як сөйләшләрнең бөртөрле булу-булмавында күзәтелә. Шулай ук күчмә сөйләш чит тел тирәлегенә эләгергә мөмкин.

3. Ана сөйләшләр белән бәйләнеш үзенчәлекләре. Бу аспект аеруча мөһим, шул ук вакытта аны ачыклау да кыенрак. Күчмә сөйләшләрнең монодиалекталь нигезе булса да, ана сөйләшләрнең хәзерге торышы, күчеш вакытындагыдан аерылырга мөмкин. Күчмә

сөйләш, нигездә, һәрвакыт ана сөйләштән аерылып тора, чөнки башка шартларда үсеш ала, һәм алар аңа көчле йогынты ясый. Әмма аерылу дәрәҗәсе төрле булырга мөмкин. Шуның белән бәйле рәвештә, беренчел һәм икенчел күчмә сөйләшләрне аерырга мөмкин. Беренчелгә төп үзенчәлекләрендә үзләренең баштагы төрен саклаган сөйләшләрне кертәбез. Икенчелләренә – шактый зур үзгәрешләр кичергәннәрен.

4. Икенчел сөйләш сыйфаты. Икенчел сөйләшнең диалекталь нигезен кайвакыт төгәл ачыклау кыенлык тудырырга мөмкин. Еш кына ул катнаш яки күчмә характерда була. Диалектологиядә күчмә характердагы сөйләшләр дип диалекталь нигезе төгәл ачыкланган, шул ук вакытта әдәби телгә яки башка диалектка якынайган сөйләшләр атала. Катнаш сөйләшләрнең диалекталь нигезе авыр билгеләнә, төрле вариантларның кушылуы күзәтелә.

5. Сөйләшнең нинди диалекттан килеп чыгуы. Нинди диалекталь җирлектән күченгәнлек экстралингвистик факторлар белән билгеләнә [Баранникова, 1975, с. 28–29].

Әлеге мәкаләдә татар теленең күчмә сөйләшләре арасыннан без Иркутск өлкәсе татар сөйләшләрен тикшерәбез. Фәндә моңа кадәр бу территориядәге татар сөйләшләрен өйрәнгән хезмәт юк.

Диалектологиядә башка телләр һәм аларның сөйләшләре булган тирәлектәге, ягъни чит телле тирәлектәге сөйләшләр утрау яки анклав сөйләшләр дип атала [Теркулов, 2009, с. 155–159]. Димәк, без тикшергән татар күчмә сөйләшләре дә – анклав сөйләшләр.

Әлеге мәкаләдә без татар күчмә анклав сөйләшләр формалашуда һәм аларның үсешендә югарыда әйтелгән факторларны тикшерәбез.

Өйрәнелгән районнарны авыл хуҗалыгы максатларында үзләштерү Көнбатыш Себердән 500 крестьян гаиләсен күчерү турында 1688 елгы указдан башлана. Крестьяннарның күчеше XIX гасыр ахырына кадәр бара. Бу Никольский Чиркәве (Залари) метрика китапларындагы язмалар белән дәлилләнә. Әлеге христиан динендәге крестьяннар белән бергә Көнбатыш Себердә Себер ханлыгы вакытында ук яшәгән татарлар күчкән булырга мөмкин. Бу фикерне регионддагы топонимик материаллар да раслый. Без тикшергән җирлекнең топонимикасы, Себер регионындагы татарлар күпләп яшәгән башка төбәкләр белән беррәттән, комплекслы экспедицияләр вакытында өйрәнелә һәм анализлана [Хисамов, Гумеров, 2020, с. 159–169]. Мәсәлән, Залари районының 1798 елгы торак пунктлар исемлегендә Минусинский хуторы бар. Заларидан ерак түгел беренче заимканы – Сейфуллин Заимкасын, татар кешесе нигезләгән булырга тиеш. Шуннан соң шул тирәдә, Мәскәү трактыннан ерак түгел, 1905 елгы карталарда Фахардитов, Каптигулов, Апсолямов заимкалары билгеләнгән [Бобкова, 2009, с. 65].

Әлеге фамилияле кешеләрне сөргенгә җибәрү фактын да читләтеп үтәргә ярамый. Нәкъ XIX гасырда Залари авылында сөргендәге татарлар була, алар фамилияләрен югалтып, яңа кушаматлар ала – Непомнящие, Сантяповы һ.б. Алар Себердә яши башлыйлар, мәчет

төзиләр. Әлеге фамилияләр күптән яшәгән кешеләрнеке, ягъни Столыпин реформаларына кадәр үк булган дип санала. XIX гасырның икенче яртысы һәм XX гасыр башында Көнчыгыш Себердә яшәүчеләрнең саны 2,5 тапкыр арта. 1863 елда ул 1269,4 мең кеше булса, 1897 елда – 2026,3 мең, 1917 елда 3113,4 мең кешегә җитә [Воробьев, 1975, с. 146].

Әлбәттә, Көнбатыш Себер регионнары арасында бу аспектта төрлелек күзәтелгән. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында илнең көньягындагы һәм көнбатышындагы җирләр алынып беткән дияргә мөмкин, һәм күпсанлы күчүчеләр Урал аръягына юнәләләр, Көнбатыш Себердә яшәүчеләрнең саны 6,5% ка арта. Иң зур күчеш агымы – әлбәттә, крестьяннарның яңа җирләргә күченүе. Шушы агымда Урта Идел буе һәм Урал буе татарлары да күчеп утырган. Моны 1897 елда үткәрелгән беренче гомумхалык санын алу вакытында теркәлгән Байкал буенда яшәүче татарларның һөнәрләре турындагы мәгълүматлар һәм башка материаллар раслый [Бобкова, 2009, с. 66].

Югарыда күрсәтелгән тарихи шартларда формалашкан татар күчмә сөйләшләрен, каралган лингвистик һәм экстралингвистик факторларга нигезләнеп, түбәндәгечә бәяләп була. Күчү характерыннан чыгып, әлеге сөйләшләр төрле вакытта күчкән вәкилләр тарафыннан формалашкан. Сөйләш вәкилләре тирә-як территориядә яшәүче халыклар белән тыгыз элемтәдә булган. Сөйләшләрнең нигезе полидиалекталь характерда.

Иркутск өлкәсендә шундый шартларда барлыкка килгән татар күчмә сөйләшләрендә барлык анклав сөйләшләргә дә хас үзгәрешләр күзәтелә. Ана сөйләшләрдә юкка чыккан яки сирәк кулланылган архаик лексик яки грамматик үзенчәлекләр күчмә сөйләшләрдә саклана. Ә икенче яктан, чит телле тирәлек сөйләшләрнең телен лексик, фонетик яктан баета. Түбәндә без Иркутск өлкәсендәге татар сөйләшләренең кайбер фонетик һәм лексик үзенчәлекләренә тукталырбыз.

Фонетик яктан Иркутск өлкәсендәге сөйләшләрдә, башка сөйләшләрдәге кебек [Бадртдинова, 2017, с. 34] авазлар составы әдәби телдәгегә якын. Әмма кайбер үзенчәлекләр күзәтелә. Мәсәлән, [***а***] авазының иренләшү белән беррәттән ачык әйтелеше дә очрый: *алты, бара, кара* һ.б.

Өйрәнелгән сөйләшләрдә аваз тәңгәллекләре еш очрый, мәсәлән, әдәби [***ө***] урынына [***э***] авазы кулланыла: *эченче* – өченче. Кайбер сүзләрдә әдәби [***о***] авазына [***ы***] авазы тәңгәл килә: *тырмыш* – тормыш, *хыдай* – ходай, *кыймак* – коймак. Әдәби телдәге [***э***]/[***е***] урынына [***и***] авазы кулланыла: *ичмәй* – эчми, *пичән* – печән, *ич* – эч, *биз-* без. Билгеле бер төркем сүзләрдә [***о***], [***у***], [***ө***]~[***ү***], [***у***]~[***ы***] сузыкларының тәңгәллеге дә күзәтелә**:** *күреш* – көрәш, *төшәм* – түшәм, *орлыйлар* – урлыйлар, *бутқа* – ботка, *шылай* – шулай, *шыларны* – шуларны, *турмышта* – тормышта, *ырламаска* – урламаска. Кайбер сүзләрдә әдәби [***ы***] сузыгы [***а***] сузыгына тәңгәл килә: *кыстабай* – кыстыбый һ.б.

Тартык авазларның әйтелеше ягыннан өйрәнелгән сөйләшләр әдәби телдән аерылмый. Сөйләшкә хас булган диалекталь үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, әдәби тел увуляр [*қ*], [*ғ*] тартыклары белән беррәттән тел арты [*к*], [*г*] тартыкларын да куллану күзәтелә.

Тикшерелгән сөйләшләргә сүз башындагы позициядә нигездә *җ*-лаштыру хас: *җук* – юк, *җәшем* - яшем, *җәшел* - яшел, *җаз* - яз, *җегерменче* – егерменче. Ләкин, кайбер торак пунктларда, киресенчә *й*-лаштыру да күзәтелә: *йомга көн* – җомга көн, *ерлар ерлый* – җырлар җырлый.

Бер төркем сүзләрдә әдәби [***б***] тартыгына [***п***] тартыгы туры килә: *пишь, пер, пардым, кәпестә*.

Түбәндәге мисалларда ике сузык арасындагы [***д***] тартыгы урынына иркутск сөйләшләрендә [з] тартыгы кулланыла: *бозай* – бодай, *изән* – идән.

Әдәби телдәге [***ч***] авазына [***с***] авазы тәңгәл килүне, һәм кире күренешне дә өйрәнелгән сөйләшләренең үзенчәлеге дип күрсәтергә кирәк: *бачкыч* – баскыч, *кескенә* – кечкенә.

Аерым сүзләрдә күзәтелә торган тәңгәллекләр: [***к***]/[***т***] *икмәк* – итмәк, [***с***]/[***з***] *сигзян* – сиксән, [***р***]/[***з***] *үткәзәләр* – үткәрәләр, [***з***]/[***с***] *сес* – сез, *бес* – без, [***с***]/ ***[ц***] *цукыр* – сукыр, [***җ***]/[***з***] *кәзә* – кәҗә, [***ч***]/[***тч***] *этчәм* – эчәм, [***к***]/[***г***] *биг* – бик, *бүтәгә* – бүтәкә, [***х***]/[***к***] *якшы* – яхшы, [***р***]/[***р'***] *кур'ам* – күрәм, [***л***]/[***л'***] *бел'ан* – белән, [***н***]/[***н'***] *ән'иләр* – әниләр, [***т***]/[***т'***] *ирт'а* – иртә, *әт'миләр* – әйтмиләр.

Бер төркем сүзләрдә тел очы [**с**] тартыгы үзеннән соң килгән [***ч***] авазына тулысынча охшашлана: *чөйөнче* – сөенче, *бачқыч* – баскыч.

Кайбер сүзләрдә түбәндәге тартыклар төшеп кала: *элкеге* – элеккеге, *муча* – мунча, *йалында* – өй алдында.

Метатеза (янәшә яки арадаш торган авазларның урыну алышу) күренеше түбәндәге мисалларда күзәтелә: *җегеременче – егерменче, азбар иясе – абзар иясе.*

Тупланган материаллар күрсәткәнчә, сөйләшләргә хас лексик-семантик система да татар әдәби теленең сүзлек фондына бик якын. Әмма өйрәнелгән сөйләшләрнең кайбер аерымлыклары да бар. Табылган диалекталь сүзләр тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләренә карый.

**Туганлык атамалары:** *әтү, әнү, картый, инәй, картәтәй, әтәү, җиңгәчәй, қатын, нәнәй, дәү әти.*

**Йорт-җир, хуҗалык атамалары:** *саплаяк* – ковш*, бидерә, сәндерә, стайка, ызба, зур пич, табагач, пич алдысында, капка*

**Аш-су атамалары:** *әпи, икмәк, колак* – кош теле, *бүккән* – татар бөккәне, *умарта* – кош теле, *май ашы* – кош теле, *төрмә* – пирожок.

Әлеге материаллар Иркутск өлкәсендәге татар сөйләшләренең фонетик, лексик-семантик системасының күпкырлы һәм кызыклы булуы турында сөйли. Өйрәнелгән сөйләшләр татар теле диалектлары системасында мөстәкыйль урын алырга тиеш, алар татар теле тарихы, диалектология фәне өчен әһәмиятле сөйләшләр булып тора.

Бу сөйләшләр әдәби телгә якын, шулай да аларның үзенә генә хас фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләр системасы формалашкан. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, өйрәнелгән сөйләшләр вәкилләренең күпчелеге Казан, Уфа губерналарыннан күчеп килгәннәр, нигездә алар – татар теленең урта диалекты вәкилләре, әмма әлеге территорияләрдән һәм Пенза өлкәсеннән күчеп килгән мишәр сөйләшләре вәкилләре дә бар. Үзенчәлекле үсеш алган керәшен сөйләшләре вәкилләре дә бирегә Казан артыннан һәм Башкортстанның Бакалы районыннан күчеп утырганнар. Димәк, Иркутск өлкәсе татар сөйләшләре өчен нигез, ана сөйләш булып казан арты сөйләшләре төркеме, шулай ук Идел буе һәм Урал буе төбәкләрендә таралган урта һәм көнбатыш диалект сөйләшләре тора. Ана сөйләшләр белән уртак үзенчәлекләрдән, мәсәлән, казан арты сөйләшләре төркеме үзенчәлекләре саклана. Шуларның берсе – *анысы, монысы, кайсы, шунысы* алмашлыкларында 3 зат берлек санда икеләтелгән тартым кушымчалары ялгану (*қайсысы, шунсысын),-дагын/-тагын* һ.б. Систематик рәвештә мишәр диалектына хас тел алды [***т***], [***д***], [***с***], [***ц***], [***н***], [***л***] алдында [***-ай***]/[***-әй***], [***-уй***]/-[***-үй***], [***-ый***] дифтонгларын монофтонглаштыру күзәтелә: *әтәбез – әйтәбез, сүлиләр – сөйлиләр, бәли – бәйли* һ.б

Тикшерелгән мәглүматлардан күренгәнчә, күчмә сөйләшләрдә төрле диалектлар, телләр арасындагы элемтәләр чагылырга мөмкин. Аларның баштагы нигезен саклаган хәлдә (лексик фонд, фонетик, морфологик системалар), сөйләшләр актив рәвештә тирәлектәге телләрдән алынмалар алу ярдәмендә байый. Шул ук вакытта, изоляцияләнү сәбәпле, күпчелек диалектизмнар сакланып кала. Тикшерелгән сөйләшләр югалу юлында, чөнки күчеп килгән халыкның яшь буыны татар телен белми диярлек яисә бик начар белә. Әлеге территориядә яшәүче татарларның теле өйрәнелмәгән. Шуңа күрә дә Иркутск өлкәсендәге күчмә сөйләшләрне өйрәнү бүгенге көндә бик актуаль мәсьәлә булып тора.

**Әдәбият**

*Бадртдинова А.А.* Урта диалект вокализм системасына күзәтү // Фәнни Татарстан. 2017. № 4. С. 28–34.

*Баженова Т.Е.* О диагностических возможностях лексики в решении проблемы генезиса переселенческих говоров // Научный диалог. 2016. № 11 (59). С. 16–25.

*Баранникова Л.И.* Говоры территорий позднего заселения и проблема их классификации // Вопросы языкознания, 1975. № 2. С. 22–31.

*Бобкова Г.И.* Татарские общины Иркутской губернии (конец XIX – начало XX в.) : монография. – Иркутск: Изд-во Иркут. гос. ун-та, 2009. 219 с.

*Воробьев В.В.* Формирование населения Восточной Сибири. Географические особенности и проблемы Новосибирск: Наука. Сиб. отд., 1975. 259 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М.: Наука, 1997. – 800 с.

Татар теленең зур диалекталогик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре: ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казань: Мәгариф, 2008. Беренче китап. 463 б.

*Теркулов В.И.* О методологии исследования анклавного говора // Філологічні трактати. Суми – Харків. 2009. № 2. Т. 1. С. 155–159.

*Хисамов О.Р., Гомәров И.Г.* Иркутск татарлары тарихында Шәйхулла Шафигуллин (фәнни экспедиция һәм архив материаллары нигезендә) // Эхо веков. 2020. № 1. С. 159–169.

*Цаллагова И.Н.* Переселенческие говоры дигорского варианта осетинского языка // Известия СОИГСИ. Вып. 17 (56). 2015. С. 89–99.

***Хөсәинова Алинә Ямил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-1

*Г.Ф. Төхфәтова*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ТУГАН ТЕЛ» ШИГЫРЕ: БАСЫЛУ ТАРИХЫ ҺӘМ ТӘРҖЕМӘ ТӘҖРИБӘЛӘРЕ

В статье, основываясь на нововыявленных источниках, воспоминаниях современников, рассматривается история написания стихотворения Габдуллы Тукая «Родной язык».

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, история литературы, татарский язык, родной язык, история изучения.

The article based on newly revealed sources and memoirs of contemporaries examines the history of writing the poem «Native language» by Gabdullah Tuqay.

**Keywords:** Gabdullah Tuqay, history of literature, Tatar Language, native language, history of study.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай (1886–1913) исемен атауга, аның атаклы «Туган тел» шигыре искә төшә. Татар халкы өчен ул гимн, изге текст сыйфатында йөри.

«Туган тел» шигыре беренче тапкыр Г. Тукайның «Балалар күңеле» җыентыгының беренче басмасында нәшер ителә. Китап «Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов лито-типографиясендә «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларны теркәү дәфтәре» [Матбугат эшләре..., 1 тасв.] буенча 1909 елның 23 ноябрендә басылып чыккан. Җыентыкка балалар өчен язылган 23 әсәр кертелгән.

Шагыйрь үзе «Туган тел» шигыренең максатын «туган тел вә әдәбиятымызга мәхәббәт уяту» [Тукай, 1911, б. 4] дип билгели. Мәшһүр татар драматургы, җәмәгать эшлеклесе Кәбир Бәкер (1885–1944) «Балалар күңеле» исемле җыентыкка бирелгән бәяләмәсендә Г. Тукайның әлеге шигыре турында: «“Туган тел” балалар рухына бик якын һәм бик муаффәкыятьле бер рәвештә язылган» [Бәкер, 1910], – дип искәртә.

Тәүге тапкыр халык игътибарына тәкъдим ителгәннән соң озак та үтми, 1910 елның 15 апрелендә иң алдынгы татар зыялыларын берләштергән «Шәрык клубы»нда укылган «Халык әдәбияты» лекциясен дә Г. Тукай «Туган тел» шигыре белән тәмамлый. Мандолиначы Җ. Мәҗитов истәлекләреннән күренгәнчә, «Йомшак кына аваз белән, җылы гына җөмләләр белән башланган бу лекция бара-бара эзгә төшә, һәм Г. Тукай үзе дә (су коеныр алдыннан чирканчык алган кеше кебек) иркенләп сулу ала һәм сөйли торган сүзен киңәйткәннән-киңәйтә бара. Халык лекцияне бик яратып тыңлый...» [Миңнуллин, 2013, б. 37]. Шул ук елда шагыйрьнең әлеге чыгышы Казанда «Сабах» көтепханәсе тарафыннан И.Н. Харитонов матбагасында аерым китап булып басылып чыга.

Лекциядә дә, китапта да «Туган тел» шигыренең бирелешендә «Балалар күңеле» басмасындагыдан үзгәрешләр бар. Әсәр тамашачыларга кыскартылып тәкъдим ителә: икенче куплеты төшереп калдырылган. Шулай ук шигырьнең соңгы өлешендә, *үзем һәм әткәмәнкәмне, Ходам* гыйбарәләре үзгәртелеп, түбәндәгечә бирелгән:

Ярлыкагыл, дип, үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам.

Шигырьнең 6 нчы юлы «Балалар күңеле»нең 1 нче басмасында *Кечкенәдән тышка чыккан шатлыгым, кайгым минем* дип, ә «Халык әдәбияты»нда *Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем* дип бирелгән.

Г. Тукайның «Туган тел» шигыре шагыйрь үзе исән вакытта ук халык арасында киң тарала. 1910 елда нәшер ителгән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясенең титул битендә әсәрнең беренче ике юлы китерелә:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

1912 елда Оренбургта «Мәктәп балаларына махсус шигырьләр» исемендә Г. Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, М. Гафури, Н. Думави, З. Бәшири шигырьләреннән тупланган хрестоматия басылып чыга. 102 битле, 5 фасылдан торган бу китапта Г. Тукайның төрле елларда язылган шигырьләре белән беррәттән «Туган тел»е дә кертелгән.

Шагыйрь үзе исән вакытта ук «Туган тел» шигыренең алты тапкыр нәшер ителүе билгеле (алдагы эзләнүләрдә бәлки башка чыганаклар да ачыкланыр). Алда күрсәтелгән чыганаклардан тыш, шигырь Г. Тукайның балалар өчен туплап чыгарылган әсәрләр җыентыгы – «Балалар күңеле»нең 1911 елда Казанда «Сабах» көтепханәсе, «Өмид» матбагасында нәшер ителгән икенче басмасына да кертелә.

Шигырь Г. Тукайның укыту-тәрбия материаллары бер системага салынган «Яңа кыйраәт» китабының икенче басмасына да урнаштырыла (беренче басмасында юк). Китап 1910 елда нәшер ителә. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясенең кереш өлешендә «Яңа кыйраәт» китабы хакында ул «… һәр шигырь вә мәкаләләрне бер төрле мәгълүм максад белән дәреҗ иткән идем» [Тукай, 1911, б. 3], – дип искәртеп үтә.

Әлеге дәреслекләр Казан мәдрәсәләрендә генә түгел, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә кулланылган. Алар 1909 елдан 1919 елга кадәр «Үрнәк», «Мәгариф», Антонов басмаханәләрендә бастырылган.

Татарлар яшәгән, төрки халыклар гомер иткән һәр өлкәдә бөек шагыйрьнең «Туган тел» шигыре яңгырый. «Без, балалар, бергә кушылып җырлый торган “Туган тел” җырын язган Габдулла Тукай исемле кеше Казаннан Астраханьга килгән, хәзер нindидер мөсафирханәдә яши икән» [Мөхәммәдова, 2015, б. 723], – дип илһамланып искә ала Г. Ибраһимовның хатыны язучы Гөлсем Мөхәммәдова.

Габдулла Тукай 1912 елның апрель аенда Петербургка баргач, «Туган тел»не кызлар хоры башкара [Бәкер, 2015, б. 658]. Башкалада мондый чыгышлар соңрак та кабатлана. Мәсәлән, Петербург җәмгыяте хәйрия мәктәбе 1914 елның апрелендә, шагыйрьнең вафаты җәһәтеннән, искә алу мәрасиме үткәрә. «Туган тел»не сөйләгән хорга күпләр ихтыярсыз кушылып китә. Шигырь юллары һәркемдә туган телгә, милләткә, әдәбиятка мәхәббәт уята.

1914 елда «Мәгариф» нәшриятында күптән көтелгән, «һәр өйдә бер нөсхә булырга тиеш китап» [Игълан, 1915] «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» басыла. 1915 елда Петербургта чыга торган «Ил» газетасы билгеләп үткәнчә, «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре – әдәбиятымызда беренче мәҗмугаи асардер» [Габдулла Тукай..., 2015]. Казанда «Мәгариф» көтепханәсе, «Мәгариф» матбагасында нәшер ителгән әлеге җыентыкны Г. Тукай үзе исән вакытта төзеп калдыра.

Җыентыкның тарихы 1912 елның көзендә башлана. Клячкин хастаханәсендә ятканда да Г. Тукай эшен дәвам итә. Г. Тукайның үләренә 40 көн кала аның янына хастаханәгә барган нәшир Шәһәр Шәрәф (1879–1938) шагыйрьнең, «Мәгариф» көтепханәсе соравы буенча, үзенең бөтен язган шигырьләрен бер тәртипкә китереп, «Мәҗмугаи асар» әзерләгән вакыты»на туры килә [Шәрәф, 2015, б. 290]. Шул вакыт бәгъзы шигырьләрен бозып, төзәтеп утырган Тукай үзенең иҗатын «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми» [Шәрәф, 2015, б. 290] дип бәяли.

14 мартта Г. Тукай соңгы «Уянгач беренче эшем» мәкаләсен яза. Мәкалә «Кояш» газетасының 1913 ел 18 март (74 сан) санында басылып чыга: «1913 ел, менә мин уяндым. (...) Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем. Валлаһел муаффикъ» [Тукай, 2015, б. 262].

Әлбәттә, шагыйрь мәҗмугага «Туган тел» шигырен кертмичә калдыра алмый. Җыентыкта әсәрнең ике төрле варианты очрый. Беренче варианты тулы килеш «Балалар кыйсеме» бүлегенә кертелгән. «Халык әдәбияты» әсәре дә «Туган тел» шигыре белән тәмамлана. Биредә, «Халык әдәбияты»ның беренче басмасындагы кебек үк, әсәрнең икенче дүртьюллыгы төшереп калдырылган.

Г. Тукайның «Мәҗмугаи асар»га кертелгән башка кайбер әсәрләре дә үзгәртелгән. Мәсәлән, «Күз» шигырендә шактый үзгәрешләр күзәтелә. Әсәрне мәҗмугага урнаштырганда аның уртадагы һәм ахырындагы ике дүртьюллыгы төшереп калдырыла. Шулай ук *татар башы кеби кыр* гыйбарәсе *фәкыйрь калды кысыр кыр* юллары белән алыштырыла.

Г. Тукайның үлеменнән соң аны искә алу кичәләрендә «Туган тел» әсәре еш яңгырый, аның сүзләре Җир шарының төрле почмакларына барып җитә.

Икенче апрельдә халык шагыйре Тукаевның вафатына ел тулу мөнәсәбәте илә Харбин мөселманнары, мәчеткә җыелып, Тукаевны

бик олылап искә алалар һәм кичәдә «7 яшьлек бер баланың фәүкылгадә (гадәттән тыш) назик (нечкә) вә нәфис бер тавыш белән:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле, –

дип укуы вә “Кадер кич” бик тәэсирле чыкты» [Әхмәди, 2015, б. 231], – дип яза Харбин шәһәре имамы һәм мөдәррисе Гыйниятулла Салиәхмәт.

«Г. Тукай мәктәп шигырьләрендә балаларыбызны Аллага кайтырга, һәр эштә Аллага таянырга куша, шундук иң мөкаддәс хис – ата-ананы сөю хисене дә калдырмый, алар өчен Аллага дога кылырга кирәк икәнлекне “И туган тел” шигырендә аңлата. Балаларга туган телләренә мәхәббәтне уятырга иҗтиһад итә» [Хуҗа, 2015, б. 80].

Россиянең иң ерак һәм иң зур каторгаларыннан берсе урнашкан Александровск авылындагы (Иркутск шәһәреннән 76 чакрым ераклыкта) мәктәптә дә балалар шагыйрьнең әсәрләрен өйрәнәләр. «Зиндан биналарыннан туктаусыз богау тавышлары ишетелеп торса, мәктәп эчендә Г. Тукайның “Туган тел”, “Пар ат”, “Мәхбүс” кебек әсәрләре яңгырый иде» [Әмиров, 2015, б. 700], – дип искә ала биредә укытучы Мөбарәкҗан Әмиров.

«Милли хис вә милли гакыл берлә кушылып эшләнгән бу шигырь парчасы Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлеседер» [Исхакый, 1938; Ил йолдызы, б. 55], – дип бәяли шигырьне җәмәгать эшлеклесе, язучы Гаяз Исхакый (1878–1954) 1938 елда «Яңа милли юл» журналында басылып чыккан «Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә» мәкаләсендә.

«Туган тел» әсәре балаларның аерылгысыз юлдашына әверелә, төрле әдәби кичәләрдә хор белән башкарыла, туган телдә белем бирүнең аерылгысыз бер өлеше буларак карала. «Ул (Г. Тукай. – *Г.Т.*), милли вазифа башындагы гаскәр кеби, берсе артыннан берсе, балалар өчен, кыйраәт (уку) китаплары өчен йә тәрҗемә, йә оригиналь бик күп шигырьләр, әфсанәләр (әкиятләр), хикәяләр мәйданга китерәдер. Ул бу бүлек шигырьләрен үзенең ана теленә һимнә (гимн) язу белән башлыйдыр. Аны иң кечкенә балалар аңларлык дәрәҗәдә садә (гади) итеп эшләп, безгә телемезнең кадере-хөрмәте хакында моңарчы тиңе күрелмәгән һимнә башлыйдыр», – дип яза Г. Исхакый [Исхакый, 1938; Ил йолдызы, 2006, б. 55].

Тарихчы, язучы Сәгадәт Чагатай (1907–1989) фикеренчә, «Балалар Тукайның иң якын дуслары, алар аның төсле керсез, сафлар, алар аның төсле җаннан, чын күңелдән “Туган тел”не сөйлиләр...» [Чагатай, 1938; Ил йолдызы, 2006, б. 67].

1918 елның азагында Саратов өлкәсе Хвалын өязе мәгариф бүлегенең бер районы каршындагы укытучылар әзерләү курсларында укучылар катнашы белән Тукай турында уздырылган әдәби кичә «Туган тел» шигырен хор белән җырлап ачыла. Кичәдә хазир булган (катнашкан) өяз мәгариф шөгъбәсеннән килгән рус инструкторы, өязгә кайткач: «Телне аңламасам да, халыкның күренешеннән бик сөеп тыңлавын сиздем», – дип ачыклап искә ала [Мәхмүд, 2015, б. 555].

Г. Тукайның «Туган тел» шигыре сугыш елларында да һәрвакыт халыкны берләштереп тора. «Ватан өчен» газетасының 1943 елның 7 августында чыккан 67 нче санында «Туган тел аркылы» дип аталган зур мәкалә басылган. Эпиграф итеп «Туган тел» шигыренең беренче куплеты алынган. Эчтәлектә татар сугышчыларын җиңүгә Г. Тукай шигырьләре рухландыруы күрсәтелә, туган телнең көче һәм әһәмияте ассызыклана. «Безнең туган телебез фронтта да (...) горур яңгырый. Ул безне кискен сугышларга, ярсулы атакаларга алып керә» [Яруллин, 1943], – дип яза өлкән лейтенант Д. Яруллин.

Шул ук елларда «Туган тел» әсәре күренекле рус шагыйре, тәрҗемәче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Семен Липкин (1911-2003) тәрҗемәсендә рус телендә дә киң тарала [Тукай, 1948, б. 10]:

Родной язык

Родной язык, святой язык, отца и матери язык,  
Как ты прекрасен! Для меня огромный мир в тебе возник.  
Качая колыбель, тебя мне в песне открывала мать,  
А сказки бабушки потом я научился понимать.  
Родной язык, родной язык, с тобою смело шел я вдаль,  
Ты радость возвышал мою, ты просветлял мою печаль.

Ләкин, кызганычка каршы, рус телендә тәрҗемәләрдә әсәрнең 3 кенә куплеты тәкъдим ителә, соңгы дүртьюллыгы төшереп калдырыла.

«Семен Липкин узган гасырның илленче еллары ахырында казакъ әдәбияты классигы Мохтар Ауэзов белән очраша. Әңгәмә барышында Габдулла Тукай әсәрләре, аерым әйткәндә, "Туган тел" шигыре искә алына. Дәһри идеология куштаннарының даһи шагыйрь мирасына оятсызларча тыкшынуы кысуларны хәтсез кичергән Мохтар Ауэзовны тәмам чыгырыннан чыгара. «Нишлисез, мин ул шигырьне балачагымнан ук яттан беләм, – дип ачуын кабарта әдип, Семен Липкинны гаепле санагандай. – Нигә соңгы ике юлны кисәсез?» [Мансуров, 2016].

Ләкин шул ук вакытта шигырьнең соңгы юллары даими рәвештә төшереп калдырылган дип әйтергә җирлек юк. Мәсәлән, Мөхәммәд Садри төзеп бастырган 1969 елдагы Г. Тукай шигырьләре җыентыгында шигырь С. Липкин тәрҗемәсендә тулысынча бирелгән. Соңгы юллары түбәндәгечә яңгырый:

Родной язык, с тобой вдвоем я в первый раз молил творца:  
«О боже, мать мою прости, прости меня, прости отца»  
[Тукай, 1969, б. 222].

Шигырьнең соңгы юлларының «Халык әдәбияты» тексты эчендә урнаштырылган Ф. Вәлиева тәрҗемәсе дә игътибарга лаек:

О родной язык! На этом языке совершена  
Самая первая молитва моя:

Помилуй, просил, меня,
Отца и мать, господи [Тукай, 1961, б. 20].

Әйтергә кирәк, бүгенге көндә кайбер әдәбиятчыларның «Совет чорында «Туган тел» шигыренең соңгы юллары басылмады» дип әйтүләре еш очраса да, Г. Тукайның ХХ гасырда чыккан татар телендәге барлык күптомлы басмаларында тулысынча тәкъдим ителүен күрәбез. Кайберләренә күзәтү ясыйк.

«Туган тел» Фатих Сәйфи-Казанлы тарафыннан төзелгән Г. Тукай әсәрләре өчтомлыгының 2 нче томында (1930) урнаштырыла. Авыр сугыш елларында Якуб Агишев һәм Хәй Хисмәтуллин тарафыннан төзелгән Г. Тукай әсәрләренең академик басмасының беренче томында (1943) «Туган тел» шигыре «Балалар өчен шигырьләр» бүлегендә урын ала. Биредә шигырь *Әй туган тел, әй матур тел, әткәм, әнкәмнең теле!* [Тукай, 1943, б. 353] дип башлана. Аңлатмаларда исә 1909 елда язылуы искәртелә.

1955–1956 елларда чыккан Г. Тукай әсәрләренең дүрттомлыгында «Шигырь 1910 һәм 1911 елларда, “Балалар күңеле” исемле җыентыкта басылган» [Тукай, 1955, б. 352], – дигән аңлатма бирелә.

1985 елда галим Рашат Гайнанов (1925–1990) төзегән Г. Тукай әсәрләренең биштомлыгында шигырь 1909 елда язылган дип күрсәтелә һәм кулланылыш даирәсе ачыклана: «Туган тел» шигырен мәктәп-мәдрәсәләрдә уку елы башлану алдыннан, уку елы тәмамланган вакытта, шулай ук бәйрәм кичә һәм иртәләрендә балалар хор белән укый яисә көйли-җырлый торган булганнар [Тукай, 1985, б. 354].

Г. Тукайның балалар өчен дип язылган «Туган тел» шигыре бүгенге көндә татар халкының бердәмлек символына, милли гимнына әверелде. Ул Җир шарының татар халкы яшәгән һәр почмагында яңгырый, «Туган тел» исемен йөрткән милли оешмалар эшли. Г. Тукай әдәби музеенда 2019 елда «Туган тел» шигыренең язылуына 110 ел тулуга багышлап «Туган тел» күргәзмәсе оештырылды, ел саен 21 февральдә – Халыкара туган тел һәм 26 апрельдә – Г. Тукайның туган көннәрендә «Туган тел бәйрәме» уздырыла. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне дә Туган тел көне буларак бәйрәм ителә:

Котлы булсын, ил рухланып
Бәйрәм иткән Тукай көне;
Сакла, татар, язларда ул
Мәңгелеккә туган көнең –
Туган телнең туган көне!
(Шәүкәт Галиев. Туган телнең туган көне)

**Әдәбият**

*Әмиров М.* Күз алдында тора // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен. 2015. Б. 700–702.

*Әхмәди Г.* Ерак Шәрыкта Тукаевны искә төшерү // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен. 2015. Б. 231–233.

*Бәкер К.* «Балалар күңеле» җыентыгына бәяләмә // Йолдыз. 1910. 19 гыйнвар.

*Бәкер К.* Тукай Петербургта // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен. 2015. Б. 632–663.

Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре // Ил. 1915. 25 гыйнвар.

Игълан // Кояш. 1915. 16 апрель.

Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз. З.Г. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 190 б.

*Исхакый Г.* Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә // Яңа милли юл. 1938. № 4(121).

*Мансуров З.* «Туган тел»гә һәйкәл кирәк // Мәдәни җомга. 2016. 19 май.

Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларны теркәү дәфтәре // ТР Милли архивы. 420 ф. 1 тасв.

Мәктәп балаларына махсус шигырьләр / җыючысы М. әл-Мәрҗани. Оренбург. 1912.

*Мәхмүд Т.* Габдулла Тукай турында истәлек // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен. 2015. Б. 543–557.

*Миңнуллин Җ.С.* Шәрык клубы. Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2013. 96 б.

*Мөхәммәдова Г.* Балачак истәлеге // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1. т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 723.

*Хуҗа Н.* Тукаевның балалар галәменә тәэсире // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 79–81.

*Тукай Г.* Академик басма: ике томда. 1 том / төз.: Я. Агишев, Х. Хисмәтуллин. Казан: Госиздат. 1943. 472 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда. 2 т. / төз. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 402 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: дүрт томда. 2 т. / төз.: Х. Хисмәтуллин, Я. Агишев. Казан: Таткнигоиздат. 1955. 376 б.

*Тукай Г.* Избранное: в 2-х томах. Т. 2. Казань: Татар. кн. изд-во, 1961. 292 с.

*Тукай Г.* Избранное: стихи, поэмы, сказки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 420 с.

*Тукай Г.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: «Сабах» китапханәсе, 1911. 144 б.

*Тукай Г.* Стихотворения / перевод С. Липкина. М.-Л., 1948. 48 с.

*Тукай Г.* Уянгач беренче эшем // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 4 т.: Проза, публицистика (1907–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. 2015. Б. 259–263.

*Чагатай С.* Габдулла Тукай: үлүенә 25 ел булу уңае берлә // Яңа милли юл. 1938. № 34.

*Шәрәф Ш.* Габдулла Тукай хакында бәгъзы хатирәләрем (Вафатына биш ел тулу мөнәсәбәте илә искә төшерү) // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 287–292.

*Яруллин Д.* Туган тел аркылы // Ватан өчен. 1943. 7 август.

***Төхфәтова Гүзәл Фәрдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Тукай әдәби музее мөдире*

УДК 82-32

***Э.Р. Нәбиуллина***

# Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» ХИКӘЯСЕНДӘ КӨНКҮРЕШ ДЕТАЛЬЛӘРЕ

Статья посвящена изучению бытовых деталей в рассказе Г. Исхакый, где писатель показывает татарскую повседневность без приукрас, такой, какая она есть на самом деле. Он описывает знакомые всем детали, затрагивает деликатные моменты из жизни народа. На примерах показана роль мелких бытовых деталей в изображении повседневной жизни главного героя.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, повседневность, бытовая деталь, татарская литература, теория литературы.

This article is devoted to the study of household items in the story of G. Iskhaky, where the writer shows Tatar daily life without embellishments, as it really is. He describes the details familiar to all, touches upon delicate moments in the life of the people. The examples show the role of small household items in the image of the daily life of the main character.

**Keywords:** G. Iskhaki, daily life, theory of literature, tatar literature, household item.

Гаяз Исхакыйның роман, повесть, хикәяләре татар прозасы тарихының алыштыргысыз әһәмиятле бер өлешен тәшкил итә. Аның әсәрләреннән башка «XX гасыр башы татар тормышын, аның авылын, шәһәрен, мәдрәсәсен, шәкерт һәм хәлфәләрен, мулла һәм хәзрәтләрен, тагын бик күп якларын тулы күз алдына китерү мөмкин түгел» [Гайнанова, 1997, б. 10]. Әдип халыкның тормышын, көнкүрешен оста күзәтә һәм аны җентекләп тасвирлауга зур игътибар бирә.

Мәсәлән, 1910 елда Төркиядә укыган Татар әдәбияты турындагы докладын ул иң элек нәкъ менә Казан татарларының яшәү шартларына, һавасына, сәяси вәзгыятькә бәйле тормыш-көнкүреше белән таныштырудан башлый: «*Суык йортыбыздан башка киемнәремезнең дә, ашаячак һәм эчәчәгебезнең дә ныклы, көчле, туклыклы булуы кирәктер. Һәр шималь төркиенең аты, сыеры, куе (сарыгы) булуы зарури. Соңрак бу хайванны симертү, асрау да кирәктер. Боларны булдыру өчен эшләргә һәм дә бик күп эшләргә тиеш буламыз... Шималь төркиләренең иҗтимагый хәятлары руслардан аерым вә үзүзенә җитәрлек иде. Бу җәһәттән гадәт буенча рус диңгезе күзәтүе эчендә калган бер утрау кебек иде. Казан татарлары мөстәкыйль бер тормыш белән яшиләр иде*» [Исхакый, 2005, т. 6, б. 191]. Ягъни Исхакый көндәлек тормыш, яшәү шартларын аерым бер кешенең генә түгел, ә, гомумән, халыкның язмышына, аның мәдәниятенә, сәнгатенә; холкы һәм уйлары формалашуга тәэсир итә торган мөһим фактор буларак кабул итә. Әлеге үзенчәлекләрне даими ассызыкларга, башка җәмгыятьләргә дә җиткерергә кирәк дип таба.

XX–XXI гасырлар чигендә фәлсәфә, культурология, тарих фәннәрендә көндәлек тормышны өйрәнүгә яңача караш барлыкка килә. Әдәбият белеме кысаларында да әлеге төшенчәгә соңгы елларда игътибар арта. Рус, чит ил әдәбиятын өйрәнүдә «*повседневность*» (көндәлек тормыш) термины уңышлы гына әйләнешкә кереп китте. Бу өлкәдә Т.А. Никонова, И.А. Манкевич, Т.Д. Венедиктова, Н.Н. Козлова, И.В. Саморукова, Т.Г. Струкова һ.б. рус галимнәренең тикшеренүләре шактый. Татар әдәбияты әсәрләренә дә көндәлек тормыш сурәтләнү, аның мәгънә төрлелеге, үсеш-үзгәрешенә яңа күзлектән карау таләп итеlә. Бу уңайдан Гаяз Исхакый иҗаты аеруча игътибарга лаек, чөнки ул, үз чорының башка иҗатчыларыннан аермалы буларак, әсәрләрендә реаль тормышны, уйдырмалардан арындырып, ничек бар, шулай сурәтли.

Исхакый көнкүреш детальләргә аеруча игътибарлы: «Әдип беренчеләрдән булып татарның көндәлек тормышын артык бизәүләрдән азат итеп, хөкем чыгармыйча, үгет-нәсыйхәтсез генә сурәтли. Ул еш кына социаль-көнкүреш тематикаларга мөрәҗәгать итә, һәркемгә таныш детальләрне, халык тормышының иң четерекле мәсьәләләрен сурәтли» [Габдрафикова].

Гаяз Исхакыйга күзәтүчәнлек хас, иҗаты аша ул үзен халыкның көнкүреш дөньясын өйрәнүче галим буларак та күрсәтә. «Мулла бабай», «Кәләпүшче кыз», «Зиндан», «Зөләйха» – бу әсәрләрнең һәрберсе татар яшәешенең мөһим сәхифәләрен тәшкил итә. Әлеге исемлекне лаеклы рәвештә «Сөннәтче бабай» хикәясе дәвам итә. Ул 1911 елда язылып, 1912 елда Казанда басыла. Шушы чорда Г. Исхакый М. Горький белән элемтәдә тора һәм үзенең берничә әсәрен, шул исәптән әлеге хикәяне дә, русчага тәрҗемәдә бастыруга ирешә[1].

«Сөннәтче бабай» хикәясенең сюжеты гади. Үзенең кәсебен яшәү мәгънәсе итеп таныган сөннәтче Корбанколый картның озак еллар бергә гомер кичергән хатыны Гөлйөзем әби вафат була. Картның моңа кадәр җай гына барган тормышы кинәт туктап кала, яшәү кыенлаша. Сөннәтче бабай үзенә урын таба алмый һәм яңадан өйләнергә, күнегелгән тормышына әйләнеп кайтырга тели. Тик аның «яңа» карчыгы Гөлйөзем әбигә капма-каршы холыклы була. Аның сөннәт пәкесе белән бәрәңге чистартып утыруын күреп, хурлыкка түзә алмыйча, Корбанколый карт тиз арада дөнья куя.

Беренче карашка әсәр милли һәм дини йолалар, гореф-гадәтләр, аларны саклау турында кебек. Г. Исхакый иҗатын өйрәнгән Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Л. Гайнанова, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин кебек татар галимнәре, әдәбият белгечләре аны шулай дип тәкъдим итә һәм әсәргә шушы күзлектән чыгып бәя бирә. Чыннан да хикәядә төп геройның көндәлек тормышындагы вакыйгалар (кунакка алу, көнкүреш мәшәкатьләре, аш әзерләү, сөннәткә утырту кәсебе, яучылау, әрвахлар

---

[1] Әсәр «Ежемесячник» журналының 1916 елгы 3–4 нче саннарында рус телендә дөнья күрә.

рухына дога уку, кешене бакыйлыкка озату һ.б. йолалар) мулдан сурәтләнә. Сөннәтче бабай образы аша Гаяз Исхакый XIX гасыр азагы – XX гасыр башы татар авылын, аның тормышын, көнкүрешен, төрлегеген күрсәтә. Татар авылының гына түгел, ә татар дөньясының тулы картинасын ачып бирә: «*Көннәр кыскара башлап, кичләр суыгая башлагач, килennәр киндер урыннарыны чормадан төшереп кора башлагач, кызлар киергеләрене киереп, балтыр чүпрәкләр челтәрли, якалар чигә башлагач, Сөннәтче бабайларда да хәл үзгәрә, анларның өйләре дә әллә нинди зур эшкә хәзерләнә башлый иде. Шул көн якынлашуы сизелә башлагач та, Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрене юа, самавырны тагы көзге кеби иттереп ачып куя, шул көнгә дип җәйли җыйган каймагыннан гөбе яза иде*». Халык нинди тәртипләр белән яшәгән, нәрсәләргә ышанган, нинди йолаларны кадерләгән – барысы әнә шушы бер хикәягә тупланган.

Әсәр көнкүреш детальләргә гаҗәеп бай. Һәр детальнең үз урыны бар: *...кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самавыр кую Гөлйөзем әбинең эше булган кеби, миләшкә су сибү, йортны себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Онытканмын икән әле, өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. Ул һәр көнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атна кич ком берлән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларыны ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур белән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде...* Аларны санап кына китү Г. Исхакый өчен бик гади бурыч булыр иде. Шушы детальләрнең һәрберсен тәфсилле карап, яңадан бербөтенгә җыйганда, автор укучыга җиткерергә теләгән яңа мәгънәләр ачыла.

*Әдәби деталь* дигәндә, без иң аз сурәтләнгән, тәэсир көченә ия әдәби нечкәлек: пейзаж, портретның бер өлешен, аерым әйбер, хәрәкәт яки психологик адымны күз алдында тотабыз. Деталь әдәби әсәрдә эмоциональ-мәгънәви көчкә ия. Аларны күпләп куллану, санап бару ярдәмендә язучы аерым бер образны күз алдына китереп бастыра. Эстетик вазифа белән беррәттән, еш кына җентекле детальләр мәгълүмат бирү вазифасын башкара. Ә кайчакта деталь символик мәгънә дә ала [Әдәбият белеме, б. 45]. Әдәби әсәрләрдә деталь көндәлек тормышның бер өлеше генә түгел, ә тулы бер чорны, мәдәниятне, халыкларны үз эченә җыйган күрсәткече дә булырга мөмкин.

Хикәянең төп героен – Сөннәтче бабайны авылда һәркем белә. Гадәттә кеше үзен белә башлаганнан бирле аны уратып алган иң якын кешеләрен хәтерли: әти-әнисен, бертуганнарын, якын кардәшләрен һәм... Сөннәтче бабайны. Кемдер аны олы хөрмәт белән искә ала, берәүләр аны балаларын елаудан туктатканда өркетү өчен файдалана, кыз балалар курчак уйнаганда да аерым бер курчакны Сөннәтче бабай дип тоталар, ягъни һәр кеше тормышында аның үз урыны бар. Сөннәтче бабайның яшен белүче, хәтта бу турыда уйланучы да юк, ул һәрвакыт булган һәм булачак кебек. Ягъни халык арасында, халыкның күзаллавында, көндәлек тормыш-көнкүрешендә

аның башкалар белән бүлешми торган аерым бер урыны бар. Кыскасы, Сөннәтче бабай – авыл халкын берләштереп торучы, бар халык өчен уртак кыйммәтләрне үзенә туплаган үзәк образ, йола һәм гореф-гадәтләрнең үзе.

*Ул ике зур холерадан* исән калган*, йорты ике зур утта* янмаган, *илдәге корылык аның арышын саргайтмаган,* ягъни халыкка бетү, юкка чыгу куркынычы янаган вакытта да, Сөннәтче бабай һәм ул саклаган кыйммәтләр ничектер исән калган. Аның *читтән килгән һәрбер шарлатанга* (ягъни чит-ят тәртипләргә) үз хакын белдерү өчен *пәкесе,* шешәгә тутырган *сары черерге* һәм *шәҗәрәсе* бар. Бу өч нәрсә кыйммәтлеге белән югары дәрәҗәдә, алар өчесе дә өйнең иң кадерле урынында торалар. Шунда ук Гөлйөзем әбинең дә кадерле саналган һәфтияге, бөтиләре саклана торган кечкенә сандыгы да бар. Өй җиһазлары күп булмаса да, рухи байлык билгесе булган шушы берничә әйбер аларны да, халыкны да яшәтә. Әлеге детальләргә тулырак тукталып китик.

Сөннәтче бабайны сөннәтче иткән, пәйгамбәрләр заманыннан мирас буларак килә дип ышанып, кадерләп тоткан, изге эшләргә рухландырган, образны ачуда хәлиткеч роль уйнаган детальләрнең берсе – ул, әлбәттә, *сөннәт пәкесе*. Автор пәкене болайрак сурәтли: *...ул бик мөкаддәс иде. Бабай аны да салаватсыз тотмый, аны да күрсәткәндә атасыннан калганыны сөйләп кенә калмаенча, аның да шул буыннардан үтеп, хәзрәти Сәлман Фарсидан килгәненә кадәр барып җитә, аңар хәзрәти Рәсүлнең үз кулы берлән бирүене дә әйтеп куя иде*, шул рәвешле аның әһәмиятен, изгелеген ассызыклый. Сөннәт пәкесе – Корбанколый карт өчен яшәү чыганагы, аның кәсебе, шуның ярдәмендә ул көн күрә.

Сөннәтче бабайның шәҗәрәсе дә *хикмәтле*, анда төрле чорда яшәгән, татар-мөселман тарихында әһәмиятле роль уйнаган шәхесләр: мәсәлән, Кырым ханнары нәселеннән Мулламорад искә алына. Гаяз Исхакый искәрмәсе буенча, Мулламорад – заманында Русиянең уртасына күчеп, гыйлем юлында хезмәт иткән шәхес. Анда Мамай, Аксак Тимер, Хан Гәрәй, хәзрәти Билал... һәм, әлбәттә, Сәлман Фарси исемнәре бар. Бу уйдырма шәҗәрәнең ышанычлы булуына һичкем, хәтта Сөннәтче бабай үзе дә шикләнми. Ул үзен шушы затларның дәвамчысы, бу җирдә бик әһәмиятле вазифа башкаручы итеп тоя. Аның чынбарлыгы шушы детальләргә, шушы инануларына корылган.

Бабайның өй түбәсе дә бик борынгы заманда *авыл тарихын белми торган вакытта* ябылган. Өйдәге барлык детальләр: тәрәзәсе, балчыгы, түбәсе Сөннәтче бабайга охшаган. Аның дөньясы башкалардан үзгә; йорты, бакчасы, каралты-курасы төзек, Гөлйөзем әби белән гармониядә яши, бакчасы, ягъни эшләгән эше уңыш китерә, һәрнәрсә билгеле бер тәртипкә, җайга салынган. Ягъни күп еллар элгәре билгеләнгән яшәү тәртипләре әлегәчә дәвам итә. Татарларда гасырлар дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килергә тиешле

тәртипләр, йолалар бар. Сөннәтче бабай да үзеннән соң әлеге яшәү рәвешен нәсел дәвамчысы булган улына тапшырырга тиеш. Ләкин аның бердәнбер улы патша хезмәтендә үлә. Автор шушы деталь аша буыннар чылбырының өзеләчәгенә, җайга салынган яшәү рәвешенең мәңгелек булмавына ишарә итә. Чөнки кешелек тарихында мәңгелек җәмгыятьләр моңа кадәр дә булмаган һәм хәзер дә юк, һәр нәрсә юкка чыгуга яки үзгәрүгә дучар. Әсәрдә әнә шушы көндәлек тормышның даими үзгәрешсез баруы белән әлеге тәртипләрне җимерүгә китергән көтелмәгән хәлләр, вакыйгалар бер-берсенә каршы куела. Гөлйөзем әбинең үлеме Сөннәтче бабай өчен шушындый җимергеч вакыйга була.

Язучы әсәрдә сүз барган замананың *башка булганлыгын* даими кабатлый: *Замана бозылмаган иде әле, кешеләр ихлас, бер-берсеннән шикләнми иде...* Үткәндәге вакыйгалар, шәхесләр һәрчак шулай матур, идеаллаштырып бирелә. *Ул вакытта җәдиде-кадиме, гәзитемәзите, думасы-бумасы юк; ул вакытта мәктәп, мәдрәсә мәсьәләсе, тел мәсьәләсе, муллалар, яшьләр мәсьәләсе юк иде. Һәр мәсьәләгә хәл кылынган, һәр агымга юл билгеләнгән иде,* дип сурәтли. Әлеге чорны язучы *җәйге җилсез көнне ашъяулык кеби тип-тигез ага торган Идел* белән чагыштыра. Аңа каршы торган *буа* юк, ягъни җәмгыятьтә каршылыклар, альтернатив фикер, теләк, яңалык юк. Чыннан да, еш кына халык арасында үткән заманнар, үткән буын вәкилләре бездән акыллырак, ихласрак, күркәм холыклырак булган дигән күзаллау яшәп килә. Бу һәрвакыт шулай булган. Шулай уйлау кеше күңелендә ниндидер теләк, тормыш итүнең идеал образын тудыра.

Сөннәтче бабайның янә бер кәсебе бар: ул яз айларында мөгез кую, кан алдыру белән дә шөгыльләнә. Ягъни халык алдында ул тагын бер зур миссия башкара, ул – бозылган канны чистартучы. Шул күнегелгән яшәү *агымыны тирескә сөрергә теләгән һавалы җилдән,* яңа гадәтләрдән башны, уйларны гына түгел, ә канны да арындыра: *«Машалла, машалла, хәзрәт, каның бик бозылган икән, кап-кара!» – дип, хәзрәткә сөйли; хәзрәт, шул бозылган каннан котылыр өчен, һаман агыздырганнан-агыздыра бара иде.*

Язучы Сөннәтче бабайны татар авылының, татар көнкүрешенең алыштыргысыз бер үзәге, барлык йолаларны җыеп, аларны яшәтеп торган образ итеп күрсәтә. Аның кайсыдыр сыйфатларыннан көлгәндә дә, үз итеп, яратып кына көлә. Мәсәлән, һәр ел көзгә аяк басканда, Сөннәтче бабай хәзрәт белән абыстайны ашка ала. Килгән кунакларны хуҗалар, гадәттәгечә, нык түбәнчелек белән кунак итәләр: *Бернәрсә дә хәзерли алмадык!* – дия-дия, шурпасын да, бәлешен дә, пешкән үрдәген дә берсе артыннан берсен чыгарып кына торалар, чөнки татарларда кунак сыйлау тәртибе шундый. Хуҗалар түбәнчелек белән генә ризык чыгара, кунаклар тартынып кына сыйлана. Ләкин сүз ара сүз чыгып, *бишенче кат самавырны яңарткannан* соң, аралар якыная, аралашу гадиләшә, Сөннәтче бабай да хәзрәт өчен Корбанколыйга әйләнә.

Алда әйтелгәнчә, Корбанколый бабайның киенү рәвеше, яшәү тәртипләре, каралты-курасы, көндәлек тормышы – барысы да үтә традицион, бер көйгә салынган. Ләкин шушы җайланган тормышны бозып, Гөлйөзем әби авырып китә, Сөннәтче бабайның дөньясы, еллар буе дәвам иткән тәртипләр какшый башлый. Баштарак әлеге хәлне тоткарларга, күнегелгән тормышны янә кайтарырга, карчыкны терелтергә уйлыйлар: аңа яңа туган балаларны *авызландыра торган хөрмә* дә каптыралар, моңа кадәр бар мәсьәләне хәл итәрдәй көчкә ия булган *мәтрүшкәле чәй* дә эчереп карыйлар, кан да алдырырга уйлыйлар, ягъни моңарчы булмаган хәлләрне үзләре өчен гадәти ысуллар белән хәл итәргә тырышалар, ләкин карчыкның хәле җиңеләйми. Таң атканда, Гөлйөзем әби бакыйлыкка күчә. Шул көннән дөнья үзгәрә башлый, әмма Сөннәтче бабай үз тормышының элеккеге тәртибен ничек тә сакларга тели һәм яңадан өйләнә. Ләкин яңа хатынның тәртипләре башка, ул элеккеге хатынга беркайчан да охшамаячак. Ул бу дөньяны башкача кабул итә, Сөннәтче бабайга кадерле булган нәрсәләр аның өчен зур әһәмияткә ия түгел.

Исхакый әлеге әсәрдә көнкүрешнең үзгәрүе, кайсыдыр мәгънәле әйберләрнең, күренешләрнең, ышануларның, тәртипләрнең юкка чыгуы турында яза. Сәбәпләрнең төрле булуын, заманага бәйле рәвештә алардан котылып булмаячагын язучы яхшы аңлый, шуңа күрә «тыныч заманаларда» булган дөньяны, көнкүрешне ничек бар, шулай язып, «фотосурәткә төшереп калдырырга» омтыла.

Әсәрдә карап үтелгән көнкүреш детальләр билгеле бер образ, бу очракта Сөннәтче бабай тормышына гына кагылмый. Ул үз эчендә аерым бер җәмгыятьнең – авыл халкының яшәү рәвешен, аның дөньяга карашын, ышануларын берләштерә. Корбанколый карт үрнәгендә әдип иске яки искергән, үзгәреш таләп иткән яшәү рәвешен яңа шартларга каршы куя, аларны бер вакыйга – Гөлйөзем карчыкның үлеме аша бәрелешкә кертә. Сөннәтче бабай – иске тәртип кешесе, ул башка төрле карашларны (бу очракта яңа хатыны алып килгән яңа тәртипләрне) кабул итми, үзгәреш кичергән дөньяга яраклаша алмый. Димәк, яңа, Гөлйөземсез дөньяда ул үз урынын тапмаячак.

Гаяз Исхакый әсәрен *Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды,* дип тәмамлый. Әлеге хикәядә Сөннәтче бабай һәм аның дөньясы ярдәмендә чорларның алмашынуы күрсәтелә. Бу – 1905 елгы революциядән соңгы үзгәрешләр, аның халыкка тәэсире дип кабул ителә. Автор иске тәртипләрнең, яшәү рәвешенең үзгәрүен табигый күренеш дип таный, шул ук вакытта халык аңында, аның көнкүрешендә булган ышануларның, тәртипләрнең, детальләрнең кыйммәтен ассызыклый: *«Бер ике-өч елдан Сөннәтче бабай йорты урынында тормыш галәмәтеннән бернәрсә дә калмады»,* ләкин каберлекләр өстендә шаулап үсеп утырган ике ак каен үткәндәге дөнья турында хәтерләтеп тора. Үткәндә булганнар: яшәү рәвеше, ышанулар яхшымы, начармы – ул халык тарихы һәм һәркемнең аларны хәтерләргә,

белергә хакы бар. Г. Исхакый көнкүреш детальләр ярдәмендә укучыны әнә шушы идеягә чыгара.

**Әдәбият**

*Ахунов А.* Долгое возвращение (135 лет со дня рождения Г. Исхаки) // Казанский альманах. 2013. № 11. С. 128 –140.

Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

*Габдрафикова Л.* Гаяз Исхаки: шакирдские будни, развод и политическая опала в жизни и творчестве // https://realnoevremya.ru/articles/90645-gayaz-ishaki-zhizn-i-tvorchestvo-do-emigracii (Дата обращения: 1.06.2020)

*Гайнанова Л.* Кереш мәкалә // Исхакый Г. Сөннәтче бабай. Казан: Идел-Пресс, 1997. Б. 3–10.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр, 1998. 464 б.

***Нәбиуллина Эльза Ринат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 82-3

***Р.Ә. Яруллина Йылдырым***

# ТӨРЕК ПРОЗАСЫНДА МИЛЛИ ИДЕАЛ БУЛАРАК ТАТАР КЫЗЛАРЫ
## (Халидә Әдип Адывар романнары үрнәгендә)

Известная турецкая писательница и общественный деятель Халида Адип Адывар в своих трудах критиковала низкий социальный уровень турецких женщин. В ее романах положительными героями выступают сильные, яркие и независимые женские характеры. В данной статье проанализированы романы «Новый туран» и «Татарчык», где главными героями являются татарские девушки, которые представлены как национальный идеал автора. Также опираясь на труды турецких ученых, раскрыты эстетические особенности этих женщин-патриотов и личное мировоззрение писательницы.

**Ключевые слова:** турецкая проза, национальная литература, Халида Адип Адывар, национальный идеал, образ татарской девушки

The famous Turkish writer and public figure Khalida Edip Adyvar in her writings criticized the low social level of Turkish women. In her novels, strong, bright and independent female characters act as positive heroes. This article analyzes the novels «New Turan» and «Tatarchyk», where the main characters are Tatar girls, who are presented as the author’s national ideal. Also based on the works of Turkish scientists, the aesthetic features of these women-patriots and the personal worldview of the writer are revealed.

**Keywords:** Turkish prose, national literature, Khalida Adip Adyvar, national ideal, image of a Tatar girl

Белгәнебезчә, 1839 елда игълан ителгән Тәнзимат яңарыш сәясәте тәэсирендә Госманлы дәүләтенең һәр өлкәсендә, шул исәптән әдәбиятта да реформалар башлана. Көнбатыш Европа әдәбиятының алдынгы идея-эстетик һәм фәлсәфи карашларын якын күргән язучыларның әсәрләрендә феодаль тәртипләр, иске яшәү рәвеше тәнкыйть ителә, Ватан һәм милләт иреге мәсьәләсе белән бергә, хатын-кыз азатлыгы проблемасы да кыю рәвештә көнүзәк мәсьәләләрнең берсенә әйләнә. Хатын-кызларны укыту мәсьәләсен беренчеләрдән булып күтәреп алган Әхмәт Мидхәт башта хатын-кызларга белемнең өйдә ирләр тарафыннан бирелергә тиешлеген белдерә. 1870 елларда дәүләт тарафыннан хатын-кызлар өчен беренче курслар ачылса да, җәмгыять күләмендә бу процесс бик авырлык белән генә бара. Нәмык Кемалның «Гаилә», «Тәрбияи-Нисван» исемле мәкаләләрендә, Шәмсетдин Саминең «Хатыннар» (1879) рисаләсендә, Әхмәт Мидхәтнең барлык әсәрләрендә диярлек җәмгыятьтәге тискәре күренешләр хатын-кызларның наданлыгына бәйләп аңлатыла, бу мәсьәләнең уңай чишелеше зарури икәнлегенә басым ясала. Болар тәэсирендә югары катлау гаиләләре арасында кызларына махсус укытучылар чакыртып дәрес

бирү очраклары күренә башлый. Иң әһәмиятлесе шунда ки, 1890 еллардан башлап, төрек матбугаты битләрендә хатын-кыз язучылар каләм тибрәтә башлый һәм хатыннар өчен «Махсус гәҗит» (1895–1908) исемле тәүге газета чыгарырга рөхсәт алына. Төрек әдәбияты тарихына исеме «беренче романчы хатын-кыз» буларак алтын хәрефләр белән язылган Фатма Алия ханым үзенең әсәрләре һәм газеталардагы мәкаләләре аша төрек хатын-кызларының уянуына зур этәргеч ясый. Төрек-грек сугышы елларында солдат гаиләләренә ярдәм итү максаты белән, 1897 елда Фатма Алия ханым тарафыннан «Нисвани Османия Имдат» (Госманлы хатыннарына ярдәм) җәмгыяте төзелә һәм ул госманлы тарихында беренче рәсми хатын-кыз оешмасы булып теркәлә [Argunşah, 2015, б. 30]. Төрек кызларының һәр өлкәдә тәрәккыяте мәсьәләсе Нигар ханым, Макбулә Леман, Әминә Сәмия кебек европача белем алган язучыларның әсәрләрендә дә көнүзәк мәсьәләләрдән санала. Аеруча 1908 елгы инкыйлабтан соң ил күләмендәге барлык сәяси һәм социаль өлкәләрдә башланган үзгәрешләр тәэсирендә хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсе тагын да кискенләшә. Төрле дәүләт оешмалары тарафыннан гүзәл затларны уянырга, ил күләмендәге вакыйгаларда катнашырга чакырган язмалар матбугатта еш күренә. Хатын-кызларның бер өлеше Балкан дәүләтләре белән дәвам иткән сугыш көннәрендә милләтне коткару һәм яңа фикерле яшьләр тәрбияләү эшендәге җаваплылыкны җитди кабул итә. Төрек миллиятчелек фикере көчәйгән әлеге елларда бу хәрәкәтнең идеологы Зыя Гөкалп хатын-кызларның бу идеологиянең дә иң әһәмиятле бер өлеше булырга тиешлеген ассызыклый [Argunşah, 2015, б. 32]. Гомумән, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы төрек җәмгыятендә дә яңа буын җитештерү һәм яңа тип гаилә моделе тудыру эшендә хатын-кызларның җаваплы булуы күздә тотыла.

Төрек әдәбияты тарихында милли әдәбият дип аталучы чорның (1911–1922) иң күренекле вәкиле – әлбәттә, журналист, укытучы, сәясәтче һәм язучы Халидә Әдип Адывар (1882–1964). Истанбул шәһәрендәге Америка кызлар гимназиясен тәмамлагач, ул Балкан сугышы елларында госпитальләрдә эшли, соңыннан укытучы, тикшерүче-методист хезмәтен башкара. Кызларны укыту һәм җәмгыять эшенә тарту максаты белән, 1909 елда «Теали-и Нисван» (Хатыннарны күтәрү) исемле оешма төзи. Азатлык сугышында катнаша, Мостафа Кемал Ататөрек белән якыннан аралаша. 1911 елда Зыя Гөкалп, Йосыф Акчура, Әхмәт Агаоглы һ.б. кебек танылган миллиятче зыялылар тарафыннан төзелгән «Төрек учаклары»нда әгъза булып тора, «Төрек Йорты» журналында хатын-кыз хокукларын яклаган күпсанлы мәкаләләре басыла [Yeni Türk edebiyatı, 2009, б. 227].

Халидә Әдип Адывар романнарының төп геройлары – укымышлы һәм көчле характерлы яңа тип хатын-кызлар. Сугышларда, илдәге сәяси алмашынулар эчендә актив катнашкан, митингларда ялкынлы чыгышлар ясаган язучы, башыннан кичкәннәрен һәм киләчәк белән бәйле эстетик фикерләрен әсәр героиняларының язмышында

чагылдыра. «Хандан» романында Хандан, «Яңа Туран»да Кая, «Татарчык»та Лалә, «Уттан күлмәк»тә Гайшә кебек бер-берсен кабатламый торган гүзәл затлар ил күләмендәге вакыйгалар фонында сурәтләнә һәм ул чорның идеаль хатын-кызлары галереясын тәшкил итә. Төрек укучысына үрнәк итеп сурәтләнгән бу көрәшче кызлар арасында икесенең татар милләтеннән булуы бездә аеруча кызыксыну уятты. Һәм «Яңа Туран» белән «Татарчык» романнарына күзәтү ясау теләге туды.

«Яңа Туран» әсәре 1913 елда госманлы дәүләтенең соңгы елларына таба – Балканнар белән сугыш башланганчы басыла. Романда Халидә Әдип Адывар таркалуга йөз тоткан Госманлы дәүләтен саклап һәм төрек милләтен коткарып калу юллары турында уйлана. Һәм үзенең сәяси фикерләренә якын килә торган проектны – Анадолу җирлегендә Туран дәүләтен кору моделен тәкъдим итә. Романда төркичелек агымына һәм заманча ислам диненә нигезләнгән яңа Төркиянең егерме елдан соңгы хыялый хәле тудырыла. Төрек галимнәреннән Тюркан Гөзүток фикеренчә, Халидә Әдип Адывар бу чор миллиятчелек бәхәсләрендә Йосыф Акчура идеяләренә өстенлек бирә һәм Яңа Туран утопиясен аның фикеренә таянып «төзи»: Анадолу җирлегендә яшәүче төрле милләт халыкларын – төрек, гарәп, әрмән, рум, көрт, лаз һ.б.ны үз эченә алган һәм уртак мәнфәгатъ тирәсендә берләшкән федераль дәүләт моделе итеп тәкъдим итә [Gözütok, 2010, б. 415–417]. Шул рәвешле, язучы узган гасырның унынчы елларында төрек җәмгыятендә яңа гына бөреләнеп килүче төркичелек агымы яссылыгында яңа чор герое, милли тарих, милли мәдәният, милли география кебек фикерләрне кыю рәвештә күтәреп һәм яклап чыга.

Әсәрдәге бөтен вакыйгалар һәм геройлар Яңа Госманлы партиясе җитәкчесе Хәмди пашаның туганы, сәясәт белгече Асым исемле егет күзлегеннән аңлатыла һәм бәяләнә. Романның буеннан-буена ике сәяси фирканең – Төрек миллиятчелеге фикерен яклаган «Иттихак һәм Теракки» (Берлек һәм прогресс) партиясе белән ватан төшенчәсенә нигезләнгән Яңа Госманлы партиясенең тоткан юлы, сәяси программасы чагыштырыла. Асым үзләренең көндәше – Яңа Туран лидеры Огузны һәм аның тарафдарларын никадәр генә тискәре яктан бәяләргә тырышса да, алар тоткан юлны, аеруча Каяның заманча кыю адымнарын күп очракта соклану хисләре аша яктыртырга мәҗбүр.

Яңа Туран дәүләтенең идеологы – Бурса шәһәрендәге татар мәхәлләсендә үскән, яңача белем һәм тәрбия алган Огуз исемле зыялы егет. Автор героеның килеш-килбәтен тасвирлауга әһәмият бирә: Огуз озын буйлы, киң җилкәле, эре сөякле, чал чәчле, кысык һәм тирән яшел күзле, үз фикерендә нык торучы, гайрәтле. Гөзүток фикеренә күрә, Халидә Әдип Адывар бары тик фикер яссылыгыннан түгел, портрет ноктасыннан да Огуз образына прототип итеп Йосыф Акчураны алган [Gözütok, 2010, б. 417]. Йосыф Акчура кебек, Огуз да Яңа Төркияне бары тик төрекләрдән генә оешкан дәүләт итеп күрми, ул Төркия җирлегендә яшәүче «гарәпләрне, әрмәннәрне, румнар-

ны, көртләрне, барысын да чакырам һәм һәр кеше өчен бу юлның иң дөрес юл булуын саныйм» [Edip Adıvar, 2018, б.34], ди. Әсәрендә Кыпчак тармагыннан булган татар егетенә Огуз исемен бирүе аша, Халидә Әдип Адывар татарларның һәм төрекләрнең бер тамырдан килүенә, бер атаның балалары булуына ишарә итә.

Романның соңына таба яралы Огуз үзенең гаиләсе – кечкенәдән этисез калуы, татар милләтеннән булган әнисенең бик тырыш, пөхтә һәм гыйлемгә һәвәсле, аеруча кызлар өчен мәктәпләр ачылырга тиешлеге фикерен яклаучыларның берсе булуы турында сөйли. Аның сөйләменнән укытучылык һөнәренең бу татар гаиләсендә буыннан-буынга күчеп килүе дә аңлашыла.

Икенче әһәмиятле герой – Огузның туганнан-туган тиешлесе Кая исемле (үз исеме Самия) кыз. Язучы үзенең идеясен укучыга тагын да тәэсирлерәк җиткерүдә янә татар төркиләреннән булган үзенчәлекле идеалист кызны сайлый. Үзенә тәхәллүс итеп сайлаган Кая (Кыя исеме күк) – каты һәм нык холыклы кыз ул. Кая үзе ышанган кыйммәтләрнең һәм идеяләрнең Яңа Туран партиясе тарафыннан тормышка ашырылачагына ышана, һич тә шикләнмичә, үзен бу юлда корбан итәргә әзер зат итеп күрсәтә. Әнисен бик кечкенәдән үк югалту сәбәпле, Кая кырыс холыклы этисе тарафыннан тәрбияләнә. Әтисе Лотфи бәй кызының европача белем һәм тәрбия алуына зур әһәмият бирә. Шул сәбәпле ул әсәрдә хатын-кызларга хас булган йомшаклык һәм нәфислек кебек сыйфатлардан ерак торучы каты табигатьле кыз итеп сурәтләнә. Халидә Әдип Адывар, ул чордагы сәяси карашлары күзлегеннән, үзен җәмгыять эшенә багышлаган яңа тип хатын-кызларны бөтенләй башка форматта – һәр яктан ирләр кебек булган затлар итеп күз алдына бастыра. Үз яшенә күрә күпкә акыллы һәм җитди характерлы, йөзеннән һәм зәңгәр күзләреннән нур балкып торган Кая, үзенең эшчәнлеге белән төрекләр арасында популярлык казана: башта Эрзурум шәһәрендәге Яңа Туран мәктәбендә танылa башлый, аннары Истанбулга килеп, бу юлда яңа мәктәпләр ача, госпитальләрдәге яралы сугышчыларның хәле белән гел кызыксына, җомга мәктәпләрен ачтыруга зур көч куя. Язучы баш героинясы аша Яңа Туран хатын-кызлары кия торган киемнәргә дә әһәмият бирә: «аркаларында борынгы татар төркиләрен хәтерләтүче соры озын пальто, башларында ак йомшак яулык, аякларында гади, калын аяк киеме, кулларында эш өчен капчыклар» [Edip Adıvar, 2018, б. 18]. Каяның киемнәрен берничә җирдә телгә алу аша Халидә Әдип Адывар үз идеалын заманча кыйммәтләр белән «коралландыра»: купшы киенергә яраткан госманлы хатыны урынына яңа дәүләттә гади киенгән, ләкин үзен яңа фикерләр белән бизәгән акыллы хатын-кызларны күрергә тели. Тагын да төгәлрәге, Госманлы чорындагы купшы, исрафчы өй ханымнарына капма-каршы итеп, Кая образында ирләр белән тигез хокукка ия, алдынгы белем алган, яңа тормыш өчен үзен аямаган көчле характерлы яңа тип хатын-кыз образын тудыра.

Язучы үзенең эстетик идеалы Каяны нечкә хисләрдән азат итеп тасвирлый, дидек. Героиняның Огузга булган мәхәббәте тора-бара үзгәреш кичерә: шәхси сөю хисе олы идеалга – милләтенә булган мәхәббәт хисенә алышына. Автор чын мәхәббәт һәм чын бәхет төшенчәләре турындагы фикерен дә үзенең идеалы Кая авызыннан җиткерә: «Озын, мәшәкатьле, ялгыз тормыш юлымда бердәнбер мәхәббәт бар иде: ул – Яңа Туран төшен (хыялын) минем белән күреп, минем белән бергә тормышта бер ишен тудырырга тырышкан Огуз! Фәкать Огуз һәм мин, төшебез һәм максатыбызны яратканга, төшебез һәм максатыбыз өчен яшәгәнгә, бер-беребезне яратабыз дип санадык. Бөтен шәхси бәхетебезне анда таптык» [Edip Adıvar, 2018, б. 38], ди. Төрек романында да татар әдәбиятындагы кебек, «олы максатка хезмәт итүнең бу юлдагы кешедән көрәш рухы һәм фидакярлек таләп итүе» ассызыклана [Zaripova Çetin, 2006, б. 145].

Кая – милли идеяләр өчен үзен корбан итәргә әзер зат. Митингларда ялкынлы чыгыш ясау сәбәпле кулга алынган Огузны төрмәдән азат иттерү өчен, ул үзеннән шактый олы яшьтәге кешенең – Яңа Госманлы партиясе җитәкчесе Хәмди пашаның кияүгә чыгу тәкъдимен кабул итә. Хәмди паша җәмәгать эшләрендә бик актив һәм күпләр өчен үрнәк булган Каяга өйләнеп, Яңа Туранчыларны, үзенең көндәше Огузны көчсезләндерергә тели. Фикердәшләреннән, «бөтен яшәешенең сәбәбе һәм максаты булган Яңа Туран»нан аерылуны Кая бик авыр кичерә. Огузның эшчәнлеген һәм сәясәттәге уңышларын газеталар аша гел күзәтеп бара, туктаусыз төркичелек фикерләре белән сугарылган китаплар укый. Берара үзен мохтаҗ гаиләләргә кием тегеп ярдәм итү шөгыле белән юатса да, бик яраткан фиркасеннән ерак тору аның сәламәтлеген какшата. Каяның үз эченә ябылуы һәм авырый башлавы Хәмди бәйне сәясәт һәм дәүләт эшләреннән еракլаштыра, акрынлап аның көчсезләнүенә юл ача башлый. Горур татар кызының күңелен яулап алу өчен, Хәмди бәй хәтта көндәшенең бер тәкъдимен кабул итәргә мәҗбүр була: мәҗлестә Огузның хатыннарны укыту мәсьәләсе тәкъдименең кабул ителүе өчен тавыш бирә. Романның соңында Огузның үтерелү хәбәрен алган Кая, милли идеалга хезмәтен дәвам итү өчен, Хәмди бәйнең затлы тормышын горур рәвештә ташлап чыгып китә.

Гомумән, бу романда Кая образы үрнәгендә төрек язучысы «Яңа Туран хатын-кызы» моделен тудыра: җәмгыятьнең гади киенгән, горур, үзен милләткә хезмәткә багышлаган, аеруча белем бирү өлкәсендә уңышлы адымнар ясаган, «ирләр кебек» кыю һәм заманча фикерле хатын-кызларга ихтыяҗы барлыгын белдерә. Халидә Әдип Адывар, «хатыннарның тигез хокукларга ия булу теләкләренең һәм җәмгыятьнең әһәмиятле бер өлеше булу юлындагы тырышлыкларының бары тик бу гүзәл затларның сүз хокукына ия булган очракта гына тормышка ашачагына ышана» [Argunşah, 2015, б. 48].

1926 елда Англиядә сөргендә чагында язган мемуарында бу әсәре турында Халидә Әдип Адывар түбәндәгечә яза: «Китап сәяси һәм

милли утопияне аңлата, ләкин утопия булса да, тормышка ашу мөмкинлеге дә юк түгел. Шулай да икътидарда тагын да камил Берлек һәм Тәрәккыят партиясе булган яңа бер Төркияне өмет итәм: хатыннары тавыш бирү хокукына ия, аларның сүзе үтә һәм чын йөрәктән тырыша торган Төркия. Гади һәм бизәксез тормышлары госманлының зарарлы люкс эчендәге яшәү рәвешеннән бөтенләй башка; госманлының бөек һәм нәсел җепләрен югалткан мәдәнияте тарафыннан уртага чыккан паразит бер сыйныф хатыннарының тормышыннан да бөтенләй башка (Төркия)» [Edip Adıvar, 1996, б. 186].

«Яңа Туран» әсәрендәге Кая образы кебек башка бер кыю һәм идеалист татар кызы идеалы язучының 1939 елда иҗат ителгән «Татарчык» исемле романында да баш герой итеп алынган. Бу әсәрендә дә Халидә Әдип Адывар, баш героинясының гаиләсенә, аеруча ата кешенең сыйфатларын тулырак ачуга аерым игътибар бирә. Истанбул янында диңгез буендагы бер авылда, башкалардан аерымрак гомер сөргән татар Госман бәй бик тыйнак, диндар, тәртипле һәм мохтаҗларга һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торган бер үрнәк ата моделе итеп тасвирлана. Азатлык сугышы елларындагы батырлыклары өчен, аңа дәүләт тарафыннан пенсия бирелсә дә, моны һичбер вакыт телгә алмый ул, һич мактанмый. Ләкин авыл халкы бу гаиләне нигәдер үз итеп бетерми һәм язучы моның берничә сәбәбен ачыклый. Беренчесе – Госман бәй «әйләнә-тирәсендәгеләрнең дә әхлаклы булуын тели. Шунлыктан якындагыларны чын мәгънәсендә туйдыра торган, гыйсъян итәчәк дәрәҗәдә дөрес мөнәсәбәттә була иде» [Edip Adıvar, 2018, б. 54], дип яза автор. Тагын да җитдирәк сәбәп исә – авыл кешеләренең төрек теленә хөрмәте. Әсәрдән аңлашылганча, төрекчә сөйләшкәндә ялгышлары өчен дә Госман бәйне истанбуллылар яратып бетерми икән (җирле кешеләр ул чорда Истанбул төрекчәсенең камил кулланылуына бик тә әһәмият иткәннәр). Татар Госман бәйнең тормыш юлдашы булган Лалезар ханым исә – бик матур һәм тыйнак, ләкин авыл кешеләре белән аралашудан читенсенә, ояла торган ханымнарның берсе. Бу пар үрнәгендә язучы «ирләр культы көчле булган госманлы чоры гаиләсендә һәм җәмгыятендә хатын-кызның пассив» [Kaya, 2014, б. 54] булып, арткы планда торуын күрсәтә.

Инглиз телен белүче һәм европаның алдынгы фикерләренә теләктәшлек күрсәтүче татар Госман бәй бердәнбер кызы Лаләне заманча фикерләр тәэсирендә тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. Нәтиҗәдә «җөмһүрият кызы» Ләлә, «госманлы ханымы» әнисеннән аермалы буларак, гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә үз сүзен әйтә алучы яңа тип хатын-кыз буларак формалаша. Инглиз теле укытучысы һөнәрен сайлаган Ләлә дә, идеалист бер кыз буларак, яшәү фәлсәфәсен җәмгыятьне һәм милләтне алга җибәрүдә күрә. Төрек тормышындагы искелекне бетереп, европача мәдәни яшәү рәвешен урнаштыру өчен хезмәт итүне, халыкка юл күрсәтүне үзмаксат итеп куя. Төрек җәмгыятенең мәдәниләшүен Европа фикерләрне кабул итүдә күргән Халидә Әдип

Адыварның героинясын галим Мөхәррәм Кая «ирекле җирле ориенталист» итеп саный: Лалә «үз халкына бер европалы күзлегеннән карап, аны әлегә җитешмәгән бер бала, белем бирелергә тиешле, формалашмаган шәхес итеп күрә» [Kaya, 2014, б. 55], ди.

«Яңа Туран» романындагы Кая кебек, бу татар кызы өчен дә милләткә һәм халыкка хезмәт итү юлында туган мәхәббәт хисе әһәмиятле. Шунлыктан Лалә шәхси тормышын үзе кебек милләткә хезмәткә омтылучы, төгәлрәге гомерен фәкыйрь авыл кешеләренең хокукларын яклауга багышларга теләүче адвокат Рәҗәп белән бәйли.

Романда Лалә аякларында нык басып торучы, ирләр белән бергә, җилкәгә җилкәне куеп, авырлыкларга каршы баручы феминист хатын-кыз тибы итеп бирелә. Әтисенең үлеменнән соң, беркемгә мохтаҗ булмыйча, гаиләне туендыру җаваплылыгын ул үз өстенә ала. Тырышлыгыннан һәм батырлыгыннан (мәсәлән, әтисенең резин итекләрен киеп, аның көймәсе белән диңгезгә балыкка чыгуы һ.б.), тәэсирләнеп, бер елдан соң аңа Татарчык кушаматы тагыла. Татарчык сүзенең этимологиясен ачыклаган Гүлдән Йүксәккая фикеренчә, әтисенең татар булуыннан һәм бу гаиләнең башкалар тарафыннан чит күрелүеннән тыш, әлеге кушаматның нигезен татар исеме тәшкил итә. Элек-электән атны оста кулланулары һәм озын юлларда түземле булулары белән дан тоткан, җитез, көчле һәм кыю характерлы татарлар госманлы гаскәрендә ямчы хезмәтен башкарган, бу эш бары тик татарларга гына ышанып тапшырылган [Yüksekkaya, www.akademia.edu]. Моннан тыш, төрекчәдә «кызу илләрдә, аеруча Урта диңгез тирәсендә яшәүче, төрле авыруларга юл ачучы вак чебен»гә дә татарчык, диләр [Türkçe Sözlük, 2011, б. 2283]. Ләкин зарарлы вак чебеннән аермалы буларак, ару-талуны белми торган безнең татар кызы төрек җәмгыятенең иске фикерле кешеләрендә борчу уята: аның яшәешне мәдәни юлга чыгару өчен башкарган тырышлыклары канәгатьсезлек хисе тууга сәбәп була.

Белемгә омтылыш, кыюлык һәм максатчанлык кебек сыйфатларны укытучы татар кызы Ләләдә туплап, бу романында да язучы үз карашларына туры килә торган яңа чор хатын-кыз идеалын күз алдына бастыра. Кая кебек, Лаләне дә «хатыннарга хас сыйфатлардан мәхрүм итеп, иркәкләштерә, яңа Төркия өчен уйланган мәдәниләшү проектында ир-атның янында аңа юлдаш булачак хатны-кыз профилен билгели» [Beyhan, 2001, б.52].

Милли идеяләр белән янып яшәгән елларда Халидә Әдип Адыварның үзләрен фидакяр көрәшкә багышлаган батыр йөрәкле татар кызлары белән күрешүе дә мәгълүм. Белгәнебезчә, Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» исемле әсәрендә Балкан сугышында бер-бер артлы җиңелүләргә дучар булган төрек гаскәрләренә ярдәмгә килгән дүрт татар кызы турында да мәгълүмат бирелә. Әсәрдән аңлашылганча, Петербург шәһәрендәге Бестужев кызлар курсларында белем алучылар – Чистайдан Гөлсем Камалова, Петербургтан Ркоя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Поташева исем-

ле туташлар 1912 елның көз аенда Истанбулга килә, һәм госпитальдә эшләү белән бергә, төрекләрнең мәшһүр шәхесләре, шул исәптән Халидә Әдип ханым белән дә күрешә. Бу очрашуда язучы Халидә ханым үзенең төрек хатын-кызларын яңарыш юлына чыгару, белемле итү, җәмгыять эшләренә тарту өчен башкарган эшләре хакында сөйли. Шул ук вакытта Россиядәге мөселман кызларының мәгариф һәм тәрәккыят юлындагы яңарышларыннан да хәбәрдар булуын белдерә. Мөселман кызларының рус мәктәпләрендә белем алулары, үз халкына хезмәт юлына басулары, Уфа һәм Оренбур шәһәрләрендә кызлар өчен махсус төрле җәмгыятьләрнең оешуы, язучы һәм әдипләр җитешүе кебек уңай күренешләргә сөенүен әйтә. «Бер милләтнең кызлары сезнең кебек алдынгы мәктәпләрдә укый башласа һәм аларның да йөрәкләрендә милли хис уянса, ул милләт бетмәс, яшәр. Мин моңа ышанам», – ди мәшһүр әдибә [Kerimi, 2001, б. 100].

Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре»ннән аңлашылганча, татар кызлары Истанбулда төрек хатын-кызлары хәрәкәтенең активлашуына да өлеш кертә. Алар хатыннар арасында ярдәм җыю, хатыннарның күзен ачу, алардан отрядлар төзеп, фронтка җибәрү кебек эшләрдә катнаша. Университетның конференция залында алты мең төрек ханымы, шул исәптән алдынгы төрек язучылары, укытучылар, журналистлар катнашында зур митинг оештыра. Бу митингта Гөлсем Камалова Россиядәге татар аналары исеменнән ялкынлы чыгыш ясый. Көчле алкышлар белән тыңланган чыгышында төрек хатыннарының хокуклары булмауның аянычлы нәтиҗәләре турында да әйтә.

Гомумән алганда, Америка колледжында уку чорында Европаның алдынгы фикерләре белән коралланган Халидә Әдип Адывар, җәмгыятьне үзгәртеп коруда һәм милләтне алга җибәрүдә белемле хатын-кызларның роленә чын күңелдән ышанган. Бу алгарышта үзе дә укытучылык һөнәре аша яшь буынны тәрбияләү эшенә алына һәм проза әсәрләренә баш герой итеп, башлыча, идеалист хатын-кыз укытучыларны сайлый. Милли идеологлар белән аралашу, дәүләт сәясәте белән дә якыннан кызыксыну сәбәпле, әсәрләрендә идеологик фикерләргә зур урын бирелә. Аңлашыла ки, Россиядәге төрки халыкларның (аеруча хатын-кызлар арасындагы) уяну хәрәкәтен күзәтеп барган һәм төркичелек фикеренең идеологы Йосыф Акчура белән якыннан аралашкан Халидә Әдип Адыварның романнарына көрәшче герой итеп татар кызларын сайлавы очраклы түгел. Үткән тарихта татар халкының батырлыгы һәм җитезлеге, белемгә һәвәслеге, иреккә омтылышы, тырышлыгы кебек милли сыйфатлар аның әсәрләрендәге геройларның төп үзенчәлеге итеп ассызыкланган. Милләтенең алгарышы өчен шәхси бәхетен корбан иткән Кая, тормыш авырлыкларына күкрәк киереп каршы барган Лалә кебек яшәүнең мәгънәсен җәмгыятьне белемле итүдә күргән мөгаллимә кызларда язучының романтик идеаллары чагылган. Госманлы хатыннарыннан аермалы буларак, гади яшәү рәвешен өстен күрүче, физик яктан ирләргә тартым, максатчан һәм көчле характерлы яңа тип хатын-кызларда ул яңа

җәмгыятьтә ирләр белән бердәй хокукка ия, алар белән кулга-кул тотынып, мәдәни тормыш юлыннан баручыларны күз алдында тоткан.

**Әдәбият**

*Argunşah H.* Halide Edip'te Değişen Kadinin Romandaki İzdüşümleri: Seviyye Talip'ten Ateşten Gömlek'e: TÜBAR-XXXVII / 2015. Bahar. S. 27–52.

*Beyhan U.A.* Halide Edip Adıvar ve Feminist Yazın, Yüksek lisans tezi, Bilkent Üniversitesi. Türk edebiyatı bölümü, Ankara, 2001.

*Gözütok T.* 'Yeni Turan'da Millî kimlik Sorunu, *Turkish Studies* International Periodical For the Languages, Literature and History of Turkish or Turkic Volume 5/2 Spring. 2010. S. 410–448.

*Edip Adıvar H.* Tatarcık, 7.Baskı. İstanbul: Can Yayınları. 2018. 264 s.

*Edip Adıvar H.* Mor Salkımlı Ev. İstanbul: Özgür Yayınları.1996. 301 s.

*Edip Adıvar H.* Yeni Turan, 5. Baskı İstanbul: Can Sanat Yayınları. 2018. 160 s.

*Zaripova Çetin, Ç.* Tatar Edebiyatının Gelişimi. Akademik Bakış Dergisi, 2006. S. 138–151.

Yeni Türk Edebiyatı (1839–2000) Editör Dr. Ramazan Korkmaz. 5. Baskı. Ankara: Grafiker yayınları. 2009. 640 s.

*Kaya M.* Halide Edip Adıvar'ın İdeal Öğretmen Tipi: Tatarcık. Varlık. Sayı 1281, Haziran. 2014. S. 53–56.

*Kerimi F.* İstanbul Mektupları, İstanbul: Çağrı Yayınları. 2001. 367 s.

*Sağol Yüksekkaya* G. Tatarcık Üzerine, www.akademia.edu

Türkçe Sözlük / haz. Şükrü Haluk Akalın ve başk. 11 baskı. Ankara: Türk Dil Kurumu. 2011. 2759 s.

***Яруллина Йылдырым Рамилә Әсхадулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, профессор,*
*Иненю университеты Төрек теле һәм әдәбияты бүлеме*
*чордаш төрки халыклар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире (Төркия)*

УДК 82-31

***А.Ф. Ганиева***

# ФОАТ САДРИЕВНЫҢ «БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ» РОМАН-ТРИЛОГИЯСЕНДӘ «ШӘХЕС ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ» МӘСЬӘЛӘСЕ

В романе-трилогии Ф. Садриева «Счастье несчастных» освещается период, начиная с 1970-х годов и вплоть до наших дней, в историко-политическом плане. Писатель использует широкие возможности реалистического творческого метода: нрав человека и его психологическое состояние изображены в единой связи с социальной жизнью; острой критике подвергается общественный порядок, угнетающий свободу личности и её право на счастье. Окружающая персонажей среда представлена с разных сторон. Автор статьи исследует концептуальные взгляды Ф. Садриева на человека и общество через анализ его философско-психологического стиля и сложных характеров изображенных героев, через изучение неповторимого образного языка писателя и его искусных изобразительных средств.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фоат Садриев, личность и общество, проза, роман.

In F. Sadriev's novel-trilogy «Happiness of the unfortunates» covers the historical and political period from the 1970s to the present day. The writer uses the wide possibilities of a realistic creative method: the human character and its psychological state are depicted in a single connection with social life; the public order that oppresses the freedom of the individual and their right to happiness is sharply criticized. The environment of the characters is presented from different sides. The author of the article explores F. Sadriev's conceptual views on human being and society through the analysis of his philosophical and psychological style and the complex nature of the characters depicted, through the study of the writer's unique figurative language and his artful visual means.

**Keywords:** Tatar literature, Foat Sadriev, personality and society, prose, novel.

XX–XXI гасырлар чиге әдәбият үсешендә мөһим этап булып тора һәм аерым өйрәнүне сорый. Бу, беренчедән, гасыр ахыры әдәбиятында бөтен йөзьеллык дәвамында булган сәнгати һәм эстетик эзләнүләргә нәтиҗә ясалу белән аңлатылса, икенчедән, яңа әдәбият бүгенге тормышның катлаулы һәм каршылыклы якларын аңларга ярдәм итә, өченчедән, үзенең яңа ачышлары, тәҗрибәләре белән алга таба XXI гасырда әдәбиятның үсеш юлын билгели [Насибуллова, б. 55]. Шул чорда язылган Ф. Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» (1991–2005) роман-трилогиясе укучы тарафыннан яратып кабул ителә һәм шулай ук тәнкыйть, әдәби җәмәгатьчелек тә аны татар прозасының казанышы буларак бәяли. Язучының шактый иҗат гомерен алган бу әсәрнең уңышы берничә фактор белән билгеләнә. Беренчедән, 1990 елларда әдәбият төрле юнәлешләр, алымнар белән

байый, шулай ук тематик яктан да үзгәрешләр кичерә. Совет чорында өнәлмәгән ирреаль дөнья сурәтенә, шартлы-метафорик тасвирга нигезләнгән әдәби әсәрләр күбәеп китү сәбәпле, татар укучысы реалистик юнәлештәге прозага күпмедер ихтыяҗ кичерә. Икенчедән, иҗтимагый проблемаларны киң планда иңләгән, кешенең рухи дөньясын тышкы тирәлек белән тыгыз бәйләнештә сурәтләгән киң панорамалы әсәрләр безнең әдәбиятта сирәк туа, ә 1970 еллардан алып бүгенге көнгә кадәрге чорны тарихи-сәяси яссылыкта яктырткан зур күләмле әсәрләр исә бөтенләй юк дәрәҗәсендә була. Өченчедән, әсәр тарихи характерда булса да, укучының замандашлары турында, җәмгыятьтәге рухи тетрәнүләр, социаль-иҗтимагый үзгәрешләр аңа яхшы таныш, ул үзе үк – аларның шаһиты. Әлеге роман-трилогиясе өчен язучы 2010 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Ф. Садриев геройлары – заман кешеләре. Язучы реалистик иҗат методының киң мөмкинлекләреннән файдалана: кеше холкын, психологик халәтләрне иҗтимагый тормыш белән бәйләп сурәтли, җәмгыятьтәге шәхес азатлыгына һәм бәхетенә каршы төшкән тәртипләрне кискен тәнкыйтьли. Әсәрдә персонажларны чолгаган мохит төрле яклап яктыртыла. Бу геройның шәхси бәхете (мәхәббәте, гаилә мөнәсәбәтләре), иҗтимагый тормышы (кеше һәм җәмгыять), табигый асылы (кеше һәм табигать, туган җир, татар авылы) яссылыкларында карала.

Фәлсәфи-психологик романда Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, И. Гази, М. Әмир, Г. Ахунов кебек әдипләрдән килгән эпик традицияләр үстерелә, Л. Толстой, М. Шолохов тәҗрибәләре уңышлы файдаланыла. Фәлсәфә тормыш ситуацияләре һәм геройларның хис-тойгылары белән үрелеп бара, шуңа психологизм әсәрдә тагы да тәэсирлерәк бирелә. «Ф. Садриевның реалист язучы буларак көчле ягы шунда: ул әсәрнең төзелешен-композициясен һәм аңа бәйләнешле сюжет тармакларын бертуктаусыз үсә, көчәя баручы вакыйгалар тезмәсенә кора белә, укучыны гел киеренкелектә тота» [Бакиров, б. 80].

Әсәрнең үзәгендә – гаделлекне яшәү маягы иткән намуслы, саф күңелле Ирек исемле ир-егет. Язучы аның яшьлек елларыннан алып ир уртасы булганга кадәрге тормышын сурәтли һәм шуңа нисбәтле бик күп геройларның язмышларын ача. Роман Ирек Сабитовның партия сафларына кабул ителүе һәм авыл мәктәбендә укытучы булып эшләгән җиреннән райкомның идеология бүлегенә инструктор итеп чакырылу вакыйгаларыннан башланып китә. Тәҗрибәле, төпле фикерле, тормышка үз карашы булган Мэлс абыйсы, райкомны кирпеч заводы белән чагыштырып, Ирекне алдан ук кисәтә: «Кирпеч заводында эш коточкыч авыр, теләсә кем түзә дә алмый. Тагын шунысы да бар, кая карасаң да кирпеч... чие, яндырырга кертелгәне, мичтән яндырып чыгарганнары. Бөтенесе бер зурлыкта, бер формада. Аяк асты тулы кирпеч ватыгы... Кайсылары урталай сынган, кайсылары буйга, кайберләре гел чәрдәкләнеп беткән...<...> Тик анда кызыл балчык урынына икенче әйбер салалар» [Садриев, 2011, б. 38]. Иҗат кешесе булган Ирек, «тормышның үзәгендә кайныйсы килеп», рай-

комда эшләргә шатланып риза була. Алга таба аны район газетасына мөхәррир, аннан профсоюз комитеты рәисе итеп куялар.

Трилогиянең беренче, икенче китапларында партиянең шәхесне изүгә корылган механизмы фаш ителә. Җитәкчелекнең (Үзәк Комитеттан башлап, гади колхоз рәисенә кадәр) икейөзлелеккә, ялганга, ялагайлыкка нигезләнгән идарә итү ысуллары төрле вакыйгаларда ачыла. КПССның һәм коммунистларның хаклыгына ихластан ышанып партиягә кергән Ирекнең ни иҗатка, ни шәхси тормышка вакыты калмый башлагач, карашлары үзгәрә, тора-бара ул үзенең партия өчен бер шөреп кенә булуын, инде бу ятьмәдән чыга алмаячагын аңлый. Райкомның беренче секретаре Миңзаһит Арысłановка, икенче секретарь Зөфәр Шәвәлиевкә дөреслекне йөзләренә бәреп бирүче Ирекне эшеннән алып ату берни дә тормас иде, әмма алар аны үзләренә докладлар, чыгышлар яздыру өчен, алны-ялны белми куйган намуслы хезмәте өчен тоталар.

Әсәрдә план артыннан куунық, идарә итүдә административ-команда методының халык тормышына китергән зыяны күрсәтелә. Эреле-ваклы түрәләргә властьны үз ирекләрендә файдалануга юл куелу гади хезмәт кешесенең хокукларын чикли. Мисал өчен, «Авангард» колхозы рәисе Гайсә Батталов үз колхозчысын үлем чигенә җиткергәнче кыйнап ташласа да, җинаяте өчен хөкем ителми, киресенчә, ялган заговорлар оештырып, каза күрүченең үзен гаепле итеп калдыра; каршы фикер әйтүче хезмәткәрләренең электр чыбыгын өзеп һәм утынсыз калдырып үч ала.

Ф. Садриевның чагыштыру алымына еш мөрәҗәгать итүен, моның өчен капма-каршы күренешләр файдалануын әйткән идек. Ул үз әсәрләрендә укучының игътибарын илдәге социаль тигезсезлеккә, аның килеп чыгу сәбәпләренә юнәлтә. Язучы Арысłановның бай йортын, сөяркәсен көткәндә затлыдан-затлы мул ризыклар әзерләп йөрүен сурәтләгәннән соң, Кырбаш авылында яшәүче Сираҗетдин тормышына күчә һәм йорт эче күренешен натуралистик сурәттә, корреспондент Ирек күзлеге аша үтә ярлы, җан өшеткеч хәләттә күз алдына бастыра. Ялгызы көн итүче, сугышта бер аягын, кул бармакларын өздереп кайткан ир ике ай ит күрмәгән, майны кайчан капканын да оныткан, бодайны тере килеш пешереп, күршесе биргән терлек эчәгесеннән аш әзерләргә җыенып йөри. Тормыш турындагы фикерләре дә уйландырырлык. «Үзем генә булсам, уйлап та бирмәс идем. Сылтар идем әле шунда йә Аллага, йә язмышка, йә бүтәнгә. Кавеме белән бит... Гомере буе эшләгән адәм баласының тамагы туя алмый икән, нидер дөрес түгел. <...> Германга барып, нимесне җиңеп кайттык югыйсә...» [Садриев, 2011, б. 168]. Әсәрдә Ирекнең «Ник кан койдың, Сираҗетдин?» исеме белән мәкалә бастырып чыгаруы һәм әлеге вакыйгага бәйле туган конфликт укучыны илнең иҗтимагый хәле турында уйланырга этәрә.

Читләтеп әйтү, киная, аллегорияләр романда мул кулланыла. Арысłанов, Шәвәлиев, Нәҗмиев, Чукаева фамилияләрен автор

геройларның тормыштагы урыннарына, яшәү рәвешләренә туры китереп сайласа, Ирек исеменә капма-каршы мәгънә сала. Хокуклары тапталмаган, рухи азатлыгы чикләнмәгән илдә генә кеше бәхетле була ала. Ирек образында исеменең киресе раслана. Мәскәүгә бер еллык театраль курсларга Язучылар берлегеннән юлламасы булса да, укырга китәргә рөхсәт бирмиләр, инде киткәч тә, партия органнары аша кире кайтартып, партиядән һәм эшеннән чыгаралар. Хатынының хыянәт итүе дә беленгәч, Ирекнең рухи кризис чоры башлана: ул эчкечелеккә бирелә. Әсәрдә аның үз-үзе белән көрәш дәвере артык озынга китә һәм кабатланулар укучыны ялыктыра башлый. Әмма бу урында шуны да әйтергә кирәк: татар әдәбиятында эчүгә бирелгән геройның рухи халәтен аңлап, моны тирәлек, мохит, заман, шәхси факторлар белән бәйләп, бөтен нечкәлекләре белән тасвирлаган әсәр юк иде әле. Геройның ихтыяр көче сыналу матурлык һәм ямьсезлек, югарылык һәм түбәнлек көрәше булып, гаять киеренке психологик моментларда күрсәтелә. Күпчелек классик әсәрләрдәге сыман, монда да коткаручы – хатын-кыз: эчкечелек сазлыгыннан Ирекне яшьлек мәхәббәте Зәнфирә тартып ала.

Романда хатын-кыз образларыннан Сөембикә татар әдәбияты өчен үзенчәлекле характер буларак ачыла. Әсәрнең баштагы өлешләрендә район җитәкчеләре белән ятак уртаклашу бәрабәренә дәрәҗәле эшләргә урнашуы, Ирекне алдавы, гаилә корганнан соң да йөрүләрен дәвам итүе белән ул үзенә карата укучыда нәфрәт уята. Алга таба аңа мөнәсәбәт үзгәрә: Сөембикә система корбаны буларак кабул ителә башлый. Холкы, темпераменты, хәтта язмышы да (әнисенә охшап) каннан килә һәм ул тәрбияләнгән мохит йогынтысы дип аңлатыла. Әсәр ахырында Сөембикә рухи-психологик катарсис халәте кичерә. Тәне белән пычранса да, күңеле белән чиста калуы, язмыш сынауларын үтәргә үзендә көч табуы, Ирек кебек аның да дөреслек өчен көрәшүе, кыю адымнары өчен язучы аны аклый һәм бәхеткә лаек дип таба.

Арыслановның җитәкчелек итүе совет дәверенә карый һәм ул әсәргә җитәкче тибы булып килеп керә. Автор аның акыру-җикеренүгә корылган авторитар идарә итү алымын тәнкыйть утына алса, аңа алмашка килгән Әхнәф Шәрифуллин исә – яңа буын җитәкче, итагатьле, белемле, үз халкының тарихы белән кызыксынучы, Ирекнең дусты, фикердәше булган кеше. Әмма власть аны да үзгәртә. Бу урында Әхнәфнең, хатыны коткысына бирелеп, шәхси милкен арттыруы белән Ә. Еникинең «Саз чәчәге»ндәге Шакир Мостафинны хәтерләтүен билгеләргә кирәк. Ф. Садриев аксакал язучының идеясен үстерә, дәүләтнең халыктан аерылу сәбәбен җитәкчеләрнең үз мәнфәгатьләрен алгы планга куюлары, шәхси милек колына әверелүләре нәтиҗәсе дип күрсәтә.

Әсәр партия аппаратын тәнкыйтьләүгә генә корылмаган, анда власть һәм кеше мөнәсәбәте, гомумән, киң планда алына. Беренче, икенче китапларда ул партия белән бәйле каралса, өченчесендә партия таркалганнан соңгы дәвер башлана. Язучы җитәкче кешенең пси-

хологиясен ачарга омтыла: «Аның уйларында, хис-кичерешләрендә, башында һәм йөрәгендә җир, техника, машиналар, мал-туар, фермалар, гектарлар, тонналар, меңнәр, миллионнар... Ул – йөрәкле роботның бер төре. Тиешлене генә белә, шул тиешне чынга әверелдерү өчен көненә мең төрле маска кия» [Садриев, 2011, б. 835]. Теләсә нинди хакимият кеше шәхесен җимерүче, аның кешелек сыйфатларын бетереп, машина-робот хәленә китерүче көч буларак күрсәтелә.

Метафоралар, тиешле урында кулланылган символик детальләр әсәрнең сәнгатилеген арттыра. Вакыйгалар барган район үзәге Болынкыр дип аталу әлеге сүзгә дә фәлсәфи шартлылык салынуын күрсәтә. Болын, кыр – дөнья әдәбиятында да сакраль мәгънәгә ия образлар. Әсәрдә уңышлы кулланылган символларга мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Әхнәфләр гаиләсе, Ирекләрнең яңа өйләрен котлап, картлар йорты өчен кайтарылган җиһазны бүләк итә. Ике дус арасындагы конфликт шул шкаф-дивар аркасында чыга һәм дусларны аеручы символга әйләнә. Ирекнең чираттагы авыр психологик кризис чоры башлана, чөнки аның өчен дуслык та – вөҗдан кебек үк, изге һәм керләнми сакланырга тиешле хис. Геройның җаны бәргәләнүен тасвирлаганда, язучы көянтәле иске үлчәү символик детален куллана.

Романда башка геройларны куркытып, укучы күңеленә шом салып торучы бер персонаж бар. Ул – Миңзаһитның гаиләдә тиешле тәрбия күрмәгән, балачактан ук узынып үсеп, Мәскәү криминалына килеп эләккән улы Рашат. Язучы, тормышны киң планда сурәтләү максатында, укучыны төрле катлам кешеләре белән очраштыра һәм бу очракта Рашат җинаятьчел төркемнең бер вәкиле буларак бирелә. Бер караганда, әдәбият өчен аның яңалыгы юк та кебек. Гаиләдә ир-хатын мөнәсәбәтләре начар булу сәбәпле, игътибар җитмәгән балаларның бозык юлга кереп китү күренешен тасвирлау мәгърифәтчелек чорыннан ук килә. Рашат образы бернинди әхлакый киртәләргә сыймый торган кешелексез гамәлләре белән Арыслановка гомер азагына бирелгән җәза буларак кабул ителә. Әмма Рашатка әлеге романда башка йөкләмә дә салынган. Автор аның авызыннан чыккан аңлашылыр-аңлашылмас сүзләр аша кешелеккә янаган куркынычны сиздерә. «Сез өстә нинди гыйфрит утырганны белмисез. Бөтен Җир шарына ул хуҗа. Астарак, – ул башы белән Фишкегә һәи Күсәккә ымлап куйды, – тагын бер кавем бар. Тик ул кавем, өстәгеләр белән чагыштырганда күселәр өере генә. Шуларның икесеннән җирнең үлем шәүләсе барлыкка килә» [Садриев, 2011, б. 832]. Язучы ил белән, хәтта дөнья белән идарә итүчеләр арасында җинаятьчеләр булуны күздә тота. Ирек бервакыт наркобизнес атаманы, криминал җинаятьче Вышканың Дәүләт думасына сайлануын һәм телевидениедән яшьләрне тәрбияләү турында чыгыш ясавын күреп шаккката. Шулай ук Рашатның фашизмны пропагандалау турындагы китапны, зур акчалар биреп, Иректән тәрҗемә иттерергә теләве Җирдә явызлыкның җәелә баруы турында сөйли. Ә инде Ирек баш тарткач, аның: «Сез бит барыгыз да болындагы үләннәр! Исеме җисеменә туры килеп

тора: Болынкыр! Ха-ха-ха! Печән чабучылар әле килмәгән, үләннең калынаюын көтәләр. Җиләк тә өлгермәгән. Аны җыярга тубал тотып шулай ук әзер торалар. Бөтенесе көтә. Шулай да чалгы янаган тавышлар ишетелә. Маңгаеңны җыерма, сез ул тавышларны ишетмисез. Сез генә түгел, алар өчен бөтен Җир шары болын, печәнлек» [Садриев, 2011, б. 656], дигән сүзләре язучының киләчәктәге куркынычны кисәтүе булып яңгырый.

Исеменнән үк күренгәнчә, язучы романда бәхет турындагы карашлары системасын тәкъдим итә. Аның беренчесе – ихласлык, сафлык, гаделлеккә корылган үзара мөнәсәбәтләр. Бу гаиләгә дә, хөкүмәт белән халык арасындагы бәйләнешләргә дә карый. Ялган кеше бәхетен җимерүче, җәмгыятьне таркатучы явыз көч буларак бирелә. Икенчесе – кешенең рухи азатлыгы. «Иң кадерлесе – һәрбер адәм баласының уй-омтылышлары, хис-тойгылары. Бары шул булганга гына бәндә кеше дип атала. Аның бөек җиһан тарафыннан бүләк ителгән һәм мәңгелек бизмәннәреннән караганда, бер генә дөртләп алуга тиң күңел тибрәнешләре, хыял-омтылышлары кагылгысыз! Иң бөеге, иң кадерлесе шул. Аңа тукыну – вәхшилек. Чөнки кеше бер генә яна да сүнә, бүтән беркайчан да кабатланмый...» [Садриев, 2011, б. 262] – дип яза автор. Дәүләтнең бурычы, – әсәрдә сурәтләнгәнчә, кешене кол хәленә төшерү түгел, ә аның хокукларын яклау, азатлыгын тәэмин итү.

Өченчесе – кешелекнең рухи һәм матди яшәеше мәсьәләсе. Яшь романтик Ирек бөтен Җир халкының дөньяга карашын үзгәртү турында хыяллана. Ул, гомумән, кешелекне ялгыш юлдан киткән, бүгенге яшәү рәвешеннән баш тартып, рухи якны алгы планга куеп яши башларга кирәк дип саный. «Бүгенге кешелек өчен күбрәк һәм сыйфатлырак әйбер җитештерү ул – яшәешнең төп кучәре. Җир йөзе күпме дауларны, яуларны, сугышларны, кан коюларны күргән – барысы да әйбер өчен... Шул мәнфәгатьләрдә барлык төр үсемлекләр, су, җир, һава, тереклек ияләре зарарлана, бозыла, агулана, юк ителә. Ирек бу һәлакәтне туктатуга бер генә юл күрә: һәммә нәрсәдән тыелырга! Кешелекнең чиксез нәфесен, Җир шарын балчыгы белән ашап бетерсә дә, канәгатьләндереп булмаячак. <...> Бүген җитештерелә торган коточкыч кораллар, бәндәләрне юк итү өчен уйланылган бүтән чаралар һәммәсе дә бары бер максатны – күбрәк әйбер яулауны күздә тоталар. Адәм баласы Тәңрегә табынмый – әйбергә табына, вөҗданга табынмый – әйбергә табына, туганлыкка табынмый – әйбергә табына, игелеккә табынмый – әйбергә табына. Шуның аркасында күпләр тормыш принципларыннан баш тартып, намусларын ташлап, кемнәрнеңдер кулында үзләре әйбергә әверелә» [Садриев, 2011, б. 163]. Әлеге фикерләрен чагылдырган хезмәтен ул «Яңа Корьән» дип атамакчы була. Улының иҗат ниятләрен белеп алган әнкәсе аны тәүбә итәргә өнди. Ул Изге китапның бер генә булуын, аны беркем дә үзгәртә дә, яңарта да алмавын әйтә, Иреккне Аллаһка каршы чыгуда гаепли. Шул ук вакытта бу мәсьәләдә автор карашы кызыклы. Әнисенең сүзен тыңлап, ул әлеге хезмәтен язудан туктый, әмма яндырырга, юкка чы-

гарырга кулы бармый. Һәм шул көннән башлап, язучы Ирекнең тормышына көтелмәгән борчулар килә башлавын яза. Монда язучының аерым кешеләр генә дөньяны үзгәртә алмый дигән фикере сизелә.

«Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе – әлбәттә, прозаикның чираттагы уңышы, киң колачлы эпик жанр мөмкинлекләрен үзләштерүдәге яңа бер иҗади казанышы» [Вәли-Барҗылы, 136]. Әдәби җәмәгатьчелек хаклы рәвештә романның озынга китүен, вакыйгаларны тыгызлау мөмкинлеге булуын билгеләп үтсә дә, бу һич әсәрнең әһәмиятен киметми. Ул татар әдәбиятында халык тормышының мөһим чорын зур күләмдә сәнгатьчә яктырткан иң уңышлы әсәрләрнең берсе булып тора.

Шулай итеп, Ф. Садриев халыкның рухи-мәдәни, иҗтимагый яшәешенә аерым игътибар бирә. Романда һәркемне борчыган мәсьәләләр күтәрелсә дә, үзәккә – Кеше, аның бәхете куела. Бәхет исә, язучы фикеренчә, рухи һәм матди бөтенлек, гармония, шәхес ирегендә. Кешене бәхетле итү – дәүләтнең төп бурычы. Бу халык белән идарә итүче җитәкчеләрнең мораль йөзе, намусы белән турыдын-туры бәйле. Әлеге концептуаль караш язучының фәлсәфи-психологик стиле, катлаулы характерлар итеп тасвирланган геройлары, беркемне кабатламаган образлы теле, зәвыклы сурәт алымнары аша укучыга җиткерелә.

**Әдәбият**

*Бакиров М.* Бәхетсезләр бәхете // Мәйдан. 2011. № 3. Б. 71–82.

*Вәли-Барҗылы М.* Намуслы кешеләр // Казан утлары. 2008. № 1. Б. 129–137.

*Насибуллова Г.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар хикәяләрендә әдәби мотивларның чагылышы // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 55–65.

*Садриев Ф.* Бәхетсезләр бәхете: роман трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 903 б.

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-31

*А.С. Чугунов*

# Ш. ИДИАТУЛЛИННЫҢ «БРЕЖНЕВ ШӘҺӘРЕ» РОМАНЫНДА МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘЛӘР

В статье рассматривается проблема национальной идентичности сквозь призму романа Шамиля Идиатуллина «Город Брежнев». Национальная идентичность связана с осознанной принадлежностью человека к определенной нации, культурному пространству этого народа. Нами определены формы и механизмы проявления национальной идентичности в романе «Город Брежнев». Национальные традиции, духовные ценности татарского народа раскрываются через мировосприятие главного героя – тринадцитилетнего Артура. Автор также описывает модель национальной семьи – взаимоотношения в семье, культ отца, роль женщины и матери.

**Ключевые слова и фразы:** Идиатуллин, город Брежнев, татарская литература, национальная идентичность, родной язык, традиционные ценности.

The article examines the problem of national identity through the prism of Shamil Idiatullin's novel «Gorod Brezhnev». National identity is associated with the conscious belonging of a person to a certain nation, the cultural space of this people. We have defined the forms and mechanisms of national identity manifestation in the novel «Gorod Brezhnev». National traditions and spiritual values of the Tatar people are revealed through the worldview of the main character thirteen-year-old Arthur. The author also describes the model of the national family – relationships in family, the cult of the father, the role of women and mothers.

**Key words and phrases:** Idiatullin, gorod Brezhnev, Tatar literature, national identity, native language, traditional values.

Мәкаләдә язучы Шамил Идиатуллинның «Брежнев шәһәре» («Город Брежнев») романында яктыртылган милли проблемалар һәм милли-мәдәни кыйммәтләр турында сүз бара. Милли үзбилгеләнү темасы соңгы чор әдәбиятында актуаль проблемаларның берсе булып тора [Малахов, с. 48]. Соңгы дистә еллар эчендә әдәбиятка килгән һәм үзенең иҗатына игътибар яулап өлгергән Шамил Идиатуллин иҗатын өйрәнү дә теманың актуальлеген арттыра.

Әдәбият белгече С.А. Кулагин бүгенге көндә бу теманың актуальлеген күрсәтеп, болай дип яза: «Хәзерге вакытта үзеңнең аерым бер этник төркемгә каравыңны аңлау – кешелек яшәешенең төп шартларыннан. Шуңа күрә бөтен дөньяда приоритетлы гыйльми эзләнүләрнең милли үзбилгеләнү өлкәсенә авыша баруы күзәтелә» [Кулагин, с. 3].

Рус телендә иҗат итүче татар язучысы Шамил Идиатуллин (1971 елда туган) – мифо-мистик эчтәлекле «Убыр» романы, «Сукояр эрасы» («Эра Водолея») повесте, «СССР™» дигән һәм жанры буенча иҗтимагый фантастика дип билгеләргә мөмкин булган әсәр, «Бу бары

уен гына» («Это просто игра») фантастик-маҗаралы роман һәм башка әсәрләр авторы. Әдәбият галиме М.И. Ибраһимов билгеләп үткәнчә, аерым язучыларның (Ш. Идиатуллин, Р. Бухараев һ.б.) рус телендә иҗат итүе аларның татар мәдәниятеннән аерылганлыгын билгеләми. Ул, рус телле татар язучыларының татар әдәбиятында тоткан урынын күрсәтеп: «Бу әдипләр үзләренең әсәрләрендә, мәкаләләрендә, интервьюларында рус телле укучылар арасында татар мәдәниятен һәм әдәбиятын пропагандалыйлар», – дип яза [Ибрагимов, 2018, с. 85]. Ш. Идиатуллин иҗаты да, рус телле язучы булуына карамастан, татар дөньясын, татар тарихын, мәдәниятен тасвирлый. К.К. Солтанов, рус телле милли әдәбиятның формалашкан күренеш булуын искәртеп, аны өйрәнүнең зарурлыгын билгели [Султанов, с. 154].

«Брежнев шәһәре», беренче карашка, үсмерләр тормышын, аларның беренче мәхәббәтләрен, өлкәннәр, ата-аналар, укытучылар белән мөнәсәбәтләрен сурәтли. Гомумкешелек һәм милли кыйммәтләр үсмерләр кабул итүе аша тасвирлана. Әсәрнең берничә сюжет сызыгы төп герой – унөч яшьлек Артур образы аша бер үзәк тирәсенә берләшә. Төрле образлар һәм күренешләрне сурәтләү аркылы автор илдәге, аерым алганда, Брежнев шәһәрендәге вакыйгалар, илдәге сәяси һәм икътисади хәл, халык тормышы белән таныштыра. Бу шәһәрдә илнең төрле почмакларыннан җыелган халык яши. Алар арасында, илдә барган вазгыятькә буйсынып, үз милли трацияләреннән, йолаларыннан качкан, гаиләдән килгән, гасырлар дәвамында формалашкан кыйммәтләрне онытырга, «совет кешесе» булырга омтылганнар да, үзенә бу тормышта урын таба алмаганнар да күп, хәтта кешелеген югалтканнар да бар. Романда вакыйгалар 1983 елда бара, бу – традицияләр юкка чыккан, буыннар арасындагы эзлеклелек, дәвамчанлык югалган чор. Кызыл лозунгларга төрелгән шәһәрдә халыкның күбесе илдәге вазгыятьтән риза түгел. Әмма халык канәгатьсезлеген кычкырып әйтә алмый, дөресрәге, бу турыда уйларга да курка.

Брежнев шәһәрендә Бөтенроссия төзелеше дип игълан ителгән төзелеш дәвам итә. Буш урында яңа шәһәр калкып чыккан. Шәһәр буш урында төзелгән кебек, мәдәният тә буш урында халыкның гасырлар буена формалашкан традицияләрен, рухи кыйммәтләрен инкяр итеп формалаша. Брежнев шәһәрендә урам исемнәре булмау, комплекс һәм йортларга номерлар гына бирелү дә өр-яңа, үткәннәргә бәйләнмәгән, тарихын оныткан яңа халык – совет халкы формалашуга этәргеч булып тора. Таш йортлар арасында халык кабул итә алмаган заманча скульптура-һәйкәлләр урнаштырылган. Автор, бу скульптураларга укучының игътибарын берничә тапкыр юнәлтә, аларга төп герое исеменнән бәя бирә: «Замаскированное оружие инопланетян или последствия автокатастрофы с участием двадцати бетономешалок, которые дешевле было изукрасить как получится да и оставить, чем убрать [Идиатуллин, с. 115]; «Скульптуры, по слухам, дико нравились иностранцам – настоящее современное искусство, все дела. Вот и забирали бы себе, а не заставляли нас этим любоваться и

тем более мерзнуть, любуясь» [Идиатуллин, с. 438]; «Только в Брежневе сплошное современное искусство, от которого дети плачут, а взрослые матюгаются» [шунда ук, б. 439].

Автор, шушы скульптураларны тасвирлап, шәһәрдәге хаоска игътибар юнәлтә, романда тасвирланачак вакыйгаларның очраклы булмавын искәртә, закончалыгын күрсәтә. Скульптуралар шушы вакуумда туган, милли һәм гомумкешелек кыйммәтләренә алмашка килгән бер халыкның традицияләренә дә туры килмәгән культураны символлаштыра.

Милли мәсьәләләр дә автор игътибарыннан читтә калмый, ул күп кенә милли проблемаларны беренче булып күтәрә. Романда тасвирланган елларда халыкны ассимиляцияләү, милли үзенчәлекләрен юк итү, аны милләт буларак юк итеп, системага яраклашкан совет халкы итеп тәрбияләү процессы бара. Халык милли кыйммәтләрдән өстен булырга тырыша, этник үзбилгеләнүдән азат халык формалаша. Бу – милли телләр, милли мәдәният, милли традицияләр юкка чыгуга юл тоткан чор. Шамил Идиатуллинның «Брежнев шәһәре» романында шушы сәясәт, аның нәтиҗәләре дә күрсәтелә. Романда милли мәсьәләләр халыкка милләт буларак юкка чыгу куркынычы янаган бер чорны тасвирлау аша ачыла.

Татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәтләре, теле, бу чорда, нигездә, гаиләдә генә сакланып кала һәм киләчәк буыннарга тапшырыла. Автор бу проблемага шулай ук аерым детальләр ярдәмендә, татар халкының менталитетын, халыкка хас сыйфатларны сурәтләү аша да килә.

Язучының татар теле лексикасыннан аерым сүзләрне романда куллануы, татарларга хас акцентны күрсәтүе дә милли картина тудырырга ярдәм итә.

Әсәрне шартлы рәвештә икегә бүлеп карап була. Беренче өлештә геройлар татар мәдәниятенә битараф булса яки аны оныту турында уйласа, икенче өлештә төп геройларның гаиләгә, туган телгә мөнәсәбәте аша асылына кайтуы сурәтләнә. Романда сурәтләнгән чор – интернациональ гаиләләр арткан, шушы күренеш хупланган заман. Артур да катнаш гаиләдә үсә. Әсәрнең башында гаилә башлыгы Вазыйх Насихович аңлы рәвештә үзенең татар булуыннан качарга, милли традицияләрне онытырга, аларны инкяр итәргә тырыша. Автор Вазыйх Насихович образы һәм производство линиясе аша әдәбият әлегә кадәр әйләнеп узган милли проблемаларга туктала. Вазыйх Насихович ике ут арасында яши, бер яктан, ул тырыш, булдыклы җитәкче, үзенең эшенә гаять җитди карый, икенче яктан, милли кадрларга булган мөнәсәбәткә бәйле рәвештә, карьерасы өчен борчыла. Бу күренеш геройның эше, төгәлрәге илдәге вазгыять белән бәйле. Вазыйх Насихович чуен кою заводында баш энергетик вазифаларын башкара. Бу чорда татар милләтеннән булган кеше, хезмәте никадәр генә югары булмасын, иң югары постларга беркайчан да билгеләнми. Бу турыда Вазыйх Насихович түбәндәгечә аңлата: «Генерал

не может быть татарином, зам может, но только если один из нескольких, а если он все-таки один, то ниже его вообще татар быть не должно. Двух Вазыхов на высокой должности никто терпеть не будет, это сразу слухи пойдут, стук: кумовство, национализм, татарское засилье, своих тащат и так далее» [Идиатуллин, с. 197]. Шушы өзек әсәрдә сурәтләнгән милли традицияләрне, татар теле, мәдәният белән бәйле һәр эпизодны башкача бәяләргә мөмкинлек ача.

Ш. Идиатуллин, Вазыйх Насихович образы аша, шул чорга хас күренешне, шәһәр халкының туган теленнән читләшеп, руслаша баруын, бигрәк тә катнаш гаиләләрдә телнең юкка чыгуын тасвирлый. Герой да туган телен баласына тапшыра алмавы, милли традицияләргә хыянәт итүе өчен борчыла. Шул ук вакытта ул, татар милләтеннән булмаса, милли проблемалар белән очрашмаячагын, карьера җиңелрәк биреләсен дә аңлый: «На таких смотрят только по существу: насколько толковый, насколько удобный, насколько молодой, такие вот вещи» [Идиатуллин, с. 198]. Әмма герой, бу мәсьәләне күтәрсә дә, милләтенә хыянәт итә алмасын да белә. Бу геройның исеме мәсьәләсендә дә күренә. Мәсәлән, Вазыйхка хатыны Вадик дип эндәшә. Ул үзе дә бу исемгә яраклашкан, хәтта исем һәм фамилиясен үзгәртү турында да фикере бар. Әгәр бабалары руслашкан булса, – икенче мәсьәлә, ул милләтеннән баш тартырга теләми. Хатынының улларына ни өчен Артем түгел, Артур дип исем кушуы турындагы соравына герой кискен җавап бирә: «Вышла бы за русского, назвала бы Артемом» [шунда ук, б. 198].

Әлеге эпизодлар, бер яктан, геройның бу мәсьәләгә карашын күрсәтсә, икенче яктан шул чорда татар халкында киң таралган күренешне тасвирлый. Бу – татарның үз исемнәрен рус теленә яраклаштыру яки охшаш яңгырашлы рус исемнәренә алыштыру. Дөрес, бу күренеш, бары телдә аралашуда гына чагыла, мәсәлән, Вазыйх – Вадик, Юныс – Юра һ.б. Исемнәргә караган икенче күренеш – катнаш гаиләләрдә балага ике халыкка да яраклы, күбрәк Европа халыкларыннан кергән исемнәр кушу. Төп геройның исеме дә шундый – Артур. Бу елларда Руслан, Тимур, Диана, Альбина кебек исемнәр еш бирелә. Аларны халык телендә «русско-татарские имена» дип йөртү күренеше дә бар.

Иң беренче милли проблемага – тел мәсьәләсенә Ш. Идиатуллин шактый игътибар бирә. Татар теленә мөнәсәбәте турында ул болай дип яза: «Чтобы у детей была тяга к изучению языка, должен быть какой-то смысл, не связанный с бытом. Должен быть какой-то луч в окошке. Если смысл экзотический – это прикольно, если он совпадает с интересом к твоим предкам, это не прикольно, но зато рифмует тебя с твоим народом и со смыслом жизни вообще» [URL: https: // www.business-gazeta.ru/article/392445]. Автор туган телгә халыкны берләштерүче чара буларак бәя бирә.

Шамил Идиатуллин әсәренә мәктәпләрдә татар теле укытуга бәйле күзәтүләрен дә кертә. 1983 елда мәктәп программасына татар

теле керә генә башлый һәм бу дәрескә бары татар балалары гына йөри. Башкалар кайтып киткәндә дәрескә кереп калырга мәҗбүр булган укучылар, әлбәттә, татар теле дәресен өстәмә йөк буларак кабул итә. Моның белән беррәттән, әсәрдә мәктәпләрдә күзәтелгән икенче мәсьәлә дә күтәрелә. Бу – былиналарда кулланылган «поганый татарин» терминын татар укучыларының авыр кабул итүе. Хәтта үзен татар дип санамаган, әлегә татарлыгы уяна гына башлаган Артур да бу күренешне авыр кичерә.

Вазыйх Насихович туган телен белә, әмма сөйләшә алмый. Хатынының рус милләтеннән булуы, бу чорда шәһәр халкының рус теленә күчә баруы аркасында, ул нигездә рус телендә аралаша. Артурның татар теленә битараф булуын, татар теле дәресләренә дә атасына хөрмәте аркасында гына керүен күрәбез. Туган телгә мөнәсәбәт аша ата белән бала мөнәсәбәтләре ачыла. Романда татар халкы тормышында зур урын тоткан ата-анага, гомумән, өлкәннәргә хөрмәт күренешенә шактый урын бирелә.

Шамил Идиатуллин татар халкының ризык культурасына да берничә тапкыр мөрәҗәгать итә. Бергәләп ризык әзерләү, бергә өстәл артына җыелу, өстәл артында гаилә өчен кирәкле мәсьәләләрне хәл итү, киңәшләшү – татар гаиләләре өчен хас күренешләрдән. Аерым акцент ашау белән бәйле хәрәм-хәләлгә ясала, бигрәк тә, мәсәлән, ислам дине кануннары буенча дуңгыз итен ашаудан тыелу. Беренчедән, Вазыйх Насихович, дуңгыз итенә басым ясап, аны башка иттән аерып куя – «мясо и свинина». Дуңгыз итенә геройның мөнәсәбәте геройның әбисе турындагы өзектән аңлашыла: «Вадик прекрасно ел свинину, со студенческих лет, даже сало иногда, и родители у него свинину ели, хоть и не слишком часто, сами ели и Вадиковой бабушке подсовывали, а она ругалась и выбрасывала оскверненные ножи и вилки на помойку» [Идиатуллин, с. 196]. Бу эпизод «үз» һәм «чит», төгәлрәге «без» һәм «алар» оппозициясен ачуга мисал була ала. Ш. Идиатуллин бу методка берничә тапкыр мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, милли кухня, аерым йолаларны тасвирлаганда, автор ике халыкның мәдәни күренешләренә параллель үткәрә, рус һәм татар халкының тормышы, көнкүрешенә хас детальләр, йола-традицияләр чагыштырыла. Әмма бу оппозиция бер якка да өстенлек бирми, автор һәр ике халыкка хөрмәт белән иҗат итә. Бу очраклы да түгел, татар һәм рус халыклары гасырлар дәвамында янәшә, бер берсен хөрмәт итеп, аралашып яши. Шуңа күрә Ш. Идиатуллин милли характердагы проблемаларның дәүләт сәясәте булуын кат-кат искәртә. Ике халык арасында аерма күрми.

Шамил Идиатуллин иҗатында милли үзбилгеләнү темасы этник толерантлык темасы аша ачыла. Артур, катнаш гаиләдә үскән бала буларак, үзен ике халыкка да мөнәсәбәтле тоя. Әнисенең рус милләтеннән булуы сәбәпле, ул үзен рус санаса да, татар мәдәнияте дә аның өчен чит түгел. Герой үзенең ике як тамырларын да тигез күрә, алар турында мәгълүмат та күзәтү характерында. Мәсәлән, ике яктагы

«дед» һәм «бабай» – икесе дә сугыш ветераны, алар бер-берсеннән, берсенең музыка яратып, икенчесенең яратмавы белән генә аерыла. Автор ике милләт кешесен янәшә куеп, ике халыкның якынлыгын, гади кешеләрнең аерылмавын күрсәтә.

«Город Брежнев» романында, сирәк булса да, татар теленә караган лексика да кулланыла. Бу лексик берәмлекләр, бер яктан, шул чордагы үсмерләрнең Татарстан халкына хас сөйләм үзенчәлекләрен чагылдырса, икенче яктан, милли үзбилгеләнешне күрсәтүче сәнгать чарасы булып тора. Мәсәлән, Шамил Идиатуллин яратып куллана торган «айда» сүзе татар телендәге «әйдә» сүзеннән алынган. Геройларның татар акценты белән сөйләшүләре дә милли элемент буларак кулланыла. Мәсәлән, романда татар телен белмәгән үсмерләрнең үз сөйләмнәрендә татар сүзләрен куллануы «сомнение бар?», рус телендә сөйләшкәндә махсус акцент белән сөйләү «аббизатильна» (обязательно) күзәтелә.

Йомгак ясап әйткәндә, Шамил Идиатуллинның «Город Брежнев» романы – беренче карашка бары үсмерләр тормышын, совет чоры гаиләләрен, производствоны тасвирлаган әсәр. Әмма татар халкы тормышын, тарихын, милли проблемаларны яктыртуы белән аның татар әдәбияты үрнәге булуын да күрү кыен түгел. Романда татар халкы өчен бүген дә актуаль туган тел, аны саклау мәсьәләсе турында сүз бара, хәзергә кадәр бәхәсле катнаш никахлар тасвирлана. Геройларның кабул итүе аша милли традицияләр, халыкка хас характер үзенчәлекләре ачыла. Романда гаилә, гаиләдә ата культы, бала тәрбиясе, хатын-кызның роле кебек күренешләр татар халкының бу мәсьәләләргә карашын ачыклый.

Шамил Идиатуллин иҗаты, рус телле укучыларны татар дөньясы белән таныштыруы ягыннан да әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

*Ибрагимов М.И.* Национальная идентичность татарской литературы: современные методы исследования: очерки. Казань, 2018. 104 с.

*Ибрагимов М.И.* Национальная идентичность литературы: пособие для учителей-словесников. Казань: Школа, 2016. 94 с.

*Идиатуллин Ш.* Город Брежнев: роман. СПб.: Азбука, Азбука-Аттикус, 2018. 704 с.

*Кулагин С.А.* Проблема национальной идентичности в прозе А.И. Куприна: автореф. ... канд. филол. наук. Тамбов, 2009. 24 с.

*Малахов В.С.* Неудобства с идентичностью // Вопросы философии. М.: Наука, 1998. № 2. С. 43–53.

*Султанов К.К.* Русскоязычная литература как культурный феномен и объект исследования // Stephanos. 2016. № 3 (17). С. 154–162.

URL: https: // www.business-gazeta.ru/article/392445 (дата обращения – 25.05.2020).

***Чугунов Александр Сергеевич,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 82.091

*Ә.М. Закирҗанов*

# ФАТЫЙХ КӘРИМИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭСТЕТИКАСЫ

Статья посвящена анализу творчества писателя-просветителя Фатиха Карими. В своих произведениях он поднимал вопросы развития татарского народа на основах образованности и культуры. Автор на первый план выводит образованного, воспитанного, радеющего за интересы народа просвещенного героя, борющегося против невежества, религиозного фанатизма.

**Ключевые слова:** просветительство, татарская литература, Фатих Карими, новый герой, мотив, идея.

The article is devoted to the analysis of the creative work of the writer-educator Fatikh Karimi. In his works, he raised issues of development of the Tatar people on the basis of education and culture. The author brings to the fore an educated, well-bred, enlightened hero who cares for the interests of the people, fights against ignorance and religious fanaticism.

**Keywords:** enlightenment, Tatar literature, Fatikh Karimi, new hero, motive, idea.

XIX гасыр урталарында Россиядә көчәеп киткән икътисади һәм иҗтимагый үзгәрешләр татарлар яшәгән төбәкләрдә мәгърифәтчелек хәрәкәтенә юл ача. Аның асылы яшәп килгән һәртөр торгынлыкка, дини фанатизмга каршы көрәшүгә һәм халыкны бәхетле тормышка чыгару максатында җәмгыятьне акыл, белем, югары әхлак нигезендә үзгәртүгә кайтып кала [Юзеев, с. 144]. Г. Утыз Имәни, Г. Курсави кебек шәхесләр эшчәнлеге белән башланган яңару хәрәкәтен Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәезхановлар күтәреп ала, аларга М. Акъегетзадә, З. Бигиев, М. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Й. Акчура, С. Максудилар килеп кушыла. Гасыр ахырында татар Яңарышының яңа баскычы рәвешендә таралыш алган җәдитчелек яшәешнең икътисад һәм сәясәт өлкәләренә дә тирән үтеп керә. Җитди мәсьәлә буларак, ислам динен реформалаштыру алгы планга чыга һәм җәмгыятьнең барлык тармакларын үз эченә ала. Гомумән, татар дини реформаторлыгы, иҗтимагый һәм фәлсәфи фикернең бер өлеше буларак, халыкны яңача фикерләүгә әзерләүдә зур урын алып тора [Очерки, с. 112]. Мәдәният өлкәсендәге үзгәрешләр белән бергә, татар халкы, милли үзаңы үсеше аша, сәяси хокуклар өчен тыныч юл белән көрәшкә тартыла [Исхаков, с. 8].

Татар җәмгыятендә башланып киткән үзгәрешләр әдәбиятка да көчле йогынты ясый. Мәгърифәтчелек, соңрак җәдитчелек идеяләре нәкъ менә матур әдәбият аша (газета-журналлар булмаган шартларда) киң халыкка килеп ирешә. Татар әдәбияты Яңарыш идеологиясен

үзенә нигез итеп ала һәм реализм юлына чыга. Мәгърифәтчелек, яңалык өчен мәйдан әзерләүче фәлсәфи, этик һәм эстетик карашлар системасы буларак, беренче чиратта, халыкны аң-белемле итүне, әхлак сыйфатлары тәрбияләүне алга чыгара. Шуңа да мәгърифәтчеләрнең караш-фикерләрен әдәби әсәрләрдә чагылдыручы язучылар әхлакый кануннарга нигезләнеп яшәүче мәгърифәтле кеше тормышта бәхетле була дип ышаналар.

Яңа чор татар әдәбиятының нигез ташларын салышкан, аның реализм һәм халыкчанлык юнәлешендә үсеп китүенә, әдәби-эстетик яктан баюына, төрләнүенә җитди өлеш керткән күренекле шәхесләрнең берсе – әдип, педагог, журналист Фатыйх Кәрими. Ул XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар әдәбиятындагы сыйфат үзгәрешләренә, мәгърифәтчелек эстетикасының төп үзенчәлекләрен ачуга, киләчәктә юл ярачак тема-проблемаларның, агым-юнәлешләрнең нигезен билгеләүгә үзеннән зур өлеш кертә [Госманов]. Язучы буларак эшчәнлеген XIX йөзнең 90 нчы еллары урталарында башлый һәм бер-бер артлы «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1898), «Шәкерт илә студент» (1899), «Нуретдин хәлфә» (1900), «Морза кызы Фатыйма» (1901), «Тәрбияле мужик» (1905), «Хыялмы, хакыйкатьме?» (1908), «Солтан гыйшкы» (1908), «Телсез хатын» (1908), «Һай, шайтан кыз» (1908), «Яшьлек гөнаһлары» һ.б. хикәя-повестьлары басылып чыга. Ул Әхмәд Мидхәднең «Яшьлек-җүләрлек», «Белгеч кыз» әсәрләрен, русчадан «Кайнана»(1901) хикәясен татарчага тәрҗемә итә.

XIX йөз ахырына татар әдәбияты мәгърифәтчелек эстетикасын үзләштерүгә әзер була. Борынгы һәм Урта гасырлардан килгән традицияләргә таянып, Шәрык һәм рус-Европа әдәбиятлары йогынтысын тойган хәлдә, әдәбият яңа сыйфат үзгәрешләренә күчә бара. Алдарак М. Акъегетзадә, З. Бигиев, ә инде ике гасыр чигендә Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Р. Фәхретдин, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев һ.б.ның уннарча хикәя-повестьлары, романнары дөнья күрә. Татар әдәбияты чынбарлыкны төп сурәтләү объекты итеп алып, кеше яшәешен тулы ачу юлларын эзли. Укымышлы, әхлакый кыйммәтләрне үзендә булдырган һәм халык мәнфәгатен кайгыртып яшәүче идеаллаштырылган герой алгы планга чыга. «Үз чорының иң алдынгы фикер-карашларын, хәтта әле хыял гына булган максатларны да тормышка ашыручы һәр яктан килгән камил кешене мәгърифәтче әдипләр аеруча яратып, җентекле тасвирладылар» [Бәширов, б. 41–42]. Сурәтләүдә реализм өстенлек итсә дә, авторлар романтик сурәт чараларын да чит итмиләр. Әлеге үзенчәлекләр Ф. Кәрими иҗатында шактый тулы чагылыш табып кына калмый, бәлки ул байтак башлангычларга үзе нигез сала. Әдипнең басылып чыккан беренче әсәре булган «Салих бабайның өйләнүе» хикәясенең эчтәлеген Салих бабайның егет вакытта өйләнү вакыйгасы билгели. Зур булмаган күренешләрдә егет белән кызның якты образлары калкып чыга. Ачык буяулар белән бирелгән сурәтләр, яшьләрнең табигый хисләрен, мөнәсәбәтләрен сәнгать дәрәҗәсенә

күтәреп бирү, кешегә, яхшылык һәм матурлык тантанасына ышану, мәхәббәт хисенең күңел дөньясын, яшәү мәгънәсен билгеләүче тойгы итеп бирелүе әсәрне романтик төсмерләр белән баета. Хис-кичерешләр байлыгы табигать күренешләре, чегәннәр турындагы публицистик мәгълүматлар белән кушылып, хикәягә эмоциональ тәэсирлелек, оптимизм бирә. Зур булмаган күренешләрдә гомумиләштерелгән ил карты образы калка. Әлеге герой белән татар әдәбиятында халыкның яшәү тәҗрибәсен үзендә туплаган, гореф-гадәтләргә таянып гомер итүче, киләчәккә дә өмет-ышаныч белән караучы татар картының мәһабәт образын сурәтләү башлана. Ф. Кәрими көнкүреш вакыйгасын сурәтләгән хикәя жанрына нигез сала һәм ул XX йөз башында Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һ.б. иҗатында тотрыклы юнәлеш төсен ала.

Әлеге чорда татар җәмгыятендәге үзгәрешләрне хатын-кыз язмышы белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү күзәтелә. Дөрес, бу проблема барлык авторларда да бер дәрәҗәдә чагылыш тапмый. Әйтик, М. Акъегетзадәнең Хәнифәсе («Хисаметдин менла») укый-яза белә, һөнәргә ия, ә менә Р. Фәхретдиннең Гайшә һәм Әсмасы («Әсма яки Гамәл вә җәза») башкача: Гайшә абыстай, яхшы белем алып, ире Габбасның укымышлы, әхлаклы булып формалашуына зур көч куя, кызлары Әсма да мөгаллимә булып җитешә. Әлеге хатын-кызларның укымышлы, әхлаклы булулары аларны шәхси иреккә ирешүгә, гаиләдә, җәмгыятьтә үз урыннары өчен көрәшүгә китерә. Автор фикеренчә, әнә шундый хатын-кызлар милләтебезнең терәге булып тора. Алдагы чорда исә Г. Исхакый «милләт анасы» символына әверелгән хатын-кыз образлары иҗат итә. Ф. Кәрими дә бу мәсьәләне читләтеп үтми. Мәгърифәтчелек романтизмының матур үрнәге булган «Морза кызы Фатыйма» повестенда, әдәбият галимнәре күрсәткәнчә, И. Гаспралының этисе Мостафаның өйләнү тарихы сурәтләнә. Бер-берсен яраткан егет белән кыз, шәхси иреккә омтылып, яшәп килгән тәртипләргә, иҗтимагый карашларга каршы чыгалар. Туган төбәкләреннән качып китеп, үз теләкләренә ирешәләр һәм ата-аналарын да моның белән килешергә мәҗбүр итәләр. Яшәп килгән гадәтләр, социаль тигезсезлек җирлегендә яшьләр белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында конфликт төенләнә һәм шуңа бәйле вакыйгалар тыгыз, драматик характерда бара. Морза кызы Фатыйма әдәпле, инсафлы бакчачы егет Мостафага гашыйк була һәм үз үрнәге белән аны активлыкка чакыра. Ул шәхси бәхете өчен көрәшергә әзер шәхес булып ачыла. Хикәядә геройларның хис-кичерешләрен, күңел дөньяларын сурәтләүгә киң урын бирелә. Әсәрдә тормышның милли үзенчәлекләренә игътибар итү, киләчәкне сиземләү, тирән оптимизм һ.б. алым-чаралар татар мәгърифәтчелек романтизмына хас сурәтләр булып тора. Автор моңа кадәр татар әдәбиятының нигезен тәшкил иткән Урта гасырлар романтизмын реаль җирлек, көнкүреш материалы һәм мәгърифәтчелек идеаллары белән бәйли һәм яңа чор романтизм әдәбиятының нигезләрен сала. Алдагы елларда әлеге юнәлеш Г. Ибраһимовның «Яшь

йөрәкләр», С. Җәлалның «Дим буенда», Г. Рәхимнең «Идел» кебек классик әсәрләре белән байый.

Реалистик һәм романтик сурәтлелектә яңа башлангычларга нигез салган әдип әсәрләре аша татар җәмгыятенә йогынты ясауның яңа алым-чараларын эзли. Аның аеруча үтемле юлы булып искелекартталыкның мәгънәсезлеген сурәтләү тора. Ф. Кәриминең «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы», «Нуретдин хәлфә», «Шәкерт илә студент» һ.б. хикәяләре наданлык, әхлаксызлык кебек күренешләрне фаш итүгә юнәлдерелгән. Әдип чынбарлыкны танып белүнең яңа баскычына күтәрелә. Ул начарлыкны күрсәтеп, аны кире кагып кына калмый, бәлки усал тәнкыйтьли, фаш итә һәм яңарышның котылгысызлыгын күрсәтә. Реализмның мондый яңа баскычы өчен автор очеркка якын хикәяләүгә мөрәҗәгать итә. Бу исә тормыш күренешләрен документальлеккә якын сурәтләүгә мөмкинлек бирү белән, авторга үз карашларын укучыга тулырак җиткерергә юл ача. «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» хикәясендә иске типтагы уку йортларының, андагы укыту-тәрбия ысулларының тормыш үзгәрешләреннән артта калуы сәнгать чаралары аша тасвирлана. Вакыйга-күренешләргә бәйле әдип бу авылда хөкем сөргән гадәтләрне, кешеләрнең искелек белән гомер итүләрен укучы каршында ача. «Нуретдин хәлфә» хикәясе искелек тарафдары кадимче Нуретдиннең монологы рәвешендә язылган. Әлеге алым Ф. Кәримигә бу социаль катламны эчке яктан күрергә, ахыр чиктә үзен-үзе фаш итү аша тормышка яраксызлыгын сурәтләргә мөмкинлек бирә. Әсәрдә Нуретдин хәлфәнең үткәне белән бүгенгесе, хыял дөньясы үзара үрелеп бара. Әлеге катламнарда аның надан, булдыксыз, мәгънәсез кеше икәнлеге ачыла. Фикерләрен чагылдыруның үтемле чарасы буларак, Ф. Кәрими әсәр композициясенә дә җитди игътибар бирә. Автор геройларын үзләре яшәгән мохиттән аерып ала һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән кискен каршылыкка кертә. Әлеге хикәя немец фәлсәфәчесе Шопенһауэр идеяләре чагылу белән дә игътибарга лаек. Бу фикер иясе тормышны аңлап бетерү авыр дип санаган һәм үз гомерен шул турыда уйлануга багышлавын белдергән. Ф. Кәрими Шопенһауэр фәлсәфәсен Нуретдин хәлфәне фаш итү өчен файдалана. Үз-үзен күбрәк яратучы хәлфә хыялы белән яшәгән вакытта Шопенһауэрның «Дөнья – бер җәһәннәмдер, гакыйль адәм өчен анда яшәмәк лаек түгелдер», – дигән сүзләрен уйлап, аны кире кага. Әлеге каршылыкны сәнгать чаралары аша сурәтләгән Ф. Кәрими кадимчелекне кискен тәнкыйтьли, ә аның бер вәкиле булган Нуретдин хәлфә мескен, кызганыч булып гәүдәләнә.

Мәгърифәтчелек әдәбиятында дини һәм дөньяви белем бирүне яклап чыгу, аны камилләштерү юлларын эзләү алгы планга чыга. Фикер-бәхәсләр укыту эшен системага салу, заманга яраклаштыру, яңа юл-алымнар эзләү турында бара. Дөньяви белемгә омтылыш, әдәбияттагы җитди яңалык буларак, һәрьяклап яклана. Бу, бер яктан, Шәрык, икенче яктан, рус-Европа әдәби-эстетик, фәлсәфи фи-

кере йогынтысы белән дә аңлатыла. Бу урында тагын шуны билгеләп үтик, гыйлем – мөселман мәдәниятенең төп кыйммәтләреннән берсе. Ул кешенең акыл дәрәҗәсен билгеләүче сыйфат булып санала. Мөселман фәлсәфәсе буенча, Аллаһы Тәгалә иң элек нурлар чәчеп, галәм акылын яраткан. Аннан акыл нурлары рәвешендә кешегә дә өлеш чыккан. Кеше акылын зирәк, үткен итү өчен, гыйлем барлыкка китергән. Шуңа да Урта гасырлар Шәрык һәм Гареб әдәбиятларында Акылны, Гыйлемне, Сүз сәнгатен мактауга зур урын бирелә [Ганиева]. XIX гасыр урталарыннан башлап татар әдәбияты әлеге традицияне чор, заман үзгәрешләренә, таләпләренә нигезле үстерә, алга куя. Мәгърифәтчеләр дини гыйлем кешенең рухына, җанына азык булса, дөньяви гыйлем тормыш өчен кирәк, диләр. Аның уңышлы үрнәге белән Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» хикәясендә очрашабыз. Әсәрдә Казаннан Чистайга пароход белән бару вакыйгасы сурәтләнә һәм искелек тарафдарлары булган ишан, аның бай мөриде, хәзрәт кияве һәм пишкадәмнең фикер-карашлары башка сәяхәт кылучыларга капма-каршы буларак ачыла. Хикәядә чор таләбе булып яңгыраган әдәпле булу, мәдрәсәләрдә уку-укыту эшләренең торышы, мөселманлыкның асылын, Коръән тәгълиматын дөрес аңлау кебек мәсьәләләр милләт язмышы белән бәйләп карала. Әдип халыкның матур сыйфатларын үзләрендә булдырырга тиешле дин әһелләренең, аларга якын кешеләрнең мәгънәсезлекләре өчен җан ачысы белән борчыла һәм моны я әйләнә-тирәдәгеләр тарафыннан тәнкыйть иттерә, я студент фикерләре рәвешендә аңлата, я хикәяләүче сыйфатында алардан сарказм белән көлә.

«Хыялмы? Хакыйкатьме?» исемле әсәре белән Ф. Кәрими Дәүләт думасы депутаты эшчәнлегенә бәйле сәяси тематика алып килә. Автор үзенең әдәби, иҗтимагый фикерләрен беренче карашка сәер булып тоелган сюжетка бәйләп ача. Депутат хыялында гына туа алырдай кыз белән очраша, ахырда исә анысы серле рәвештә юкка да чыга. Депутат зур хыяллар, планнар белән төрки халыкларга ярдәм итү теләге белән яши. Ул тормыштагы социаль каршылыклар өчен борчыла. Ф. Кәрими, мөселман депутатларының бергә эшләү программасын биреп, И.Гаспралы карашларын яклавын сиздерә. Әдип депутатның күңел дөньясын, каршылыклы уйларын күрсәтә, аннан ирония белән көлә дә. Идеаллаштырылган кыз образы аша хатын-кыз мәсьәләсенең кискенлеген, әһәмиятен ачу максат итеп куела. Хатын-кызны ул милләт анасы буларак һәм халыкның киләчәге белән бәйләп карый. Әсәрдәге кыз образының Р. Фәхретдиннең «Сәлимә»сендәге университет тәмамлаган, инглиз, француз телләрен белүче Иран бае кызы Сәлимә белән якынлыгын күрми мөмкин түгел. *«Бу заманда гыйлемсез яшәмәк – мөмкин улмадыгы, (...) хатыннары тәрбия вә тәгълим күрмәгән милләтләр инкыйразга дучар улачаклар...»* дигән кискен фикерләре белән автор юкка чыгудан котылуның бер юлын тәкъдим итә.

Шулай итеп, Ф. Кәрими әсәрләренә рационализм хас. Аның тискәре геройлары тулы канлы характер булудан бигрәк, үз катлавын

ачыклаган берьяклы билгеләр, сыйфатлар белән тасвирлана. Әдип акыл, белем, тәрбия көченә ышана. Аның күпсанлы әсәрләре артында вакыйга-күренешләргә бәя бирүче авторның үз образын күрәбез. Татар тормышындагы тискәре күренешләрне җан сыкравы белән сурәтләвендә әдипнең милләтен яратуы, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылуы һәм тирән ышанычы да чагылыш таба. Татар милли яңарышының нигез ташларын салышкан Фатыйх Кәрими яңа тема-мотивлары, үзенчәлекле геройлары, сурәтләүнең яңа алым-чаралары, фәлсәфи һәм эстетик карашларны тыгыз бәйләнештә бирүе белән татар әдәбияты тарихында лаеклы урын алып тора.

**Әдәбият**

*Бәширов Ф.* Проза // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 4 т.: XX йөз башы [фәнни мөх. Р.К. Ганиева]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 41–63.

*Ганиева Р.* Философско-эстетические основы тюркских литератур средневековья / Р. Ганиева // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 14–23.

*Госманов М.* Әдипнең намус көзгесе // Мәдәни җомга. 2000. 7 апрель.

*Исхаков Д.* Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. Казань: Иман, 1997. 79 с.

*Юзеев А.* Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. 192 с.

*Очерки* истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 191 с.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы***,
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

УДК 82.091

***Ә.А. Гатин***

# ТАТАР ДӨНЬЯСЫНА ЕВРОПАДАН БЕР КАРАШ: Арминий Вамбери һәм Фатыйх Кәрими

Статья посвящена исследованию взаимоотношений между венгерским тюркологом А. Вамбери и татарским писателем, педагогом Ф. Карими. Заочная дружба между двумя изучаемыми деятелями оказала на них заметное влияние. Особое внимание уделено оценке Арминием Вамбери культурного прогресса татарского народа в конце XIX – начале XX в. А. Вамбери был первым европейским ученым, который исследовал татарский джадидизм, а сотрудничество с Ф. Карими помогало ему получать татарские книги и газеты, издаваемые в России.

**Ключевые слова**: тюркология, татары, джадидизм, татарская литература, Оренбург. Вамбери, Фатих Карими.

The article is devoted to relations between the Hungarian Turkologist Armin Vambery and the Tatar writer, teacher Fatikh Karimi. The correspondence friendship between the two studied figures had a noticeable influence on them. The great attention is paid to A. Vamberi’s assessment of the cultural movement among the Tatars in the late XIX – early XX centuries. A. Vambery was the first European scholar who studied jadidism. His cooperation with F. Karimi helped him to get Tatar books and newspapers from Russia.

**Keywords:** Turcology, the Tatars, jadidism, Tatar literature, Orenburg, Vambery, Fatikh Karimi.

1907 елда Арминий Вамбери алман телендә «Die Kulturbestrebungen der Tataren» («Татарлар арасында мәдәни хәрәкәт») исемле мәкалә яза һәм 5 елдан соң ул рус теленә тәрҗемә ителеп басыла [Вамбери, 1912, с. 276–302]. Әлеге мәкаләнең язылу һәм рус теленә тәрҗемә ителү сәбәпләре XX йөз башында Россиядә барган үзгәрешләр белән бәйле булган. 1905 елда Россия империясендә башланган Беренче рус инкыйлабы рус халкын һәм башка милләтләрне хәрәкәткә китерә. Арминий Вамбери үзенең мәкаләсендә Россия мөселманнарының яңалыкка, реформаларга омтылышын тасвирлаганда, Кырымда һәм Идел-Урал буенда яшәүче татарларда барган үзгәрешләрне аеруча искәртеп уза. Бу мәкалә Яңа заман Европа фәнендә, беренчеләрдән булып, татар халкының иҗтимагый һәм сәяси хәрәкәтен җентекләп аңлатырга тырышкан хезмәт булып санала ала. Ә инде рус теленә тәрҗемә ителүенең сәбәбе – безнеңчә, аның эчтәлекле булуында. Европада яшәгән галимнең Россия мөселманнары хәрәкәтенә игътибарлы булуы, әлбәттә, Россия галимнәрен дә кызыксындырган. Әйтергә кирәк, А. Вамбери исеме Россия галимнәренә һәм сәясәтчеләренә 1860 еллардан ук таныш була, ул язган китаплар рус теленә тәрҗемә ителеп тора, ләкин Россия хөкүмәте Вамберины күбрәк үзенә дош-

ман дип саный. Кем соң ул А. Вамбери һәм ни өчен ул татарлар белән кызыксынган? Мәкаләдә әлеге сорауга җавап бирергә тырышырбыз.

Герман (Арминий) Вамбери (Armin Vambery, 1832–1913) Австро-Венгриядә ярлы дини яһүд гаиләсендә дөньяга килә. Үзенең автобиографиясендә ул, авыр балачагын тасвирлаганда, яшьтән үк белемгә һәм телләр өйрәнүгә омтылуын әйтеп уза. Кызыксынучан һәм үз максатына ирешүчән булуы аңа башта чит телләрне үзләштерергә, аннары, чит телләр ярдәме белән, дөнья гизәргә мөмкинлек бирә. Яшь чакта маҗар халкының килеп чыгышы белән кызыксынуы аны башта борынгы маҗарларның ватаннарын эзләп китәргә этәрсә, соңрак фәнни эзтабарлыгы аның исемен фән дөньясында таныта. Моны ул үзенең автобиографиясендә дә аңлата [Вамбери, 1914]. XIX гасырда зур фәнни һәм мәдәни үсеш кичергән Европа халыклары үз тарихын, килеп чыгышын өйрәнүгә керешә, һәм бу Европа галимнәрен дөнья буйлап тарихи эзләнүләргә этәрә. Шундый халыклар арасында маҗарлар да була. Маҗар теленең Алтай телләре гаиләсенә якын булуы билгеле булса да, аның төрки яисә фин-угор гаиләсе төркемнәренә керүе турында XIX йөз уртасында төгәл фикер булмый. Бу сорауга җавап бирү максаты белән һәм шулай ук маҗарларның ерактагы ватаннарын эзләп табу өчен, Вамбери төрки телләрне өйрәнергә керешә һәм Урта Азия җирләренә барып чыга. Бу кыю планнарны тормышка ашырыр өчен, бер генә тарихи нигез була: борынгы маҗар чыганакларында халыкның каяндыр көнчыгыштан килүе турында әйтелә. Ул Истанбулда берничә ел яшәп, ислам мәдәнияте, төрек теле аркылы төрки халыклар телләре белән якыннан таныша, һәм шуннан соң Азиядә урнашкан Бохара, Хива дәүләтләренә барып кайтуны максат итә. Берничә елга сузылган сәяхәте вакытында башта Иранга барып җитә, Тәһранны, төрекмән җирләре аша, Хива, Бохара, Әфганстан җирләрен күреп кайта. Сәяхәте вакытында ул үзенең Европа кешесе булуын танытмас өчен, хаждан кайткан дәрвиш шикелле киенә, хәтта язмаларын гарәп хәрефләре белән язарга тырыша [Вамбери, 1865]. Күргән, кичергән вакыйгалар турындагы язмаларын китап өчен туплый бара. Вамберының 1865 елда инглиз телендә басылган «Урта Азиядә сәяхәт» исемле китабын Европа галимнәре һәм сәяси катламнар кыйммәтле чыганак буларак кабул итәләр, чөнки Маҗарстан сәяхәтчесе, беренчеләрдән булып, Урта Азия халыклары һәм дәүләтләре турында үз тырышлыгы белән төгәл һәм тәфсилле мәгълүматлар җыюга ирешә [Vambery, 1865]. Шулай итеп, сәяхәте һәм китабы аның исемен бик тиз таныта, һәм шуннан соң Арминий Вамберының фәнни эшчәнлеге башлана. Дөнья күргән китабы бигрәк тә Бөек Британия мәнфәгатьләренә хуш килә. Гомерен маҗар тарихын, төрки телләр, Госманлы дәүләте мәдәниятен өйрәнүгә багышлаган галим зур сәяси үзгәрешләрләрдән дә читтә калмый. Бөек Британия аның фикеренә колак салырга мәҗбүр була, чөнки Вамбери Урта Азиядән кайту белән, Россия империясе Хива, Бохара, Коканд дәүләтләрен яулап алуга, ә Бөек Британия әфган (пуштун) кабиләләрен буйсындыруга керешә – әлеге «Зур уен»

барганда, А. Вамбери үз фикерләрен Бөек Британия матбугаты аша җиткерергә тырыша. Шуңа күрә Россия галимнәре һәм түрәләре Вамберины Бөек Британия тарафдары, шпионы буларак кабул итәләр һәм бу аяныч факт аның Россиягә сәяхәт кылуына киртә булып тора. Шуңа карамастан, А. Вамбери гомер буе Госманлы дәүләте тормышы, ислам дөньясының халәте белән даими рәвештә кызыксынып торган, шул исәптән ул Россия империясе эчендә яшәгән мөселман халыклары тормышын да игътибар үзәгеннән читкә җибәрмәгән. Шуңа күрә XIX йөз ахыры – XX йөз башында танылган галим матбугат битләрендә ислам дөньясы белгече, эксперты буларак та бәяләнә.

XIX йөз ахырында Россия мөселманнары яшәгән җирләрдә йөрмичә генә аларның тормышын өйрәнүнең ике генә юлы кала. Беренчесе алар үзләре бастырган һәм тараткан әсәрләрне, китапларны уку булса, икенчесе – аралашып тору, хатлар алышу. Россия мөселманнары арасында А. Вамбери берничә татар зыялысының эшчәнлеге белән кызыксына, шулар арасында И. Гаспралы, Ф. Кәрими. Р. Фәхретдин исемнәре дә бар. Ф. Кәрими белән А. Вамбери берничә ел дәвамында хат язышып тора һәм аларның аралашулары икесе өчен дә файдалы була. А. Вамбериның архивта сакланган хатлары белән танышкач, әлбәттә, шундый сорау туа: алар ничек танышып киткәннәр һәм бу ике шәхесне нәрсә бәйләгән соң?

Ф. Кәриминең күренекле тюрколог белән танышкан урыны һәм сәбәпләре безгә төгәл билгеле булмаса да, җыелган фактлар аларның танышу тарихы Истанбулдан башланган дияргә нигез бирә. 1892–1896 елларда Ф. Кәрими Госманлы дәүләтенең башкаласында «Mekteb-i Mülkiyye-i Şâhâne» исемле уку йортында укый һәм шул вакытта А. Вамбери белән очраша, алар арасында мөселманнар тормышы турында җентекле сөйләшү була. Әңгәмә яшь Фатыйхның күңеленә кереп кала. Бераздан, укуын тәмамлап, 2 ел дәвамында Ф. Кәрими Кырымда Даракөй авылында мөгаллим булып эшли һәм 1898 елның башында Кырымнан Будапештка хат юллый. Хатта ул А. Вамбери тарафыннан басмага әзерләнгән «Die Scheïbaniade: ein özbegisches Heldengedicht in 76 Gesängen» (Budapest, 1885)[1] китабын җибәрүне үтенә. 1898 елның 30 апрелендә язылган җавабында галим татар дустына рәхмәтен белдерә һәм үзенең башка китаплары турында да хәбәр итә. Аларның хат аша дуслыгы аеруча 1905–1908 елларда нығый. Ә. Вамберины Россия мөселманнарының тормышы, иҗтимагый хәрәкәтләре кызыксындыра. Шул вакытта чыга башлаган татар газеталары, басылган китаплар аңа килеп ирешә тора – алар аркылы карт галим ерактагы Россия мөселманнары тормышын өйрәнә, һәм нәкъ менә

[1] XVI йөзнең беренче яртысындагы Урта Азия тарихын тасвирлаучы чыганак – «Шәйбәнинамә» исемле китап – 1885 елда беренче тапкыр нәкъ А. Вамбери тарафыннан бастырыла һәм шуннан соң Европа һәм Россия галимнәре тарафыннан өйрәнелә башлый. А. Вамбери әзерләгән басмада Россия галимнәре шактый күп хаталар тапсалар да, тюркология тарихында бу басма кыйммәтен һәм әһәмиятен югалтмый. Шулай ук бу китапның Европада гарәби археография үсеше өчен дә әһәмияте зур.

шул материаллар нигезендә ул алда телгә алынган «Татарлар арасында мәдәни хәрәкәт» исемле мәкаләсен язган дип әйтергә мөмкин.

Россия мөселманнары арасында ул татар халкы вәкилләрен аерым ассызыклап китә. Иҗтимагый хәрәкәт башында торган Исмәгыйль Гаспралыны һәм «Тәрҗеман» газетасын беренче урынга куеп, аның уңышлы тактикасын түбәндәгечә аңлата: 20 ел дәвамында ул муллаларны турыдан-туры тәнкыйть итмичә, алдынгы карашлы һәм укымышлы мөселманнарның игътибарын җәлеп итә һәм газета битләрендә акрынлап мөселманнарның артталыгын, ислам диненең гыйлемгә нигезләнүен һәм укыту эшен яңарту зарурлыгын күрсәтә. Татар язучылары, мәгърифәтчеләре арасында кырымлы Исмәгыйль Гаспралы, Госман Нури Акчокраклы, казанлы Каюм Насыйри белән беррәттән, Фатыйх Кәрими исеме дә искә алына. Ф. Кәриминең ул чакта язучы, мөгаллим булып танылуы билгеле, ләкин А. Вамбери күзәтүендә аның исеменең берничә урында телгә алынуын башка сәбәп белән дә аңлатырга мөмкин. Хат алышкан чорда А. Вамбери Ф. Кәримидән китаплар соратып ала, алар арасында Оренбург басмалары булуы да билгеле (шул исәптән Ф. Кәрими язган әсәрләр дә). Шулай итеп, аларның дуслыклары Вамберига татар тормышы белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә, ә Ф. Кәрими татарлар арасыннан аның иң якын танышы була.

Татар әдәбиятын тикшергәндә галим-тюрколог татар язучыларының кыю фикерләренә игътибар итә. Аның карашынча, татар әдипләре кадими муллаларны тәнкыйтьләүләре белән төрек язучыларыннан һәм Һиндстан зыялыларыннан аерылып тора, чөнки Госманлы дәүләтендә һәм Бөек Британия колонияләрендә имамнарны, дин галимнәрен ачыктан-ачык тәнкыйтьләү очраклары аңа билгеле булмый. Ф. Кәриминең «Кырымга сәяхәт» китабын ул шуңа мисал итеп китерә. Фатыйх Кәриминең кадими мәдрәсәләрне һәм мөгаллимнәрнең укыту ысулларын тәнкыйтьләвен ул бик кыю һәм моңа кадәр ислам дөньясында күрелмәгән бер хәл дип саный, авторны Көнбатыш мәгарифе тарафдары буларак сыйфатлый.

А. Вамбери, беренчеләрдән булып, Европа халкын татарларның Беренче рус инкыйлабы вакытында башланган сәяси хәрәкәте белән таныштыра, 1905–1906 елларда узган Россия мөселман җыелышлары турында яза. Татарларның сәяси эшчәнлеген ул феноменаль күренеш дип бәяли. Беренче рус инкыйлабының татар җәмгыятенә тәэсирен түбәндәгечә тасвирлый: *«Тыйнак, моңарчы тыныч һәм аек яшәгән тугрылыклы татарларга ул аеруча көчле йогынты ясаган»*. Аның фикеренчә, татар халкы борынгы ислам үзәкләреннән ерак булу сәбәпле, дини яктан «примитив» шартларда яшәде, дини йолаларга күбрәк игътибар бирде һәм шул сәбәпле яңалыкка сусаган иде. Галимнең татар халкына мондый карашы, аны артта калган, түбән дәрәҗәдә торучы халык дип бәяләве безне гаҗәпләндерергә тиеш түгел. XX йөз башында Европа халыкларына хас бу караш татарларга гына түгел, күпчелек (бәлки, Япониядән башка) Көнчыгыш

халыкларына да кагылган. Колониаль империяләр заманында Россиядә яшәгән мөселманнарга Европа галимнәре дә колониаль халык дип караган. А. Вамбери фикеренчә, татарлар өстеннән басым иҗтимагый хәрәкәт өчен уңайлы шартлар тудыра, чөнки патша хакимияте мөселман халыкларында эчке реформаларны туктатырга ашыкмый, эчке процесслар һәм хәрәкәтне начар күзәтеп, барлыкка килгән үзгәрешләрне дини яктан берничек тә тикшерми. Әлбәттә, хәзер галимнең кайбер фикерләре белән тулысынча килешмәсәк тә, аның карашларын нигезсез булган дип санарга ярамый, чөнки ул нәтиҗәләр төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларга таянып ясалган, алар арасында Оренбургта чыгучы «Вакыт» газетасы да мөһим роль уйнаган (баш мөхәррире Ф. Кәрими).

Шунысын да әйтергә кирәк: А. Вамбери Россиядә яшәгән мөселман халыклары белән галим буларак кызыксынган. Урта Азия, Госманлы дәүләте, Иран территориясендә яшәгән төрки халыкларның гореф-гадәтләрен үз күзләре белән күргән галим гомер буе аларның телләрен дә өйрәнгән. Эчке Россиядә яшәгән төрки халыкларның телләре дә аның игътибар үзәгендә булган. Гомумән, XIX йөзнең икенче яртысында – XX гасыр башында Идел-Урал буенда яшәүче халыкларны өйрәнү максаты белән Австро-Венгриядән галимнәр күп килә. Алар арасында А. Вамбери аерым урын алып тора. Ул тюркологлар арасында «Etymologisches Wörterbuch der Turko-Tatarischen Sprachen» (Leipzig, 1878) исемле тәфсилле хезмәте белән билгеле. Анда уйгур, кыргыз, казакъ, төрекмән, Алтай халыклары, якут, Анатолия төрекләре, чагатай, азәрбайҗан, госманлы-төрек телләре белән беррәттән, татар теленең казан сөйләше дә урын алган. Галим телләрне чагыштыру һәм тарихи реконструкция нигезендә сүзләрнең килеп чыгышын тикшерә, төрки сүзләрнең борынгы тамырларын билгели.

Ф. Кәрими үзенең хатларында галимне татар зыялылары белән таныштыра, шул исәптән Р. Фәхретдин, татарлар арасында барган мәдәни һәм иҗтимагый хәрәкәт турында яза. Һәм, әлбәттә, алар икесе дә төрекләр тормышы белән кызыксына. Балкан сугышлары башлангач, Европа дәүләтләре кабат Госманлы дәүләтенең җиңелүен тели. Россиядә бу сугышларны матбугат битләрендә дини (цивилизацион) бәрелеш – ярымай һәм хач сугышы буларак күрсәтәләр. А. Вамбери үзенең татар дустына 1913 елның 26 маенда язган соңгы хатында төрекләрнең җиңелү сәбәпләрен аңлатырга тырыша; ул аларны наданлыкта, тәкәбберлектә, рухи кризиста гаепли, төрекләрдә милли һәм патриотик хисләрнең аз булуын ассызыклый. Шул ук вакытта татар халкының тиз үсешенә игътибар итеп, татарларны мактый, бигрәк тә тел үсешенә зур әһәмият бирә. Тел бәхәсен башлап җибәргән «Шура» журналын мисалга куя. Чынлап та, тел реформасы турында галим үзенең «Татарлар арасында мәдәни хәрәкәт» мәкаләсендә дә яза һәм аның иҗтимагый үсеш өчен әһәмиятле булуын ассызыклый, «Вакыт» газетасы битләрендә басылган мәкаләләр аңа бу мәсьәләне аңларга бик нык ярдәм итә.

«Вакыт»ның баш мөхәррире вазифасын үтәгәндә, Ф. Кәрими газета битләрендә үзенең ерактагы дусты белән укучыларны да таныштыра. Мәсәлән, 1907 елның февраль санында (№ 119) ул «Профессор Вамбери вә Русия мөселманнары» исемле мәкаләсен урнаштыра, ә галимнең үлеме турындагы хәбәр Оренбургка килеп ирешкәч, аерым мәкалә-некролог бастыра.

Ике шәхес арасында дуслык хат алышу белән генә чикләнмәгән. Аралашу һәр икесе өчен дә файдалы булган: А. Вамберига ул ерактагы татар дөньясын күзәтү өчен «тәрәзә» булса, абруйлы тюрколог-галимнең фикерләре Ф. Кәримигә татар иҗтимагый хәрәкәтен бәяләргә ярдәм иткән.

**Әдәбият**


*Вамбери Г.* Культурное движение среди русских татар // *Гольдцигер И.* Лекции об исламе. СПб., 1912. С. 276–302.

*Вамбери Г.* Моя жизнь / авториз. пер. с англ. и предисл. В. Лазарева. М., 1914. VII, 408, 2 с.

*Вамбери Г.* Путешествие по Средней Азии в 1863 году / пер. с англ. СПб., 1865. II, II, II, 221 с.

Письма Вамбери Фатиху Каримову // ГАРТ, ф. 1370, оп. 1, д. 18.

Фатыйх Кәрими: фәнни-биографик җыентык = Фатих Карими: научно-биографический сборник / төз.: Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. 320 б.

*Vambery A.* Travels in Central Asia. New York: Harper & Brothers Publishers, 1865. 493 p.



***Гатин Әскәр Александрович,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 82.091

*Д.М. Абдуллина*

# МӘҖИТ ГАФУРИ ИҖАТЫНЫҢ ИДЕЯ-ТЕМАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В этой статье представлен обзор творчества народного поэта М. Гафури. Анализировались идейно-тематические особенности его произведений. Более подробно остановливаясь на проблемах, поднятых писателем в отношении судьбы нации, была сделана попытка раскрыть его отношение к татарскому народу и татарскому языку.

Статья посвящена 140-летию со дня рождения народного поэта М. Гафури.

**Ключевые слова:** М. Гафури, творчество, идея, тематика, судьба татарского народа, нравственные ценности.

This article provides an overview of the folk poet M. Gafuri's work. The ideological and thematic features of his works were analyzed. Dwelling in more detail on the problems raised by the writer in relation to the fate of the nation, an attempt was made to reveal his attitude towards the Tatar people and the Tatar language.

The article is dedicated to the 140th anniversary of the national poet M. Gafuri's birth.

**Keywords:** M. Gafuri, creativity, idea, theme, fate of the Tatar people, moral values.

Татар һәм башкорт халыклары әдәбияты классигы, XX йөз башы татар милли шигъриятен һәм прозасын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән, тормышчан әсәрләре белән халык күңеленә уелып калган күренекле әдип Мәҗит Гафуриның тууына 2020 елның 1 августында 140 ел тулды.

Гасыр сынауларын үтеп, үз бәһасен дәлилләгән бу иҗатның көче халыкчанлыгында, милли азатлык, кешелеклелек идеалларын чын күңелдән яңгырата алуында. М. Гафури да – замандашларының бик күбесе кебек, үз тырышлыгы белән талантына юл ярган, шуның аша гадилектән галилеккә ирешкән шәхес.

Олы әдипне зур юлга алып чыккан сукмак башы халкыбызга шактый күп талантлы шәхесләрне биргән уңдырышлы Башкортстан туфрагыннан.

Аның тормыш юлы да, үз замандашларыныкынан күпкә аермалы түгел, гыйбрәтле дә, катлаулы да, данлыклы да.

Гыйлем эстәүнең фарыз гамәл булуын гаиләдә үк аңлап үсү, башта авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем алып, соңрак мәртәбәле мәдрәсәләрнең берсендә уку – бу чор зыялылырының һәркайсы үткән юл. М. Гафуриның үсмерлек һәм яшьлек еллары да шуннан аерылмый. Әмма унөч яшеннән тулы ятим калган Мәҗит өчен белем алу бик авырга туры килә. Матди мөмкинлекләре чикле булганлык-

тан, бер мәдрәсәдән икенчесенә күчә. Уфадагы «Госмания», «Галия», Троицкидагы «Рәсүлия», Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый. Җәйләрен, казакъ-кыргыз даласына чыгып, бай балаларын укыта, Рәмиевләрнең алтын, Яушевларның торф приискаларына сезонлы хезмәткә яллана, тиречедә чыра очлый, байларга яллыанып эшләүче кешеләргә ашарга әзерли, икмәк сала, урак ура, мәдрәсәдә сукыр суфиларга китап укый, бай балаларына ашарга пешерә. Белем алуга омтылышы зур булган егет бу юлда барлык киртәләрне дә үтеп чыгарга үзендә көч таба һәм максатына ирешә. Мәдрәсәдә уку еллары аның өчен олы тормыш мәктәбе була.

Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укуының соңгы елларында «Хезмәт» көтепханәсе аша яңа басылган китаплар, көндәлек матбугат белән таныша, «Тәрҗеман» газетасының бер санын калдырмый укып бара, өч ай дәвамында рус телен махсус өйрәнә. Казакълар арасында мөгаллимлек иткәндә, заманына күрә аңлы, яңалык тарафдары булган, үзе дә шигырьләр язарга яраткан Урынтай хаҗи белән аралашу, шәкертләр арасында да искечә укытуга каршы тору, надан хәлфәләрне кире кагу рәвешендә башланып киткән хәрәкәтләрне күрү яшь Мәҗиткә тормыш каршылыкларын тирәнрәк төшенергә ярдәм итә.

М. Гафуриның Казанда «Мөхәммәдия»дә укыган чоры (1905–1906) революцион көрәш киң җәелгән вакытка туры килә. Татар халкының милли азатлык хәрәкәте, Россияне тетрәндергән Беренче рус революциясе үсмер егеткә көчле тәэсир ясый. Күңелендәге хисләр өермәсе тышка бәреп чыга, ул илдә барган сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә туган хыялларын, рухи куанычын халык белән уртаклашырга, бу көрәштә үз авазын ишеттерергә омтыла. «Яшь гомерем» исемле шигырь мәҗмугасын тәмамлап нәшриятка тапшыра. Моннан тыш яңа ачылган «Йолдыз», «Казан мөхбире» кебек газеталарда шигырьләр, мәкаләләр бастыра.

Гади халык тормышын, аның рухын аңлау, ил эчендә барган вакыйгаларны дөрес бәяләрлек дәрәҗәдә сизгер күңелле һәм хәбәрдар булу аның әдәби иҗатына зур мөмкинлекләр ача. Бу уңайдан: «Гафури иҗаты халыкның тарихи эшчәнлегенең сәнгать көзгесендә чагылган җанлы сурәте буларак мәйданга чыкты», – дип язган иде Х. Госман [Госман, б. 104]

М. Гафури әсәрләре идея-тематик яктан гаять киң колачлы. Ул гадәти көндәлек тормыш вакыйгаларына да, шигърият өчен мәңгелек саналган мотивларга да мөрәҗәгать итә. Шундыйлардан тормыш-яшәеш турында фәлсәфи уйланулар («Хәлең», «Күңел тарлыгы», «Кайвакытта», «Тормыш»), табигать һәм кеше («Яз башлануы», «Эңгер вакыты», «Харап бакча»), сөю-мәхәббәт («Беренче мәхәббәт», «Янган йөрәк», «Сөюдән качу») кебек темалар аның иҗатында әледән-әле чагылып тора. Әхлакый темаларны да, сәясәт, туган җир, ил, Ватан мәсьәләләрен дә яратып, теләп яктырта шагыйрь. Әмма шулар арасында гади халык, үз милләтенең язмышына аерым игътибар бирүе сизелә. Иҗатының тәүге чорында:

Бер адым алга басам да
Әйләнәмен артыма,
Кайда басканнар икән дип
Күз саламын халкыма [Гафури, б. 294], –

дип язган булса, бөтен иҗаты дәвамында ул шул мәсләгенә тугрылык саклый. Нинди жанрда гына иҗат итсә дә, күңел түренә кереп утырган гади халык, милләт язмышы аның каләменә юл күрсәтә, әдипнең йөрәген халыкныкы белән бәйли.

М. Гафури иҗатында милли тойгылар гәүдәләнешендә бер нәрсә ачык чагылыш таба: бу – әдипнең үз иҗатында һәрвакыт татар милләтен, татар телен күздә тотуы, үзен шул халыкның бер вәкиле итеп күрүе. Ул бу турыда үзе дә ачыктан-ачык яза: «Шигырь язды Габделмәҗит ибне татар» («Алмашыну», 1905), «Русияле бер татардыр – асыл затым, Габдулла ибне татар – мәшһүр затым» («Яшь гомерем», 1906).

Аның беренче шигырьләрендә үк милләт язмышы мәсьәләсе күтәрелә.Ул әле аны мәгърифәтчелек идеяләре яктылыгында хәл итәргә омтыла. Халыкның белемле, һөнәрле, мәдәниятле булу дәрәҗәсен үстерүне, икътисади һәм мәдәни үсешкә ирешкән халыклар югарылыгына күтәрелүне максат итеп күрә. Иң беренче шигъри тәҗрибәләреннән булган «Гыйлем» шигырендә:

Мәгърифәт бабларын без ачаек,
Тәрикы тәрәккыя без басаек, –

дип өнди. Милли-мәдәни үсешнең асылын да шулай аңлата:

Гакыл сарыф итеп һиммәт итсәк,
Урынның алырбыз һәрдәм түрен [Гафури, б. 419].

Биредә әле аның җәмгыятьтәге һәр кимчелекне наданлыктан күрүе, мәдәни үсеш барлык кешеләргә дә бәхет китерер дип чын күңелдән ышануы сизелә. Шунлыктан аларда үгетләү, коры дидактика өстенлек итә, шагыйрь тәрбиялелек, белем, һөнәр, әдәплелек, милли тәрәккыят мәсьәләләрен күтәрә һәм әлеге камиллеккә ирешү юлларын шәхеснең үз тырышлыгына бәйләп аңлата. Белемле, тәрбияле, һөнәрле шәхеснең милләтпәрвәр булуы да сорала:

Гыйлемеңнең файдасын үзең дә күр,
Файдада милләтеңне үзеңдәй күр;
Гыйлемең берлә милләтеңне иткел син шат [Гафури, б. 411].

Тәрбия мәсьәләсенә килгәндә, халыкның киләчәген күкрәк тәрбиясе белән саклаучы хатын-кызның хокуксызлык һәм наданлык соткынлыгында булуы шагыйрьне иң тирәнтен борчыган мәсьәләләрдән булды. Коллык богауларын өзәрлек көч, хөр шәхес тәрбияләү аның шигъриятендә дә, прозасында да үзәк темага әверелде. «Әйдә, кызым, мәктәпкә», «Зәйнәп» (1907), «Кем бәхетсез» (1910) кебек дистәләгән шигырьләре хатын-кыз киләчәген кайгыртып, аңа мөрәҗә-

гать итеп, гаилә тәрбиясе, бала тәрбияләүдә гаиләнең ролен күздә тотып язылды.

Тәрбия бирүнең асыл чыганагы анадан башланганлыгын аңлап, киләчәктә ана булачак кыз балаларның тәрбиясен яшьтән кайгырту кирәклеген ул һәрдаим искәртеп килде.

Башлангыч чор иҗатында әле аның сәясәт һәм ул тудырган иҗтимагый шартларның асылын тулысынча аңлап бетермәве дә сизелә. Җәмгыятьтәге тигезсезлек, әхлакый бозыклык кебек хәлләрне дә наданлыктан һәм тәрбиясезлектән күрә. Җәмгыять һәм шәхес арасындагы каршылыкларны да җәмгыять төзелешенә, капиталистик яшәү кануннарына бәйләп караудан бигрәк, кешенең рухи ярлылыгы, тәрбиянең түбәнлеге белән аңлата. Әмма мондый гади фикер йөртү, милләт һәм кеше язмышын иҗтимагый, сәяси җирлектән аерып карауның дөрес түгеллеген ул бик тиз төшенә.

1905 елның канлы вакыйгалары, сәяси фикер ягыннан гаять алдынгы булган Казан мохитендә яшәү аңа революцион көрәшнең эчке каршылыкларын тирәнрәк төшенергә булыша. Искиткеч катлаулы һәм каршылыклы, сыйныфлар арасындагы канлы көрәш белән узган бу вакыйгалар шагыйрьгә үзенең кыйбласын билгеләргә ярдәм итә. Ул азатлык хәрәкәтенең «асыл серен» – коры сүзнең максатка илтмәгәнлеген, милләтнең якты киләчәге, хезмәт кешесенең бәхете өчен көрәш кирәклеген аңлый. Әмма шагыйрь революциянең бер талпынуда һәммәсен хәл итүенә ышана. Икътисади, рухи артталыкка, матди тигезсезлек, милли изүгә чик куярга тиеш дип санаган бу алмашынуны М.Гафури бөтен күңеле белән яклый, 1905 елда язылган «Алмашыну», «Хөррият дәверендә», «Инсаф вә иттифак», «Өндәү», «Вакыт йитте» кебек шигырьләрендә әлеге хәрәкәтне күтәреп алырга, берләшергә, мөмкинлектән файдаланырга чакыра. Шул тәэсирләр йогынтысында язылган «Шатлык шигыре»ндә (1905) ул халкыбызның киләчәген оптимистик рухта сурәтли:

Алынды авырлыклар кулымыздан,
Манигъ юк бара торган юлымызда.
Хөррият заманнары каплап алды
Алдан, арттан һәм уң илә сулымыздан [Гафури, б. 31].

Бу шигырьләрендә ул әле еш кына татар һәм мөселман сүзләрен тиңдәш итеп файдалана. Мәсәлән, «Өндәү» шигыре:

Йа татар! Вакыт йитте кузгалырга,
Мәгариф шәмгыданын кулга алырга, –

дип татарга мөрәҗәгать белән башланып китә.

Файдалы эш вөҗүдкә чыксын дисәк,
Карап яту тиеш түгел мөселманга [Гафури, б. 38], –

дип тәмамлана.

Аерым әсәрләрендә ул гомумән мөселман дөньясын кайгыртуга да күчә. Бер яктан, патша Россиясендә генә түгел, бөтен дөньяда

халыкара колониаль изүнең югары ноктасына җитүенә, анда да мөселманнарның хәле катлаулы булуга борчыла. Төрле елларда язылган «Аурупа–Азия» (1906), «Башка җирдәге мөселманнарның хәле» (1906), «Инглизләрнең сәясәте» (1907) шигырьләрендә турыдан-туры гомум сәясәтнең аерым милләтләргә китергән зыяны турында сөйли. «Аурупа–Азия»дә, мәсәлән, шагыйрь үзен өстен санаган Аурупага: «Мәгарифнең асыл тамырын бәхәс итсәк, Азиядәге халыклардан сезгә килгән», – дип, тарихи яктан Шәрык дөньясында фәнни-мәдәни казанышларның иртәрәк тууын искәртеп, мөселманнарның һич тә түбәнрәк дәрәҗәдә торган халык булмауларын дәлилли.

Икенче яктан, аны Россия җирлегендә яшәгән татар, башкорт, казакъ һәм башка мөселман халыкларының хәле уйландыра. «Ике кош», «Мал өчен», «Фидаи мәхбүс агызыннан», «Балыкчылар» (1906), «Безнең хәл», «Гафури сән онытма милләтеңне…», «Милләткә хадим булган яхшыларга», «Икенче сада» «Мәмләкәтнең барчасы әгъдәя мөлкәт улмасын» «Сөембикә манарасы» … (1907) шигырьләре «асыл ватан»да татар халкының хокукларын даулап язылган күпсанлы әсәрләренең бер өлешен тәшкил итә.

Биредә инде шагыйрь милләт язмышын мәгъифәтчелек идеяләре югарылыгыннан торып кына хәл итәргә алынмый, мәсьәләнең асылына якын килеп, күпмилләтле дәүләт эчендә милләтләрнең тигез хокуклы булуының иң төп шарт икәнлегенә игътибарын юнәлтә. «Ике кош» шигыре – шул мәсьәләне бик үзенчәлекле яктырткан әсәрләренең берсе.

Милләт һәм тел шагыйрь өчен бер-берсеннән аерылгысыз. «Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь»ендә дә милләт һәм тел язмышының бердәмлеген ассызыклый, телне саклау – милләтне саклау, дигән фикер әйтә:

Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар;
Милләт ашдыкча – ашар, милләт яшьдекчә – яшәр [Гафури, б. 195].

Милләт дигәндә татар халкын күңелендә тоткан кебек, тел дигәндә дә ул татар телен күздә тота. Татар телен ул «үз ана телем» дип атый:

Үз ана телем — минем өчен матур, иң тәмле тел;
Үз телем — үз әйберем булган өчен ярата күңел.

Шул ана теле белән мин мәкъсудымны аңлатам;
Шул анам теле белән «балам» диләр анам-атам...

Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән көйлим берәр көй көйләсәм [Гафури, б. 254].

Милләт язмышы М. Гафуриның шигъри әсәрләрендә генә түгел, прозасында да аерым урын алып тора.

М. Гафуриның инкыйлабка кадәрге чор прозасында берничә әсәрне аерып күрсәтергә мөмкин. «Ачлык яки сатлык кыз» (1907),

«Ярлылар яки өйдәш хатын» (1907), «Үги балалар» (1908), «Онытылган җинаять, яки үткәнне искә төшерү» (1909), «Исәпсез байлык» (1912) кебек бер төркем әсәрләрендә тормышны сәнгатьчә гәүдәләндерүгә мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм синтезы аша ирешә. Бу әсәрләрендә инкыйлабка кадәрге Россия мөселманнарының яшәешен сурәтләү аркылы, милли дискриминация, социаль тигезсезлек хөкем сөргән җәмгыятьтә кешенең асылын, шәхес һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген ачарга омтыла.

Әсәрләренең чынбарлык белән тәңгәллегенә ирешү, укучыга тәэсирлелекне көчәйтү юлында кырыс, җентекле натуралистик алым белән эшләнгән күренешләр тудырудан да читләшми. Дөрес, тормышны реалистик сурәтләүгә юнәлдерелгән әсәрләрендә дә ул әле нәтиҗәләр ясарга, хөкем итәргә ашыкмый, вакыйгалар агымын эзлекле хикәяләүче, күзәтүче буларак чыгыш ясый.

«Ярлылар яки өйдәш хатын» повесте үзенең салмак агымда эзлеклелекне саклап, тормышны сурәтләүдә ышандырырлык итеп, фәкыйрьлек төбенә төшкән ярлыларның һәм мал белән күңел күзләре томаланган байларның эчке дөньясын искиткеч оста психологик төгәллек аша сурәтләп бирүе белән үзенчәлекле. Әсәрдә өметсезлек, фәкыйрьлек, ачлык, салкын кочагында бер-берсенә сыенган, үлем тырнагыннан котылып калырга теләп берләшкән көнлекче хезмәте белән генә җан саклаучы Шәриф, аның хатыны Бәдри белән балалары һәм алардан да бәхетсезрәк Җәмиләнең язмышы турында сөйләнә. Укучы күңелен тетрәндерерлек фаҗигаларны хикәяләүче бу әсәрне укыганда күңелдә авыр тойгылар белән янәшә өмет, соклану чаткысы яши. Ярлыларның өметсез, нурсыз тормышын аларның кешелеклелеге бизи. Язучы байларның тупас күңеллелегенә, фәкыйрьләрнең кешелеклелек сыйфатларын каршы куя. Карасаң, кешенең асылы болайрак корылган икән шул: авырлыкларны күтәрә, сабыр итә, соңгы сулышына кадәр яшәү өчен көрәшә, өметен җуймый, иманын саклый, тик үзенең башкалардан өстенрәк торуын тоюга, ул нәфес колына әверелә башлый, югарырак үрмәләү өчен намусын да, иманын да сата. Ә чынлыкта һәммәбез дә яратылышыбыз белән тигез, кайтыр урыныбыз да бер, әмма нәфес колына әверелеп, шуны онытабыз. Әсәрләрендәге бер-берсеннән кискен аерылган байлыкта яшәүче кешелексезләр һәм тормыш төбендә җан саклаучы ярлылар образлары аша автор шушы хакыйкатьне дәлилли.

«Үги балалар» әсәрендә үгилек турындагы гомумиләштерүләрне укыганнан соң, автор фикеренең Галә мулла гаиләсендәге вакыйгалар белән генә чикләнмәве ачык аңлашыла. Әдип яшь хатын җаһиллыгына бирелеп, балаларын үгилек ачысыннан саклый алмаган Галә мулла образы аша милләт хөрлеген якларга тиешле ир-егетләребезнең гамәл кыласы урында тормыш агымына ихтыярсыз бирелгәнлекләрен ача. Моның сәбәпләрен ул аларның иске тәртипле мәдрәсәләрдә укып, тормышка әзерлексез булуларында күрә.

Ике инкыйлаб арасында (1905 – 1917) хөкүмәт тарафыннан оештырылган кысу, тентү-тикшерүләр, полиция күзәтүләре, татар зыялылары арасында төрле якка тартылу, бүлгәләнеш һәм шуның нәтиҗәсендә кешеләргә карата ышаныч, алдагы көнгә өмет югалу, көрәш рухы сүрелү М. Гафури иҗатына да сизелерлек йогынты ясый. «Әмма М. Гафури бервакытта да тоташ пессимизмга бирелмәде. Чөнки ул йөрәгенең һәр тамыры белән халыкка береккән иде. Халыкка исә пессимизм – ят нәрсә» [Нуруллин, б. 231]. Җәмгыятьтәге бу халәткә карата язучы күңелендә туган эчке каршылык нигезендә әдәбиятта азатлык, шәхес иреге, милли үзаң, Ватан төшенчәсен, яшәү мәгънәсен аңлату үзенчәлекле гәүдәләнеш ала. Шигъриятендә дини мифология, ислам фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итү, мәхәббәт, табигать культын данлау кебек үзенчәлекләр белән сыйфатланган бу күренеш, прозасында да реалистик сурәтләүдән тайпылып, романтизмга йөз белән борылуына китерә, язучы иҗаты модернизмга хас үзенчәлекләр белән баетыла. Язучының рухи дөньясында барган үзгәрешләр, үзен әйләндереп алган мохит белән каршылыкка керүе, аның белән көрәшүдә яңа көч, реакцион җәмгыять вәхшилегенә каршы торырлык идеал эзләү «Болгар кызы Айсылу» (1910), «Тәэссорат» (1913), «Бу кемнең кабере?» (1913), «Хан кызы Алтынчәч» (1914) кебек хикәя, нәсерләрен тудыруга сәбәп булды. Төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Бер чәчәкнең наләсе» (1911), башкорт халык авыз иҗатына нигезләнгән ярым тезмә формада язылган «Зыятүләк берлә Сусылу» (1910) әсәрләре дә шушы исемлекне тулыландыра [бу хакта кара: Заһидуллина, б. 58–61].

«Тәэссорат» («Сиземләү») әсәрендә җир һәм күкләрне берләштергән, һәрнәрсәне үзенә сәҗдә кылдырган газамәт (олы, бөек), мәгънәви бер куәт – мәхәббәт турында сөйләнә. Автор хис һәм табигать культына өстенлек биреп, кешеләрнең табигать кануннары буенча яшәргә тиешлеген раслый, җир тормышының шәфкатьсезлегенә мәхәббәтнең илаһилыгын каршы куя, әсәрдә мәхәббәт яшәешнең төп кануны, яшәү гармониясе тудыручы илаһи көч, олы матурлык буларак шәрехләнә.

«Бу кемнең кабере?», «Хан кызы Алтынчәч» кебек әсәрләре идея ягыннан халкыбызның үткәнен данлый, шәхес иреген бар нәрсәдән өстен куя, кеше гомеренең дә, дан-шөһрәтләрнең дә, фани дөньяның да узгынчы булуын кисәтә, үткән белән бүгенгене киләчәккә тоташтыручы буын, хәтер сакчысы булганда гына яшәеш дәвам итә дип раслый. Шуларга нигезләнеп ул гомумкешелек тарафыннан кабул ителгән тормыш кануннарын, аларның әхлакый нигезен укучы өчен ачып бирә, уйланырга этәрә.

Шагыйрь поэзиясенең тагын бер мөһим үзенчәлеге бар. Ул дөньякүләм танылган мәсәлләрнең сюжетларын файдаланып та, үзе тудырган оригиналь сюжетлар аша да татар поэзиясендә беренчеләрдән булып мәсәл жанрын тудыруга зур өлеш кертте. 1910–1913 елларда ул Эзоп, Лафонтен, Крыловлардан килә торан жанрга – мәсәлгә

мөрәҗәгать итә һәм егермеләп мәсәл язып бастыра. 1913 елда алар махсус җыентык рәвешендә «Әмсәль» исеме белән укучы кулына килеп ирешә.

Мәсәл жанры кешелек яшәеше дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән гомумкешелек кануннарын, әдәп-әхлак кагыйдәләрен саклауга, әлеге кануннарга буйсынмаганнарны читләтеп әйтү юлы белән тәнкыйтьләүгә һәм тәрбияләүгә хезмәт итә. Алда искәртелгәнчә, М. Гафури мәсәлләренең дә тамыры тирәндә ята, анда Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыкларының акылы синтезлаша. М. Гафури мәсәлләре аерым бер чор һәм аерым бер вакыйганы гына күздә тотмыйлар, ә гомумкешелек проблемаларын үз эченә алып, киң масштабта фикерләргә урын калдыралар, нәтиҗәдә вакытлар үтү белән үзләренең актуальлекләрен дә югалтмыйлар. Аларның кыйммәте дә шунда. Әйтик, «Кошларның патша сайлаулары» яки «Үгез белән Бүре» мәсәлләрен укыганда, бүгенге көн укучысы эчкә яшерелгән образда үз чорыбызның төгәл вакыйгаларын күрә ала. Әдип үзенең мәсәлләрендә яшәешебездәге кимчелекләрне тәнкыйть утына тотып, гаделлек һәм кешелек кануннарын саклап яшәргә чакыра.

М. Гафури Октябрь инкыйлабына кадәрге шигъриятендә дә, прозасында да Россия халкының – бигрәк тә үзе өчен бик тә таныш гади халыкның – аянычлы хәлен, хокуксызлыгын тасвирлап, аңа теләктәшлеген генә сөйләп калмый, ул «зарлы, моңлы», әмма «эч кере» булмаган, «тәкәллефсез», «ана сөтедәй хәләл» ризык белән тукланган гади кешене тирәнтен аңлап, аларның инсаниятенә, рухи камиллегенә мәдхия укый.

М. Гафури инкыйлабтан соңгы чор шигъриятендә заман белән бер сулышта булып, бергә атларга, яңа дәвергә хас җыр-моңнарны да табарга тырыша. 20–30 еллар иҗатының идея-тематик юнәлешендә бу үзен нык сиздерә. 1919 елда язылган «Изге юлда», «Безнең юл», «Гаһед», «Сәлам», «Татар җегетенә» кебек шигырьләре илдә яңа тормыш төзүче каһарманнарга багышланса, «Яңа бәйрәм» (1920), «Беренче май сәламе» (1921), «Нинди бәйрәм бар соң» (1922), «Таң бәйрәме» (1927) «Кызыл гаскәр җыры» (1928) кебек шигырьләрендә яңача яшәү рәвеше, совет иленең куәте данлана. «Бир кулыңны» (1919), «Эшче» поэмасы (1920), «Урак һәм чүкеч» (1921), «Шахтер» (1925), «Златоуст» (1928), «Колхоз фронтында җиңүчеләргә» (1933) кебек шигырьләре гади хезмәт кешесенә багышлана.

Халыкның шатлыгын үз шатлыгыдай күргән әдип, аның ачы хәсрәтен дә уртаклашып, тирәнтен кайгыра белә. Халык җилкәсенә төшкән авырлыктан сызлану бигрәк тә язучының Идел буен тетрәндергән зур фаҗига – ачлык афәтенә мөнәсәбәтле шигырьләрендә чагылыш тапты. 1921–1922 елларда иҗат ителгән «Ач», «Сулган гөлләр», «Соңгы минутта», «Җылыйлар», «Сүнделәр», «Алтын тәре, бәрхет палас» кебек шигырьләрендә һәм «Кеше ашаучылар» поэмасында җан өшеткеч вакыйгалар, яшәүгә өметен югалткан, чарасыз, аяныч хәлдәге кешенең соңгы сулышын гәүдәләндерүдән

алып, биологик зат буларак һәр адәм баласының да кыргыйлыгын, вәхшилеген, җан саклау өчен үз баласына ук кул салуын тетрәндергеч натуралистик картиналар аша сурәтләп бирде. Үзен саклау инстинкты кешене кыргыйлыкка этәрә, әмма кешелек асылы аны туктатып кала: баласын ашап исән калуны түгел, ул үлемне сайлый.

Язучы «Кеше ашаучылар» поэмасы белән кешенең кешелексезлек чигендә дә асылын җуймаска тиешлеген дәлилләргә алынды.

М. Гафуриның Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән проза әсәрләре арасында гына да түгел, гомумән бөтен ижатында, тематикасы, әдәби эшләнеше – сюжет үстерелеше, образлар системасы, идея-проблематикасы ягыннан «Тормыш баскычлары» повесте аерым игътибарга лаек. Бу әсәр – милли характер, милли көнкүреш аша гомумкешелек проблемалары югарылыгына күтәрелгән, мохит тәэсире, тормыш тәҗрибәсе ярдәмендә шәхес формалашуны аерым вакыйгалар яктылыгында, ышандырырлык итеп ачып бирә алган повесть.

Әдип прозасының бер өлешен балалар өчен язылган хикәяләр тәшкил итә. Аларның язылу вакытлары билгеле булганнары инкыйлабтан соң иҗат ителгән. «Ялчы» (1921), «Безнең әйберләрне сатканда» (1927) кебек хикәяләре М. Гафури иҗатына хас гомуми тематиканы – байлар һәм ярлылар арасындагы кискен каршылыкны, хезмәт кешесенең рәнҗетелү-кимсетелүен, байларның кешелексезлеген сөйләүне дәвам итә. «Хәзер ансат ул – элек Троицкидагы кыен иде» (1927), «Югалган Актырнак» (1930) хикәяләрендә инкыйлабка кадәрге тормышта һәм яңа заманда гади кешенең яшәү рәвешен чагыштырып бирә. Дөрес, алда әйтелгән һәм язылу вакыты күрсәтелмәгән «Кыр казы» хикәяләрендә гомумән кеше күңелендәге шәфкатьсезлек һәм кешелеклелек каршы куела, берсе икенчесе яктылыгына чыгарылып каршылык кискенләштерелә, укучыны уйланырга мәҗбүр итә. Гади кеше тормышын, аның рухи дөньясын, күңел халәтен нечкә тоемлап сурәтли алган язучы балалар өчен язылган әсәрләрендә дә шул югарылыкны саклый.

Әдипнең иҗади эшчәнлеге матбугат органнарында хезмәт итү белән үрелеп бара. Ул талантлы шагыйрь, прозаик буларак кына түгел, туры сүзле, үткен күзле, җәмгыятьтәге һәр үзгәрешкә үзенең мөнәсәбәтен белдереп барырлык гаять киң фикери даирәсе булган публицист буларак та танылa. Халыкның мәгълүматлылыгын күтәрү, иҗтимагый аңны үстерүдә вакытлы матбугатның ролен тирәнтен аңлап эш итә. Аның беренче мәкаләләре мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылып, халыкны аң-белемгә, прогресска чакырып, күбесе шәкертләргә мөрәҗәгать итеп язылган иде. Алга таба ул халык арасында агарту эшен пропагандалауны да дәвам итә һәм үтә җитди рәвештә үз чорының бик тә әһәмиятле социаль-икътисади мәсьәләләрен күтәреп чыга.

Октябрь инкыйлабыннан соң, бигрәк тә «Шәрык ярлылары» «Башкортстан», һәм «Яңавыл» газетларында эшләгән елларда, аңа халык арасында еш булырга туры килә. Шунлыктан ул үз чорының көндәлек проблемаларын ачык тоеп, халыкның рухи халәтен, яңа тор-

мыш төзү юлына баскан кешенең психологиясен тирәнтен аңлап һәм аңа чын күңелдән теләктәшлек белдереп мәкаләләр, хәбәрләр, очерклар яза, искелек калдыкларыннан ачы көлеп, кимчелекләрне фаш итеп, фельетоннар бастыра. Җәмгыятьтәге һәр иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни үзгәреш, халыкны борчыган һәр мәсьәлә, һәрбер алдынгы тәҗрибә М. Гафуриның үткен каләме аша халыкка җиткерелеп килә.

М. Гафури ижаты Россия җирлегендә генә түгел, кешелек дөньясында тамырдан борылыш барган чорга туры килүе һәм шул вакыйгаларны милли мәнфәгатьләр яссылыгында гәүдәләндерүе белән үзенчәлекле. Аның каләме милли һәм социаль тигезсезлек тудырган каршылыклар соң дәрәҗәдә кискенләшеп, җәмгыятьнең әхлакый кануннардан йөз чөергән, кыргыйлык хөкем сөргән елларны да, тормыш авырлыгыннан гаҗиз булган халыкның ярым саташулы хәлдә канлы юл белән яңа тормыш төзүен дә гәүдәләндерде.

Милләт язмышы, гади кеше хокукларын яклаучы буларак иҗат мәйданына атлаган язучы М. Гафури, давыллы еллар сынавын үтеп, чын мәгънәсендә халык шагыйре булып җитеште.

**Әдәбият**

*Гафури М.* Әсәрләр: 4 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 534 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX гасыр башы татар прозасы. Казан: Татар. кит нәшр., 2003. 255 б.

*Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 285 б.

*Госман Х.* Шигърият гомере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 204 б.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 374(575.1)

*Л.Р. Мортазина*

# БУЛАТ САЛИЕВ – ҮЗБӘК ТАРИХЫН ЯЗГАН ТАТАР ГАЛИМЕ

В статье освещается жизнь и научно-педагогическая деятельность известного в Узбекистане ученого-историка Булата Мазитовича Салиева, оставившего заметный след в исторической науке тюркских народов, одним из первых изучив полную историю узбекского народа. Особое внимание уделяется освещению узбекского периода жизни ученого, раскрывается его вклад в развитие науки и просвещения Узбекистана.

**Ключевые слова**: Булат Мазитович Салиев, профессор, педагог, история Средней Азии, история Бухары, научные труды.

The article highlights the life and research, pedagogical activity of the famous scholar, historian of Uzbekistan Bulat Mazitovich Saliev. He left a noticeable mark in the historical science of the Turkic peoples. Saliev was one of the first to study the full history of the Uzbek people. Particular attention is paid to coverage of the Uzbek period of the scholar’s life, his contribution to the development of science and education of Uzbekistan is revealed.

**Keywords:** Bulat Mazitovich Saliev, professor, teacher, history of Central Asia, history of Bukhara, scientific works.

Совет чорында, аеруча XX гасырның 20–30 нчы елларында, башка төрки халыкларның фәне, мәгарифе, мәдәнияте, сәнгате үсешенә зур өлеш керткән татарлар турында мәгълүматлар бүгенге көндә җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Киң җәмәгатьчелек азәрбайҗан, үзбәк фәнендә тирән эз калдырган Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, Сәмәрканд, Фирганә, Ташкент югары уку йортларында үзбәк әдәбияты кафедраларына нигез салган, үзбәк әдәбияты буенча беренче дәреслекләр язган Габдрахман Сәгъди, Кавказда мәгърифәт таратучылардан Терегуловлар нәселе вәкилләре һәм тагын кайбер берничә шәхес турында гына хәбәрдар. Билгеле булганча, үзбәк һәм Урта Азиядәге башка төрки телләрдә беренче газеталарны чыгаручылар, беренче дәреслекләрне язучылар, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укытучылар, үзбәк милли театрына нигез салучылар, дәүләт эшлеклеләре дә нигездә татарлар булган. Тик, кызганыч, аларның күпчелегенең эшчәнлеге, тормышы әлегә тулысынча өйрәнелмәгән, исемнәре дә галимнәр даирәсендә генә билгеле. Тарих мәйданында үзенең тиешле урынын һәм бәясен алырга хаклы шәхесләр арасында төрки-мөселман халыкларының мәгарифе, фәне үсешенә зур өлеш керткән татар мәгърифәтчесе һәм галиме Булат Мәҗит улы Салиев[1]

[1] Булат Салиев Үзбәкстан галимнәре хезмәтләрендә Бик Булат Соли-углы, Пулат Солиев буларак та искә алына.

та бар. Бүгенге көндә фәнни даирәләрдә ул беренче чиратта тарих буенча беренче үзбәк профессоры буларак билгеле.



Булат Салиев

Булат Мәҗит улы Салиев 1882 елда Әстерхан губернасы Кызан[1] авылында дөньяга килә. Бала вакытыннан ук бик кызыксынучан булуы белән аерылып тора. Танылган дин әһеле һәм мәгърифәтче-галим Габдрахман Гомәринең «Низамия» мәдрәсәсендә укыган вакытта, мөгаен остазының йогынтысы астында, тарих белән, төрки кавемнең килеп чыгышы белән ныклап кызыксына башлый. Моның өстенә, Әстерханның Урта Азия-Россия сәүдә юллары тоташкан урында урнашуы сәбәпле, анда үзбәк һәм башка төрки телләрдә аралашкан кешеләрне, сәүдәгәрләрне күзәтүнең дә тәэсире булгандыр.

«Низамия»не тәмамлаганнан соң, Булат Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә, 1905 елда белем алуын Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Бу – булачак галимнең фәнни күзаллаулары, фикерләре, дөньяга карашы, омтылыш-теләкләре формалашкан чор дип әйтергә мөмкин. «Галия»дә укыган дәвердә ул гарәп һәм фарсы телләрен, төрки халыклар тарихын бик теләп өйрәнә. Галимҗан Ибраһимов белән якыннан танышуы (алар икесе бер бүлмәдә яшиләр) [Германов, с. 126], аның белән төрле фәнни темаларга әңгәмә корулары да, мөгаен, киләчәк һөнәрен сайлауга ярдәм иткәндер дип фаразларга җирлек бар. «Галия» мәдрәсәсен уңышлы тәмамлаган Булат Салиевка, шунда калып, укытучылык эшенә керешергә тәкъдим итәләр. Тик ул, балалык елларыннан ук килгән хыялын тормышка ашырырга – төрки халыкларның тарихын, телләрен, мәдәниятен өйрәнергә карар кыла. Шул максат белән 1909 елда Урта Азиягә китә, анда мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый.

Салиевның Урта Азия халыклары тарихы белән кызыксынуының сәбәбен ачыкларга теләп, үзбәк галимнәре аның бабаларының килеп чыгышын үзбәк милләте, Бохара ханлыгындагы мангыт кабиләсе белән бәйләп карыйлар. Шуңа күрә дә ул, алар фаразынча, ата-бабаларының ватанына кайтырга карар кыла [Германов, с. 126]. Гарәп, фарсы, төрек, татар, рус телләрен бик яхшы белгән Булат Салиевны бигрәк тә яңа мәдәният, яңа тирәлек, үзе өчен әлегәчә ачылып бетмәгән яңа дөнья, яңа тормыш белән танышу, аны тирәнтен белергә теләү тойгысы үзенә тарткан булса кирәк.

[1] Бу авыл Татарская Башмаковка буларак билгеле.

Ташкентка килгәннән соң, Б. Салиев Җагайбайлы кышлагында балаларга тарих, арифметика, туган тел буенча дәресләр бирә башлый. 1910 еллар – патша хөкүмәтенең Төркестандагы татар мөгаллимнәрен эзәрлекләү, аларны педагогик процесстан читләштерү сәясәте белән бәйле чор. Бу шаукым Салиевка да кагыла, нәтиҗәдә ул яшерен рәвештә эшләргә мәҗбүр була: үзенең мәктәбен «керосин кибете» итеп «үзгәртә», аның янына дәрес алырга килгән шәкертләре исә остазлары карамагына керосин сатып алучылар кыяфәтендә йөриләр. Күпмедер вакыт шулай дәвам итә. Әмма үзенә көндәш (конкурент) итеп күргән кайбер муллалар аннан котылу җаен табалар: Салиев турында Ташкентка язалар. Нәтиҗәдә ул «законсыз рәвештә кышлакта мөгаллимлек иткән өчен» кулга алына, биш тәүлек төрмәдә утырып чыга [Германов, с. 128].

Б. Салиевның революциядән соңгы еллардагы эшчәнлеге шәһәр мәктәпләре белән бәйле. Ул бу вакытларда Мәскәүдә чыгып килгән «Ил» газетасына языша, озакламый үзе дә Коканд шәһәрендә төрки телдә «Ил байрагы» исеме астында сәяси, әдәби-иҗтимагый газета чыгара башлый, әмма басма озак гомерле булмый, бары тик 20 саны гына дөнья күреп кала[1].

1918 елның ноябрендә Салиев җирле халык вәкилләреннән укытучылар әзерләү өчен ачылган Коканд халык университетының беренче директоры итеп билгеләнә. Аның белән бергә мәгърифәтче, мөгаллим Һади Фәйзи һ.б. эшли [Узбекистон, б. 342]. 1919 елдан – ул Ташкентта яңа оештырылган Төрек-татар мәгариф институты директоры вазифасын үти башлый. Бу елларда ул үзбәк телендә чыгып килүче «Таң» һәм «Инкыйлаб» журналлары белән хезмәттәшлек итә, бер үк вакытта Урта Азия халыкларының тарихын, этнографиясен һәм икътисадын өйрәнү буенча экспедицияләргә чыга. Гомумән алганда, үзбәк галимнәре билгеләвенчә, Б. Салиев, Ә. Диваев[2] белән берлектә, 1918–1920 елларда үзбәк халкының мәдәни тормышында зур урын алган шәхесләрдән саналырга лаеклы [Узбекистон, б. 351].

1922 елда Б. Салиев – Бохара Халык Совет Республикасының Мәгариф халык назиратының Фәнни советы рәисе итеп билгеләнә, бер үк вакытта Укытучылар институтында гарәп әдәбиты тарихы һәм гарәп теле буенча лекцияләр укый. Бу чорда ул иң кызыклы, әмма иң аз өйрәнелгән Урта Азия дәүләтләренең берсе – Бохара тарихы белән ныклап шөгыльләнә башлый. Нәтиҗәдә аның Бохара тарихына багышланган берничә фәнни хезмәте дөнья күрә. Бүгенге көндә Салиевның үзбәк телендә басылып чыккан өч хезмәте – «Бохара тарихы», «Мангытлар солтанаты дәверендә Бохара өлкәсе» һәм «Үзбәкстан

---

[1] Әлеге газетаның берничә нөсхәсе бүгенге көндә Ташкент шәһәрендә А. Нәвои исемендәге Үзбәкстан милли китапханәсендә саклана.

[2] Әбүбәкер Әхмәтҗан улы Диваев (6.12.1855, Оренбург – 5.02.1933, Ташкент) – шәркыятьче-галим, этнограф, фольклор белгече, профессор, Төркестан университетын оештыручыларның берсе, Ташкентта татар мәктәбен ача һәм аңа җитәкчелек итә.

һәм Таҗикстан» китаплары Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясенең Әбу Рәйхан Беруни исемендәге Шәрык институты китапханәсендә саклана.

Бохарада Б. Салиев Бохара әмирләренең моңарчы беркемнең дә кулы тимәгән бай китапханәсе һәм архивы белән эшләү бәхетенә ирешә. Гарәп һәм фарсы-таҗик телләрендә язылган тарихи кульязма китапларны фәнни-тикшеренү институтына тапшыру өчен әзерләү эшендә катнашкан галим бер үк вакытта үзенең фәнни тикшеренүләре өчен шактый мәгълүмат туплый.

1924 елның август аенда Б. Салиев Бохара мәгариф йортында укыту өчен Мәскәүгә җибәрелә. Бер үк вакытта Кызыл профессура институтына йөреп, үзенең белемен дә күтәрә (1926 елда тәмамлый), Свердлов исемендәге Коммунистик университетта лекцияләр тыңлый. Кайбер авторлар, мәсәлән, Б. Салиев эшчәнлеген өйрәнгән галим Т.С. Саидкулов мәгълүматлары буенча, ул Мәскәү дәүләт университетының көнчыгыш факультетында да белем ала [Саидкулов, б. 183].

Мәскәүдән кайтканнан соң, Б.М. Салиев Урта Азия дәүләт университетына[1] эшкә чакырыла, анда «Урта Азия халыклары тарихы» юнәлеше буенча фәнни эшчәнлек алып бара, Урта Азиянең иҗтимагый-сәяси тарихы кафедрасын оештыруда катнаша [Саидкулов, б. 183].

1927 елда Сәмәркандка әйләнеп кайтканнан соң, Салиев яңа ачылган Югары педагогик институтта (соңрак Сәмәрканд дәүләт университеты итеп үзгәртелә) укыта башлый, башта Көнчыгыш тарихы, соңрак Урта Азия тарихы кафедрасының мөдире итеп билгеләнә. 1930 елда аңа профессор дәрәҗәсе бирелә [Саидкулов, с. 183].

20 нче елларның икенче – 30 нчы елларның беренче яртысы – Б.М. Салиевның Урта Азия һәм үзбәк халкы тарихы буенча зур эзләнүләр алып барган чоры. Иң күләмле, әһәмиятле хезмәтләре дә шушы вакытта языла. Алда искә алынганнары белән беррәттән, Булат Салиевның «Урта Азия тарихы (XI–XIX гасырлар)», «Үзбәкстан тарихы», «Урта Азиядә ислам таралу» һ.б. үзбәк һәм рус телләрендә басылып чыккан китаплары булуы билгеле [Татарская, с. 216]. Моннан тыш, архив документларында сакланган мәгълүматларга караганда, 1936 елда галимнең «Россия яулап алуларына кадәр Урта Азиядә җир-су мөнәсәбәтләре», «Урта Азия тарихы буенча феодаль грамоталар һәм документлар җыентыгы» кебек хезмәтләренең кульязмалары басмага тапшыру өчен әзерләнгән була [Саидкулов, с. 184]. Ләкин, кызганычка каршы, Урта гасырлар манускрипты һәм иске үзбәк, гарәп-фарсы чыганакларына таянып язылу сәбәпле, алар идеологик яктан тотнаксыз дип табыла, репрессия елларында бу хезмәтләрнең күбесе китапханәләрдән алына һәм юк ителә [Германов, с. 125].

[1] Мирза Олугбек исемендәге Үзбәкстан милли университеты, 1960–1990 елларда Ташкент дәүләт университеты буларак билгеле.

1932 елда Салиев кире Ташкентка кайтарыла, Үзбәк революция тарихы фәнни-тикшеренү институтына эшкә билгеләнә, аңа бик борынгы чордан алып хәзерге көнгәчә Үзбәкстан тарихын язу бурычы тапшырыла. Шактый эш эшләнсә дә, кызганычка каршы, аны тулысынча башкарып чыгу насыйп булмый, 1937 елның көзендә Б. Салиевны тентү һәм кулга алу өчен ордер бирелә. Галимнең фатирындагы иң кадерле, кыйммәтле мирасы сакланган бүлмә – аның китапханәсе һәм шәхси архивына йозак салына. Шулай итеп, илдә тамыр җәйгән зәхмәтле сәясәт Үзбәкстан тарихчысын да эзләп таба.

Кулга алу сәбәпләренең берсе – тарихчы-галим, сәяси эшлекле, исламчылык, төркичелек идеяләре тарафдары Зәки Вәлиди белән бәйләнеш, дуслык һәм хезмәттәшлек була. Үзе кебек үк Үзәк Азия һәм мөселман Көнчыгышын өйрәнүче белгеч белән Б. Салиев 1913 елдан ук таныш була, 1917 елда алар кабат күрешә. Шуның өстенә, З. Вәлидинең Берлиннан Салиев исеменә атап җибәргән хаты органнар кулына эләгә. Әлеге хатта Вәлиди Төркестан тарихына багышланган зур күләмле фәнни хезмәтләрен, бигрәк тә дүрт томлык «Төркестанның кыскача географик тарихы»н бастыруда дустыннан ярдәм сорап яза [Шигабдинов]. Бу хат Салиевны кулга алу өчен җитди сәбәп дип табыла. Моннан тыш, галимнең элегрәк кылган «җинаятьләре» дә искә алына: Яңалифкә күчеш чорында ул дусты һәм фикердәше Галимҗан Ибраһимовны яклап чыга, «яңа алфавитны кабул итү көлке, һәм ул бернинди файда бирмәячәк», дип белдерә. Галимнең педагоглык эшчәнлеге дә шик астына алына: профессорның студентларга лекцияне А.Вамбериның «Мәвараэннәһер тарихы» китабы буенча укытканлыгы ачыклана. «Контрреволюцион эшчәнлектә» фаш ителгән Фатыйх Кәрими тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән бу китап, НКВД хезмәткәрләре билгеләвенчә, Урта Азиядәге «хезмәт ияләренең чынбарлыктагы хәлен» тасвирламый, шул сәбәпле укыту процессында аны куллану җинаятькә тиң була [Германов, с. 146].

1937 елның 13 октябрендә профессор Б.М. Салиев кулга алына. Эшне тикшерү дүрт айга сузыла. Бер-бер артлы үткән йокысыз төннәр, бер-берсен алыштырган тикшерүчеләр. 50 кешегә исәпләнгән тынчу камерада өчәр катлы ятакларда 150 әсир, араларында сәясиләре дә шактый. Салиевның тарих профессоры икәнен белеп алган камерадашлары аннан нинди дә булса берәр тарих турында сөйләвен үтенәләр. Ул исә Әмир Тимер дәвере, аның яулары, Сәмәрканд, Бохара тарихы турында сөйли, яраткан шагыйрьләре Нәвои, Дәрдмәнднең шигырьләрен хәтердән укый...

1938 елның 7 февралендә өчлек суды тарафыннан Үзбәкстан НКВДсының Сәмәрканд секторында профессор Булат Салиев эше карала, галимнең мал-мөлкәтен конфискацияләү, ә үзен атып үтерү турында карар чыгарыла. 28 февральдә карар тормышка да ашырыла. Соңыннан, соңгы көннәре турында белергә теләп мөрәҗәгать иткән якыннарына Б. Салиевның 10 елга ирегеннән мәхрүм ителүе, ләкин 1944 елда энтероколиттан вафат булуы турында хәбәр ителә.

Б. Салиев төрки халыклар тарихына беренче тапкыр үзбәк телендә Үзбәкстанның тулы тарихын язарга җөрьәт иткән, күп кенә чорлар буенча югары дәрәҗәдә язылган фәнни хезмәтләр авторы буларак кереп калды. Ул Үзбәкстан тарихында беренчеләрдән буларак Коръәнне үзбәк теленә тәрҗемә итә, аңа үзбәк телендә тәфсир (комментарийлар) ясый, тик әлеге академик хезмәт, кызганыч, тентүләр вакытында эзсез юкка чыга.

Фәнни тикшеренүләре һәм хезмәтләре өчен Булат Салиев 1931 елда Кемаль Ататөрек тарафыннан оештырылган Төрек тарих җәмгыятенә мактаулы әгъза итеп сайлана (Turk Tarih Kurumu). Бүгенге көндә дә галимнең Үзбәкстандагы фәнни-педагогик эшчәнлеге һәм хезмәтләре онытылмый. Аны хаклы рәвештә Үзбәкстанның XX гасырдагы иң мәшһүр тарихчылары белән бер рәткә куялар, тарих буенча беренче үзбәк профессоры, үзбәк һәм гомумән Урта Азия тарихы фәнни мәктәбенә нигез салучы галим буларак таныйлар [Германов, с. 125]. Моннан тыш, Б.М. Салиев, беренчеләрдән булып үзбәк телендә типография ысулы белән фәнни хезмәтләр язып бастыручы тарихчы һәм шәркыятьче галим, Урта Азия халыклары мәгарифе үсешенә биниһая зур өлеш керткән, тарихта беренче тапкыр Үзбәкстанның төрле шәһәрләрендә югары уку йортлары ачкан һәм аларга җитәкчелек иткән татар мәгърифәтчесе дә.

**Әдәбият**

*Германов В.А.* Профессор Пулат Салиев: судьба и драма // История и историки Узбекистана в XX столетии. Ташкент: Navro'z, 2014. 428 с.

*Саидкулов Т. С.* Очерки историографии истории народов Средней Азии: Учеб. пособие для студентов. Ч. I. Ташкент: Укитувчи, 1992. 192 с.

*Салиев Булат.* Үзбәкстан һәм Таҗикстан. Ташкент: Үздәүләт нәшрияты, 1926. 104 б. (үзбәк телендә).

*Салиев Булат.* Мангытлар солтанаты дәверендә Бохара өлкәсе. Ташкент: Үздәүнәшр., 1925. 18 б. (үзбәк телендә).

*Салиев Булат.* Бохара тарихы. 1 нче кыйсем. Мәскәү нашире Бохара халык мәгарифе, 1923. 36 б. (үзбәк телендә).

Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 5. Казань: ИТЭ, 2010. 736 с.

Узбекистон тарихи (1917–1991 йиллар). К. 1. Узбекистон 1917–1939 йилларда. Тошкент: «Ozbekiston» НМИУ, 2019. 560 б.

*Шигабдинов Р.* Узбекистанская интеллектуальная элита: вторая половина 20-х годов XX века.Ч. 2 https://ia-centr.ru/experts/test/2228/

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 2-335

*А.Ә. Зиннәтуллина*

# ДИН ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ МАНСУР ӘЛ-БОРЫНДЫКЫЙ

Данная статья посвящена известному религиозному деятелю первой половины XVIII века, выходцу из деревни Бурундуки Кайбицкого района РТ Мансура аль-Бурундуки. В статье излагается его религиозная, научно-педагогическая и государственная деятельность, приводятся некоторые факты и сведения из жизни.

**Ключевые слова:** село Бурундуки, Мансур ал-Бурундуки, Мухаммеджан Хусаинов, ахун, «Таракийбе Мансурия», В. Татищев, «История Чингиз-хана».

This article is dedicated to the famous religious figure of the first half of the XX century Mansur al-Burunduki. He was born in the village of Burunduki in the Kaibitsky district of the Republic of Tatarstan. The article describes his religious, scientific, pedagogical and state activities. Some facts and information from his life are also given.

**Keywords:** village Burunduki, Mansur al-Burunduki, Muhammedjan Khusainov, akhun, «Tarakyb-e Mansuria», V.Tatishchev, «History of Genghis Khan».

Элек-электән Идел елгасының уң ярын алып торган өлкәне Җәбәлстан, ягъни Тау ягы дип атап йөрткәннәр. Бүгенге көндә әлеге территориягә Татарстан Республикасының Апас, Кайбыч, Яшел Үзән, Югары Ослан, Буа районнары керә. Тарих битләренә күз салсак, Тау ягыннан чыккан алдынгы карашлы, күренекле шәхесләр байтак. Монда мәгърифәтче Каюм Насыйри, Уральскида Г. Тукай белем алган атаклы «Мотыйгия» мәдрәсәсенә нигез салган Мотыйгулла Төхвәтуллин, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Гайнетдин Әхмәров һәм башкаларның исемнәрен атап үтәргә була. Оренбург төбәгенең беренче ахуны, Мәхкамәи шәргыя Оренбургиянең беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновның да нәсел тармагы шушы төбәккә, хәзерге Кайбыч районының Борындык авылына барып тоташа.

Кайбыч районы Татарстан Республикасының көнбатыш өлешендә урнашкан. Ул чагыштырмача яңа барлыкка килгән район дисәк, ялгыш булмас. Чөнки район 1927 елда оештырылып, берникадәр үзгәрешләр кичергәннән соң таркатыла, һәм 1991 елның 19 апрелендә яңадан торгызыла. Әлеге район территориясенә кергән җир биләмәләре революциягә кадәр Зөя, Тәтеш һәм Чуел өязләренә караган.

Риваятьләргә караганда, Борындык авылы Бөек Болгар дәүләте таркалган чорда барлыкка килә. Арыслан исемле кешенең ике улы Болгардан Зөя янына күченеп килә. Бер улы – Борындык баба, икенчесе Чулпан баба исемле була. Борындык баба дигәне Бәрле суы тамагындагы урман эчендә урын ачып, нигезен булдыра. Авыл исеме шуннан барлыкка килгән икән.

Каюм Насыйри язмаларында Борындыкның борынгы һәм бай авыл булуы, анда мәчет-мәдрәсәләр эшләве турында мәгълүматлар бар [Насыйри, 3т., б. 203–205]. Дөрестән дә, Борындыкның күптәнге авыл булуы турында тарихи дәлилләр шактый. Мәсәлән, Зөя өязенең 1565–1567 елгы теркәү кенәгәсе буенча, Казан ханлыгы чорында бу авылда татар, чуваш һәм руслар яшәгән [Писцовая книга...]. И.П. Ермолаевның «Казанский край во второй половине XVI–XVII вв.» дигән хезмәтендә әлеге авылга кагылышы булган берничә документ теркәлгән [Ермолаев, с. 58, 59, 128, 153, 208].

Мансур бине Габдеррахман бине Әнәс әл-Борындыкый – Борындык авылын дөньяга таныткан шәхесләрнең берсе. Ул – мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур бине Габдеррәхим бине Әнәс әл-Җәбәли әл-Борындыкыйның бабасы, ахун, танылган галим, дәреслекләр авторы һәм тарихчы. Фәнни даирәдә әлеге шәхес Мансур әл-Борындыкый, Мансур Габдрахманов, Габдулла әл-Болгарый тәхәллүсләре белән дә билгеле.

Чыганаклардан күренгәнчә, «ахун» – фарсы сүзе. Ул «остаз», «укытучы» мәгънәләренә ия. Әлеге исемне йөртүче шактый дәрәҗәле кеше булып саналган. Ул – тиешле белеме булган, гарәп телен яхшы белгән, мулла һәм мөхтәсибләрдән югарырак дәрәҗәдәге рухани. Димәк, Мансур әл-Борындыкый заманы өчен киң танылган шәхес була. Шуңа да карамастан, аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында мәгълүматлар бик аз сакланган. Әлеге шәхес безгә, нигездә, Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдин хезмәтләре аша билгеле.

Галимнең туган һәм үлгән елларын төгәл күрсәткән тарихи документлар әлегә табылмаган. Әмма, ревизия язмаларына нигезләнеп, туган елы 1676 булырга тиеш, дигән фикерләр бар [Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман, с. 11]. Борындык авылының 1716 елгы ревизия язмаларыннан күренгәнчә, ул елны Мансур Габдрахмановка (чыганакта Абрахменев. – *З.А.*) 40 яшь, аның ике хатыны (Хәлимә Кадрәлева, 40 яшь һәм Гөлбәр Мәмәкова, 20 яшь) һәм ун яшьлек кызы Рәбига була [Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман, с. 28].

Мансур әл-Борындыкый баштан Дагстанда укып кайткан Мамадыш өязе Симет авылы мөдәррисе Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети мәдрәсәсендә белем ала [Мухаметзянова, с. 82], соңыннан Бохарага барып гыйлем эсти. Ул Казан ханлыгы Россия хакимлеге астына кертелгәннән соң, Бохарага барып белем алучыларның беренчесе булып санала [Мәрҗани, б. 236]. Чит җирләрдә белем алып кайткач, ул үзен, әлбәттә, башкалардан өстен саный, башка муллаларның, үз укытучыларының фикерләре белән килешми, аларның кимчелекләрен күрсәтергә тырыша, һәм, шуның нәтиҗәсендә, күп кенә каршылыкларга очрый.

Аның турындагы мәгълүматлардан күренгәнчә, ахун зур мәдрәсә тотып, күп шәкертләр җыйган. Белем бирү системасына да үзгәрешләр керткән. Ул вакытта мөдәррисләр мәдрәсәләрдә башлангыч сыйныфларга сарыф (гарәп теленең морфологиясе) буенча – «Зәнҗани»,

нәхүдән (гарәп теленең синтаксисы) «Мисбах» белән «Ифтитах» китаплары буенча укыта торган була. Мансур әл-Борындыкый исә, Бохарадан кайткач, яңа тәртип куллана башлый, ягъни сарыфтан «Бидан» һәм «Шәрхе Габдулла», ә нәхүдән «Кавагыйдә» һәм «Гавамил» китаплары буенча дәрес бирү тәртибен кертә. [Фәхретдин, 1 т., б. 36]. Алга таба бу китаплар кадими мәктәпләрдә төп уку әсбабы булып хезмәт итәләр. Татарның XX гасыр башында мәйданга чыккан зыялы шәхесләре һәм мәгърифәтчеләре үзләренең истәлекләрендә әлеге китаплар буенча белем алуларын, аларны күчереп язуларын искә алалар [Ризаэтдин, б. 16–17]. Соңгырак чорда бу китаплар татар галимнәренә гарәп теле буенча дәреслекләр төзү өчен нигез булып та торган.

1727 елда Мансур әл-Борындыкый Габдулла әл-Болгарый тәхәллүсе белән «Әл-гавамилел-мийә» китабына аңлатма рәвешендә фарсы телендә «Тәракыйбе Мансурия» («Чәчелгәннәрне җыйнау») әсәрен яза. Р. Фәхретдин әлеге хезмәткә югары бәя биреп: «Бу әсәре арабызда шулкадәр күп күренә ки, мондый зур күләмле бер китапның каләм илә язылып, бу кадәр күп таралуыннан әлеге шәхеснең шәкертләре күп вә шөһрәте дә аеруча зур булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин», ди, әлеге китапның башлангыч сыйныф укучылары арасында XX йөз башында да кулланышта булганлыгын ассызыклый [Фәхретдин, 1 т., б. 39, 36].

Мансур әл-Борындыкыйның киң җәмагатьчелеккә моңа кадәр билгеле булмаган тагын бер хезмәте бар. Ул «Тарих әл-Чыңгызхан» дип атала. Бу тарихи хезмәт көнчыгыш халыклары тарихы белән тирәннән кызыксынган, ләкин аларның телләрен белмәгән галимнәр В.Н. Татищев һәм П.И. Рычков соравы буенча, гарәп чыганагыннан татар теленә тәрҗемә ителгән. Рус галимнәре куллана алсын өчен, хезмәт алга таба рус теленә тәрҗемә ителә.

Ахун әсәрне XIV гасыр галиме Җамал Каршиның хезмәтенә нигезләнеп, үзе дә шактый үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп иҗат итә [Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман, с. 30]. Мансур әл-Борындыкыйның бу хезмәте 2018 елда Д.В. Мөхетдинов һәм И.В. Зайцев тырышлыгы белән фәнни кулланылышка кертелде [Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман]. Авторлар раславынча, «Тарих әл-Чыңгызхан» – бүгенге көндә Россия мөселманнары тарафыннан иҗат ителгән фәнгә билгеле беренче тарихи хезмәт. Димәк, ул Көнчыгышны өйрәнү өлкәсендә әһәмиятле чыганак булып тора, дияргә мөмкин.

Бүгенге көннәрдә дөнья күргән әлеге китап Д.В. Мөхетдиновның кереш сүзе белән башланып китә. И.В. Зайцев үзенең күләмле генә мәкаләсендә хезмәтнең язылу тарихы, аның эчтәлеге, кайларда саклануы һәм кемнәр тарафыннан өйрәнелүе белән таныштыра. Алга таба Мансур әл-Борындыкыйның татар телендә язган кулъязмасының фотокүчермәсе, әлеге кулъязманың 1741 елда ясалган русчага тәрҗемәсе, шулай ук, хезмәтне чыгаруга тырышлык куйган галимнәрнең үзара язышкан хатлары урын алган. Күренгәнчә, басма шак-

тый эчтәлекле. Безнең өчен әлеге китапның әһәмияте шунда: ул, төзүче авторларның язмаларына нигезләнеп, Мансур әл-Борындыкыйның тәрҗемәи хәленә күпмедер дәрәҗәдә ачыклык кертергә мөмкинлек тудыра. Чөнки Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдин хезмәтләрендә ахунның соңгы еллары турында мәгълүмат бирелмәгән.

И.В. Зайцев мәгълүматларына караганда, Мансур әл-Борындыкый XVIII гасырның 30–40 нчы елларында хәзерге Оренбург өлкәсендә гомер кичерә. Ул Оренбург экспедициясендә ахун вазифасын башкара, Кече җөз ханы Әбелхаирның Оренбургта тоткынлыкта булган улының укытучысы һәм тәрҗемәчесе була. 1738 елда Орск шәһәрендә агачтан зур булмаган беренче җамигъ мәчетне төзетә һәм аның беренче имамы да була [Ислам на Урале, с. 285–286].

Самарада В.Н. Татищев татар-калмык мәктәбе оештыра. Монда лингвистик материаллар җыю, көнчыгыш әсәрләрен тәрҗемә итү буенча эшләр алып барыла. Бу мәктәптә 1737–1739 елларда көнчыгыш телләрен Мәхмүд Габдрахманов исемле кеше укыткан, дигән мәгълүмат бар [История отечественного..., с. 46] И.В. Зайцев фикеренчә, әлеге шәхес һәм «Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов» сүзлегендә искә алынган Мәхмүд ахун Габдрахманов – безгә билгеле Мансур әл-Борындыкый. Биобиблиографик сүзлектә аның татар, фарсы, гарәп телләрен яхшы белүе искә алына. Димәк, ул ким дигәндә дүрт тел белгән. Мансур ахун П.И. Рычков тәкъдиме белән эшләнә башлаган русча-татарча-калмыкча сүзлекне (А, Б, В хәрефләре) төзүчеләрнең дә берсе булган [Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман, с. 27].

Мансур әл-Борындыкый тәрҗемә эшен 1740 елның августында тәмамлый. Әлеге датага нигезләнеп, ахунның яшәгән елларын да чамалап әйтеп була, ул 1676–1740 еллар аралыгына туры килә.

Күренгәнчә, Мансур әл-Борындыкый гыйлемле һәм тәвәккәл кеше була. Күп шәкертләр җыеп, мәдрәсәсендә муллалар әзерләве, күренекле мөдәррис буларак, белем-тәрбия бирүдә яңа дәреслекләр куллануы, рус хакимиятенә хезмәткә керүе – моның ачык мисалы. Шул ук вакытта ул, Россиянең Кече җөз белән мөнәсәбәтләрен көйләүдә катнашкан ахун, дәүләт эшлеклесе дә.

**Әдәбият**

*Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман ибн Анас ал-Бурундуки.* История Чингисхана / вступ. сл. Д. Мухетдинов; встп. ст., подготовка текста, указ. И.В. Зайцев. М.: Медина, 2018. 176 с.

*Ермолаев И.П.* Казанский край во второй половине XVI–XVII вв. (Хронологический перечень документов). Казань: Изд-во Казан. ун-та., 1980. 264 с.

Ислам на Урале: энциклопедический словарь / Коллект. автор.; сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. М.: Медина, 2009. 404 с.

История отечественного востоковедения до середины XIX века. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1990. 435 с.

*Насыйри Каюм.* Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 384 б.

*Мәрҗани Ш.Б.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

*Мухаметзянова Д.С.* Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. 216 с.

Писцовая книга Свияжского уезда 1565–67 г. //http://yakov.works/acts/16/2/1565sviyazhsk.htm (дата обращения 29.04.2020)

Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 1999. 224 б.

Татар энциклопедия сүзлеге / баш мөхәррир М.Х. Хәсәнев; җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. Казан: ТР ФА Татар энциклопедия институты, 2002. 830 б.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4: М–П. 768 с.

*Фәхреддин Ризаэддин.* Асар. 1 т. Казан: Рухият, 2006. 360 б.

***Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 82-141

***Р.Ф. Сафиуллина***

# ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙНЫҢ «РИСАЛӘИЛ-ИРШАД» ПОЭМАСЫНДА ФОЛЬКЛОР ҺӘМ СУФИЧЫЛЫК ШИГЪРИЯТЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Дидактическая поэма «Рисаляи-ль-иршад» татарского поэта Габдельджаббара Кандалыя написана в традициях «Пэнднамэ» ‘Аттара и др. суфийских поэтов, а также татарского фольклора. В поэме, состоящей из двадцати восьми глав, автор убедительно «наставляет» читателей на путь истинный, призывает к добрым помыслам и действиям. О принадлежности поэмы к конкретной поэтической школе и традиции свидетельствует использованный автором язык: произведение Кандалый обогащено арабо-персидской и османской мусульмано-суфийской лексикой.

Принадлежность поэмы традициям татарского религиозного фольклора доказывается в статье тем, что Кандалый вставляет в свое произведение мунаджаты – песенный религиозный фольклорный жанр, обращение к Всевышнему с молитвой. Кроме того, в поэме встречается множество крылатых слов и выражений, которые реминисцируют с образцами афористических жанров фольклора.

Приверженность поэмы «Рисаляи-ль-иршад» мусульмано-суфийским поэтическим традициям обосновывается тем, что в данном произведении присутствует ряд признаков подобной литературы: традиционный зачин с восхвалением Всевышнего, Творца; форма самоуничижения лирического героя; суфийская символика и свойственные жанру тропы и др. средства выразительности, как то: олицетворение, придание смерти качеств одушевленного предмета и, наоборот, изображение существующего на этом свете, живого человека – спящим и т.д.

**Ключевые слова:** Габдельджаббар Кандалый, фольклор, традиция, «Рисаляи-ль-иршад», суфийская поэзия, дидактическая поэма, мунаджат.

The Didactic poem «Risalah-al-Irshad» by the Tatar poet Gabdeljabbar Qandaly is written in the traditions of «Pandname» by ‘Attar and other Sufi poets, as well as Tatar folklore. In the poem, which consists of twenty-eight chapters, the author calls for good thoughts and actions. The language used by the author testifies to the poem's belonging to a specific poetic school and traditions: the work of Qandaly is enriched with Arab-Persian and ottoman Muslim-Sufi vocabulary.

The poem's belonging to the traditions of Tatar religious folklore is proved by the fact that Qandalyy inserts munajats – religious songs, an appeal to the Almighty with prayer – into his work. In addition, the poem contains aphorisms and expressions that create a reminiscence with examples of aphoristic genres of folklore.

The adherence of the poem «Risalah-al-Irshad» to the Muslim-Sufi poetic traditions is justified by the fact that this work contains a number of signs of such literature: the traditional beginning with the praise of God; a form of self-deprecation of the lyric hero; Sufi symbolism and personification peculiar to the genre.

**Keywords:** Gabdeljabbar Qandaly, folklore, tradition, «Risalah-al-Irshad», Sufi poetry, didactic poem, munajat.

XIX йөзнең танылган шагыйре Габделҗаббар Кандалый (1797–1860) иҗаты күп гасырлык госманлы-төрки, гарәп-фарсы һәм татар әдәбиятына һәм татар фольклорына нигезләнә. «Рисаләил-иршад» поэмасын шагыйрь мәдрәсәдә уку чорында иҗат иткән. Әлеге әсәр элгәрерәк заманнарда яшәгән авторлар шигъриятенә ияреп язылган, ягъни нәзирә. Фәридеддин Гаттарның «Пәнднамә»се һ.б. суфи шагыйрьләренең нәсыйхәт, үгетләү, вәгазьгә корылган әсәрләре традициясенә тугрылыклы бу поэманы дидактик суфичылык әдәбиятына һәм шулай ук татар фольклорына нисбәттә карарга мөмкин.

Автор әсәрнең максатын поэманың исемендә үк ачып бирә: «Рисаләил-иршад»ны гарәпчәдән «Үгет-нәсыйхәт китабы» кебек тәрҗемә итәргә мөмкин. Үгет-нәсыйхәтләрнең адресаты итеп Кандалый үз заманының укый белгән, шактый ук мәгърифәтле, яшәү мәгънәсе турында уйланган кешеләрен күрә. 28 бүлектән торган «Рисаләил-иршад» поэмасының башыннан ахырынача шагыйрь үз укучысын тәкъвалыкка, игелеккә, мәгърифәтлелеккә өнди – чын мөселман булырга омтылырга үгет-нәсыйхәт кыла.

Бөтебдер Гъәбде-л-Җәббар,
Нәсыйхәт һәрберсе нә-чар,
Тәмам ошбу рисаләдә
Вәгъәзләр бабедин ачар [Госманов, б. 246][1].

Гарәп-фарсы, госманлы һәм архаик татар сүзләрен, мөселман-суфи лексикасын мул кулланып язылган поэма кереш белән ачыла. Традиция буенча, мөселман Шәркы авторларының дини-дидактик лирик әсәрләре Аллаһы Тәгаләне олылаудан, Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм), кайчакта – аның сәхабәләрен һәм замандашларын мактаудан башланып китә. Кандалый да шушы традициягә тугры калган. Фольклорчы Айсылу Садекова әлеге күренешне болай аңлата: «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ыннан ук, алга таба – XVIII–XIX гасырлар татар шагыйрьләре әсәрләрендә Аллаһны һәм Пәйгамбәрне традицион мактау-одалар барлык әдәби әсәрләрдә очрый, фольклорда ул мөнәҗәт жанрында яңгырый» [Садекова, б. 208]. Хәзерге заман мөнәҗәтләренә дә шул ук мотивлар хас, ә бу шигъри мактаулар – мәдхияләрнең фольклорга да йогынтысы гаять зур булганлыгы турында уйлануларга этәрә.

Поэмада шулай ук фольклорның афористик жанрларына реминисценцияле (хәтерләткән, аваздаш) тапкыр гыйбарәләр, канатлы сүзләр еш очрый. Фольклор (мөнәҗәт һәм афористик жанрлар) һәм әдәби әсәрнең, бу очракта Г. Кандалый поэмасының, аваздашлыгы – аларның дини, суфичыл идеология белән сугарылган булуында. Поэмада шагыйрь нәсыйхәте:

---

[1] Г. Кандалый поэмасыннан барлык цитаталар күрсәтелгән хезмәттән алып китерелә.

Укый күргел кичә-көндез,
Гыйлемлек хәсълидә тиз-тиз,
Бәнемдик калмагыл гаҗиз,
Җәһаләтдә улып гъишйан.

Татар халык мәкальләреннән мисал:

*Надан кеше – яман кеше. Наданның аяк баскан җирендә үлән корыр.*

Мөнәҗәттә нәсыйхәт үрнәге:

Укы Коръән илә намаз...

«Рисаләил-иршад» суфичыл дидактик поэма традициясенә ияреп язылган. Суфи шагыйрьләр, дәрвишләр – үзләрен минималь уңайлыклардан да мәхрүм иткән һәм көннәрен-төннәрен Аллаһка дога кылуга багышлаган аскетлар. Суфи авторлар иҗатына үз шәхесен кечерәйтеп яки бөтенләй юкка чыгарып күрсәтү әдәбе – мәләмәтийә традициясе хас [Мухаммад, с. 41]. Әлеге күренешнең мәгънәсе шул: кеше, кем генә булмасын, ни белән генә шөгыльләнмәсен ул – барыбер Аллаһ Тәгаләнең күпсанлы мәхлүкларының берсе, колы; табигать каршында көчсез, тәкъдирен үзгәртә алмый, хәтта гөнаһлардан хали түгел, дөнья яралышы, галәм хакында белеме-хәбәре бик тә чикләнгән һ.б. Шул ук вакытта бәндә, Аллаһ каршында үзенең зәгыйфьлеген, мескенлеген танып, Раббысыннан мәрхәмәт-шәфкать сорап дога кылу мөмкинлегенә ия.

Мөселман-шәркый халыклар әдәбиятында әлеге күренеш байтак чагылыш тапкан. Ул аеруча суфи шагыйрьләр Ф. Гаттар, Ә. Ясәви, С. Бакыргани, Мәҗлиси, Аллаһияр, Хәмдәми иҗатында күренә. Мәсәлән, XVI йөз шагыйре Мөхәммәдъяр үзен «фәкыйри» – «ярлы, хәерче» дип атый. Әдәбият белгече Фәрит Яхин фикеренчә, үзләрен «фәкыйри» дип атау традициясе Әхмәд Ясәви дәвамчыларында, шулай ук нәкышбәнди тарикатендә очрый [Яхин, б. 200]. Мәгълүм булганча, Идел буе татарлары арасында суфичылыкның әлеге ике тарикате шактый ук таралган була, димәк, Габделҗаббар Кандалый поэмасында лирик геройның үз-үзен кимсетеп күрсәтүе ул – төрки-татарлар арасында гадәтигә әверелгән күпгасырлык дини-суфичыл һәм әдәби традицияләргә тугрылык. Моннан тыш, лирик геройның тыйнаклыгы һәм үз-үзен «кимсетүе» – поэманың укучыга тәэсирен, эмоциональ йогынтысын арттырырга һәм образлылыгын баетырга тиешле өстәмә әдәби алым да.

Поэма төгәл хронологиягә корылган: автор үгет-нәсыйхәтләрне балалык чорыннан башлый һәм кеше гомеренең барлык дәверләре хакында яза. Инсан олыгая төшкән саен, аңа адресланган нәсыйхәтләр дә үзгәрә. Әсәрдә алар яшь тәртибе буенча һәм җәмгыяви төркемнәрнең, мәсәлән, гендер билгесенә мөнәсәбәтле рәвештә, аерым бүлекләр итеп урнаштырылган. Моннан тыш, Кыямәт көне, җәннәт, хур кызлары; хак мөселманнарга Аллаһы Тәгаләне күрергә рөхсәт ителәчәге турында хәбәр; бу дөньяның чикләнгән һәм

азагы булуы турында фәлсәфи уйлануларга нигезләнгән гомуми бүлекләр бар.

Балалык чорына багышланган беренче бүлек «Нәсыйхәт фи вакъты-с-сабый вә вәгъзәһү» дип атала. Шәригать буенча, балалык тумыштан алып 9–12 яшьләргә чаклы дәвам итә. Автор фикеренчә, балалар вакытны уен белән генә уздырырга тиеш түгел: алар үзләрен киләчәктә тәкъвалыкка һәм дөрес яшәү рәвеше алып барырга әзерләргә тиешләр. Моның өчен гыйлем алырга, ислам диненең биш баганасын яхшы белергә һәм дин таләпләрен үтәргә, остазларга һәм ата-анага илтифат күрсәтергә, аларны хөрмәт итәргә кирәк.

«Рисаләил-иршад» поэмасының икенче бүлеге – «Егетлек вакытындагы нәсыйхәтләр вә вәгъәзләр» яшь-җилкенчәккә багышланган. Өченче бүлек – «Кызларга улган нәсыйхәтләр, вәгъәзләр бәйане» турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Һәр заманда, ләкин бигрәк тә ислам дине һәм шәригать кануннары гамәлгә керү белән, кешелек җәмгыятендә хатын-кызга, аның гыйффәтен, намусын саклауга карата таләпләр зур була. Ислам кануннары буенча, кыз бала, хатын, ананың роленә тагын да ныграк әһәмият бирелә башлый. Бу турыда, хатын-кызга багышланган әсәрләр белән беррәттән, төрле халыкларның фольклор әсәрләре ачык сөйли. Күргәнебезчә, «хатын-кыз мәсьәләсе» XIX йөз татар шагыйре Г. Кандалыйны да битараф калдырмаган.

«Тәләттыйфлык белән сөйләмәк бәйане» – матур, җанга ятышлы сөйләм турындагы бүлек. Урынлы, матур яңгырашлы сүзләрнең йогынтысын шагыйрь энҗе бөртекләренең балкуы белән чагыштыра. Әмма сүз белән җәрәхәт ясарга да мөмкин, дип саный автор.

Сүәксез дел яратды Хакъ,
Сүзи та кыйладыр йомшак,
Җәрахәт дел белән кыйлмак
Яман эн-нәйзаи Бәһрам.

Сүз көченә әлегедәй җитди караш фольклор жанрларында да чагылыш тапкан. «Тел белән Бәһрам кылычыдай яра салырга мөмкин» дигәндә, Кандалый Урта гасырлардагы таҗик-фарсы халык дастаны персонажын күздә тота. Шул рәвешле, әсәрнең образлылыгы, хиссилеге тагын да байый. Кандалый поэмасында телгә алынган персонажның прототибы Бәһрам V, яки Бәһрамгур, Иранда Сасанилар династиясенең ундүртенче падишаһы булган (439 елда вафат) [Яхин, б. 57]. Ул үзе батыр һәм куркусыз, ә кылычы бик үткен, диелә риваятьтә. Димәк, шагыйрь үз иҗаты белән татар әдәбиятын яңа образлар, символлар, идеяләргә баета, төрле халыкларның әдәбиятара элемтәләрен ныгыта. Татар әдәбияты һәм фольклорның элек-электән бер-берсен тулыландыру үзенчәлеге күзәтелгән икән, димәк, Кандалый иҗаты халкыбызның фольклор фондын да баеткан.

«Рисаләил-иршад» поэмасында өлкәнлек чорына караган үгет-нәсыйхәтләр берничә аерым бүлек итеп бирелгән. Алар арасында

Кандалыйның субъектив «мин»ен һәм авторның гражданлык позициясен белдергән «Ирлек вакытындагы нәсыйхәтләр, вәгъәзләр», «Хәмийәтсез ирләрнең вә чапәк хатынларның нәсыйхәте», «Хатынларга улган нәсыйхәтләр бәйане», «Яман хатынлар бәйане вә ирен рәнҗеткүчеләр» дип аталган бүлекләр ифрат кызыклы. Чыннан да, биредә Кандалый кырыс дидактика, өйрәтү-күрсәтмә бирү алымын бер читкәрәк куеп, әлегәчә билгесез булып калган вәгазьче Габделҗаббарның индивидуаль «йөзен» ача төшә. Әлеге бүлекләрдә субъектив караш, бәя бирү нык сизелә. Мәсәлән:

Гаҗәб бу хиндәге ирләр
Бу дөнйаны «Безем!» – дирләр.
Хосусән Болгари йирләр
Җиһанә хирсъ улып дәр-зән.

Ягъни Болгар җирләреннән булган ирләр дөнья мәшәкатенә бик хирыс, фани дөньяны «безнеке» диләр, дип ачына шагыйрь. Кандалый үзенең автор позициясен белгертеп кенә калмый, ул көнкүрешкә артык бәйләнгәнлекне тәнкыйтьли, якташларының суфичылык идеалларыннан читләшүенә ризасызлыгын белдерә. Ике-өч гасыр элек Болгар җирләрендә яшәүчеләр өстенә ирекне һәм үз территорияне югалту афәте шуның аркасында килмәгәнме икән? Тышкы дошман каршында татар халкы нәкъ шушы ваемсызлыгы аркасында көчсез булып калмаганмы? Кандалый поэмасында бу сорауларга анык җавап табып булмас, ләкин автор укучыны әлеге темага уйланырга этәрә. Икенче яктан, бу строфа «Менә шундый заман җитәр» дигән популяр татар мөнәҗәтенә аваздаш.

Дөньяда ямь бетәр шунда –
Халык китәр уңга-сулга.
Изге гамәл һич кылмаслар,
Тәмам мал күп булыр кулда.
Аталарда гайрәт бетәр,
Балаларда шәфкать бетәр,
Туганнарда рәхмәт бетәр –
Менә шундый заман җитә [Мөнәҗәтләр, б. 36].

Шагыйрь алга таба да гомумкешелекнең фәлсәфи мәсьәләләре хакында уйлана. Мәсәлән, бу дөньяның тиз үтеп китәчәге, аңа алданырга ярамаганлыгын искәртә торган бүлек тулысынча татар дини фольклоры һәм мөселман-суфи дидактик поэзиясе үрнәкләреннән үрелгән.

Адәм гъәфләт үзә ятып,
Үлем киләдер уятып.
Әҗәл йайдин укый атып,
Һәмандәм къәсд итеп бәр-җан.

Адәм гафләт эчендә ята, үлем аны килеп уята... Үлемгә җанлы предмет сыйфатларын бирү һәм, киресенчә, исән кешене үлем

йокысына талган итеп күрсәтү – троплар һәм образлылыкны арттыру чаралары гына түгел. Бу – мөселман халыкларының традицион күзаллавы – фани дөньядагы тормышның бик кыска һәм аның мәңгелек тормышка әзерлек этабы гына булуы турындагы карашларга аллюзия. Поэмада ассызыклангача, биологик үлемнән соң да тормыш барлыгын онытмаганнарны – тәкъва мөселманнарны – әҗәл һич көтмәгәндә, әзерлексез килеш алып китми, үлем алар өчен куркыныч түгел. Әлеге карашлар традицион дидактик шигърияткә хас.

«Рисаләил-иршад»ның тагын бер үзенчәлеге – поэмада суфичыл әдәбиятка хас тел-стиль чаралары, символлар, троплар белән беррәттән, фольклор әсәрләренә, шулай ук Коръән һәм хәдисләргә реминесценцияләр, аллюзияләрнең күплеге. Шулай ук элекке чор шагыйрьләренә иярү – нәзирә һәм традицион символлар мул кулланылган.

Сәба йиле килеп һәббәт,
Нә вар наим күреп һәйбәт,
…Идеп гъәфләт шәрабен нуш,
Нигәчә ятасән мәдһуш? –
Күзең ач, бакыйбән күр уш:
Кичеп кәрван варадыр ан.

Иртәнге җил – сәба җиле таң атуын хәбәр итә. Суфи символикасы буенча, сәба җиле – ул Кыямәт көне. Ваемсызлык шәрабыннан авыз итеп, кеше хиссез кала, үлгәндәй ята, ягъни Аллаһ ризалыгына ирешү өчен берничек тә тырышмый. Фәрит Яхин фикеренчә, шәраб – ул суфилар гыйлемен тарату һәм шәригатьне өйрәнү дә [Яхин, б. 40]. Димәк, кеше ахирәт дөньясы турында уйламаса, шәригать белемнәрен алмаса һәм таратмаса, мәеткә тиң икән. Шулай ук бара торган кәрван һәм хиссез яткан кеше дә – мәгълүм суфи символлары. Кәрван дөньяның узгынчы булуын аңлата. Китеп бара, ерагая торган кәрван исә үлемне символлаштыра.

Фани дөньяның вакытлычалыгы, үлем һ.б. дини-фәлсәфи карашлар татар дини фольклорында, аеруча мөнәҗәтләрдә киң чагылыш тапкан. Татар әдәбиятында исә борынгыдан әсәрләргә мөнәҗәтләр кертү традициясе яшәп килә. Бу традиция хәтта Котб («Хөсрәү вә Ширин»), Харәзми («Мәхәббәтнамә), Утыз-Имәни иҗатларына барып тоташа, дип санала [Садекова, б. 250]. Әлеге күренеш поэмаларның һәм мөнәҗәтләрнең ритмикасы туры килү, шигъри әсәрләрне, мөнәҗәт көйләгәндәй, көйләп укырга мөмкин булу белән аңлатыла.

«Рисаләил-иршад» поэмасының соңгы бүлеге – «Мөнәҗәт» үзенә күрә бер нәтиҗә ясау, йомгаклау булып тора. Тулаем алганда, поэма – мөселман Шәркындагы суфичылык әдәбияты һәм татар-төрки фольклоры традицияләренә нигезләнгән, халыкның күңел көзгесен чагылдырган дидактик-вәгазь әсәренә бер матур үрнәк. Шушындый әдәби әсәрләр һәм дини фольклор – мөнәҗәтләр аркылы татарлар Коръәннең байтак күрсәтмәләрен үзләштергән. Кандалый поэмасын-

да халык яратып көйли торган мөнәҗәтләр дә, нәсыйхәтләр дә, Аллаһка дога-зикер дә, Пәйгамбәр хәдисләренә һәм Коръән аятьләренә аллюзия дә очрый.

Габделҗаббар Кандалыйның дини-дидактик «Рисаләил-иршад» поэмасы, яшьлек чорында язылган һәм башка әсәрләргә нәзирә булса да, татар шигъриятендә тирән эз калдырган. Поэманың өлешләре, аерым мөнәҗәтләр, мәкаль-әйтемнәр булып, фольклорга әверелгән.

**Әдәбият**

*Бертельс Е.Э.* Избранные труды. История литературы и культуры Ирана М.: Наука, 1988. 558 с.

*Госманов М.Г.* Бер гомердә ике чор // Кандалый Габделҗәббар. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 5–67.

Мөнәҗәтләр. Казан: Милләт. Б. 36.

*Мухаммад Ю.Х.* Суфийская энциклопедия (Часть I–II). Казань: Иман, 2004. 230 с.

*Садекова А.* Идеология Ислама и татарское народное творчество. Казань: Иман. 2000. 260 с.

*Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшр. 2000. – 268 б.

***Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 371.214.41=512.145

***М.М. Шәкүрова,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

# ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУНЫҢ ЯҢАЧА КУЕЛЫШЫНДА М.Х. КОРБАНГАЛИЕВНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ (1917–1941 еллар)

Данная статья посвящена исследованию научного наследия по методике преподавания татарского языка в 1917–1941 гг. Этот период характеризуется активным поиском новых теоретически обоснованных методов, приемов и форм обучения татарскому языку в школе. Особое место в методике преподавания татарского языка в школе этого периода занимают работы М.Х. Курбангалиева, который развивает на новой основе идеи К.Д. Ушинского, Каюма Насыри. Его уроки, отражающие методику работы с текстами и словарями, сочетание грамматической теории с практикой, и в наше время представляют большой интерес. В статье рассматриваются структура и содержание учебников татарского языка М.Х. Курбангалиева в историко-методическом плане.

**Ключевые слова**: научное наследие, преподавание татарского языка, структура и содержание учебников, М.Х. Курбангалиев.

This article is devoted to the study of the scientific heritage in the methodology of teaching the Tatar language in the 17–41 years of the 20th century. This period is characterized by an active search for new theoretically grounded methods, techniques and forms of teaching the Tatar language at school. A special place in the methodology of teaching the Tatar language at school of this period is occupied by the works of M.Kh. Kurbangaliev, who develops on a new basis the ideas of K.D. Ushinsky, Kayum Nasyri. His lessons, reflecting the method of working with texts and dictionaries, the combination of grammatical theory with practice, are of great interest in our time. The article discusses the structure and content of the Tatar language textbooks by M.Kh. Kurbangaliev in historical and methodological terms.

**Keywords**: scientific heritage, teaching of the Tatar language, structure and content of textbooks, M.Kh. Kurbangaliev.

Татар телен укыту методикасы тарихының үсеш этапларын нигездә алты чорга бүлеп карыйбыз: татар телен укытуның беренче адымнары (1740–1804), мәктәпләр өчен дәреслекләр, үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр язу, сүзлекләр төзү һәм тәҗрибә туплау чоры (1804–1890), татар телен укыту методикасының яңа юлларын эзләү чоры (1890–1917), татар телен укыту методикасының чәчәк аткан чоры (1917–1941), совет чоры татар телен укыту методикасы (1941–1990), татар телен укыту методикасының бүгенге торышы (1990–2020) [Шәкүрова, 2010, б. 207].

1917–1941 елларда татар мәктәпләрендә татар телен һәм әдәбиятын укытуның яңача куелышын, татар телен гамәлгә кую мәсьәләләрен күз уңында тотарга кирәк. Татар теленең фәнни эшләнеше

һәм аны дәүләт дәрәҗәсендә куллану – татар зыялыларын күптәннән борчыган төп мәсьәләләрнең берсе. 1917 елгы февраль революциясеннән соң бу юнәлештә беренче адымнар да ясала. Нәкъ шул елның 1–11 майларында Мәскәү шәһәрендә узган I Бөтенрусия мөселман съезды мәгариф өлкәсендә татар телен саклау һәм өйрәнү юнәлешендә мөһим карарлар кабул итә [Хаков, 2003, б. 241]. Әлеге чорда татар әдәби теленең фонетик нормаларын эшкәртү, әлифба һәм язу өлкәсендә яшәп килгән каршылыкларны хәл итү һәм орфографик кагыйдәләрне бер тәртипкә китерү, педагогика һәм методика фәнен эшләү, укыту ысулларын ачыклау, «үз эшен белеп эшләүче яхшы эшчеләр, ныклы халык ияләрен» тәрбияләү мәсьәләләре борчый.

1920–1930 еллар татар тел белемен яктыртуга вакытлы матбугат битләрендә, фәнни җыентыкларда зур урын бирелә: «Мәгариф» (1938 елдан «Совет мәктәбе»), «Безнең юл» («Атака», Совет әдәбияты»), «Татарстан» журналлары, «Кызыл Татарстан» газетасы һ.б. Бу чорда комплекслап укыту методы, Дальтон-план, бригада-лаборатория, проектлар методлары кулланыла башлый.

1927 елда Казанда Бөтенсоюз тел-әдәбият укытучылары конференциясе үткәрелә һәм тел-әдәбият укыту мәсьәләләре карала. 1928–1929 уку елында мәктәпләрдә уку-укыту эшләрен яхшырту юлында төрле чаралар үткәрелә һәм гамәлдәге дәреслекләрне тикшерүгә дә зур игътибар бирелә. Ул елларда башлангыч мәктәп дәреслекләренең эчтәлеген һәрьяклап яхшырту, аларны берничә еллык итеп стабильләштерү һәм ул дәреслекләрнең кайсы төбәкләрдә таратылырга тиешлеген билгеләү мәсьәләләре дә карала [Ибраһимов, 1994, б. 165].

1927 елда хөкүмәтнең махсус карары белән латин алфавиты татар теленең рәсми алфавиты итеп кабул ителә. 1939 елда М.Х. Корбангалиев Һәм Ш.А. Рамазанов тарафыннан төзелгән кирилл алфавиты проекты хөкүмәт указы белән рәсми төстә раслана. Алфавит алмаштыру үз чиратында уку-укыту барышын катлауландыра: яңа дәреслекләр һәм программалар, методик кулланмалар чыгару, уку китаплары бастыру, орфография кагыйдәләрен төзү, язуга кергән үзгәрешләрне һәм аермалыкларны күрсәтү һ.б.

Бу чорда татар телен укытуның яңача куелышында М.Х. Корбангалиевнең эшчәнлеге аеруча зур. Күренекле педагог, методист, тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе *Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев* 1873 елның 20 ноябрендә элекке Вятка губернасы Алабуга өязенең Биектау авылында туган. Ул халык мәгарифенә төпле нигез салучыларның берсе була [Вәлиева, 1951, б. 6]. Мирасы гаять зур һәм күпкырлы: әлифбалар, дәреслекләр, методик кулланмалар, программа һәм сүзлекләр, грамматика китаплары һ.б. Моны Г. Ибраһимов та үзенең «Мәдәни хезмәт юлында 30 ел» дигән мәкаләсендә (1925) ассызыклап үтә һәм М.Х. Корбангалиевне «мөхтәрәм карт педагог», уку-укыту мәсьәләләрендә «урыс-Аурупа нигезләрен өйрәтүче» буларак та бәяли [Шәкүрова, 2012, б. 45].

М.Х. Корбангалиев – XIX гасырның икенче яртысында иҗат иткән рус педагогларыннан К.Д. Ушинский, В.П. Вахтеров, А.П. Флеровларның эшчәнлеген дәвам иттерүче [Ханбиков, 1975, б. 106]. Аның педагогик эшчәнлеге һәм карашлары З.Т. Шәрәфетдинов тарафыннан җентекләп өйрәнелгән [Шарафутдинов, Ханбиков, 1998, б. 34].

1914 елдан «Мәктәп» (1918 елдан «Мәгариф» дип атала башлый) журналында татар телен укытуның эчтәлеге, максаты-бурычлары, укыту ысуллары һәм алымнары, төрле фән программалары турында мәкаләләр яза, тәрбия эшен дөрес алып барырга өйрәтә, рус һәм чит ил педагогларының прогрессив идеяләрен пропагандалый (Я.А. Каменский, Ж.Ж. Руссо, Д. Локк һ.б.).

1914 елда М.Х. Корбангалиевнең «Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты» дигән мәкаләсе «Мәктәп» журналында басылып чыга. Әлеге мәкаләдә автор төп ике ысулны билгеләп үтә:

1) имла,

2) күчереп яздыру.

«Әлеге ике ысул бер-берсеннән аерылгысыз кулланылганда гына укучыларның дөрес язуына ирешергә мөмкин», – ди М.Х. Корбангалиев [Корбангалиев, 1914, б. 116]. Методист «өйрәтү имласы укыргаязарга өйрәтүнең әүвәлге дәресләреннән башланып, урта мәктәпне тәмамланганчы дәвам итәргә тиеш» дип саный. Ул кабатлау имласы өйрәтү имласы дәресеннән соң үткәрелә һәм «алга таба яңа кагыйдәләр өйрәтергә кирәкме, я шул өйрәткәннәрен кабатлатуны дәвам итәргәме?» дигән сорауларны ачыкларга ярдәм итә» [шунда ук, б. 117].

М.Х. Корбангалиевнең «Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты» дигән мәкаләсендә дөрес язарга өйрәтү өчен, кагыйдә аңлату гына җитми, укучыларны шул кагыйдәдән файдалана белергә, аңа туры китереп, мисаллар табарга өйрәтергә кирәклеге ассызыклана. Биредә автор бүгенге көндә дә киң кулланылышта булган дәрес планын тәкъдим итә:

1. Сыйныф тактасына язылган мисалларны укыту һәм кагыйдә чыгарту.

2. Мисалларны ишетелерлек ачык һәм китапча әйтеп яздыру. Мисалларның авыр, катлаулы булулары истә тотылып, укучылардан берничә мәртәбә кабатлатылганнан соң гына дәфтәрләренә яздыру.

3. Мисалларны дөрес язу җәһәтеннән җентекләү өчен, укытучы үткән дәресләрдә өйрәнелгән кагыйдәләргә бәйләнешле сүзләрне таптыра, авазларга аерттыра. Әгәр мисаллар арасында кагыйдәсе аңлатылмаган сүзләр очраса, ул вакытта укытучы әлеге сүзләрнең язылу кагыйдәләрен өйрәтә. Шул рәвешчә, бөтен мисаллар җентекләп тикшерелгәч, балалар кагыйдәне кабатлагач кына, дәфтәргә яздыра башларга кирәк.

4. Яздырганны дөресләү. Иң элек балалар хаталарын үзләре сизәргә тиеш. Хаталарны һәрвакыт сыйныфта, балаларның үзләре алдында төзәтү уңышлырак. Укытучы хаталарның астына кызыл белән сызып, дәфтәрләрен сыйныфка алып килә дә, аларны шәкертләргә

биргәнче, иң әүвәл хаталарын сыйныф тактасына язып тикшертә [Корбангалиев, 1914, б. 119 ].

Укучыларны мәктәптә дөрес язарга өйрәтү бүген дә иң кыен мәсьәләләрнең берсе булып санала. М.Х. Корбангалиевнең «Ана теле методикасы» дигән хезмәтендәге (1918, 1920) «сүзнең дөрес язылышында шикләнсәгез, сүзлек китабыннан карап язарга, кечкенәдән балаларны сүзлекләр белән эшләргә күнектерергә кирәк» дигән фикерен билгеләп үтәсе килә. Әлеге хезмәттә галим дөрес язарга өйрәтүдә имла, күчереп язу, ятлаганнарны язып карау кебек эш алымнарына да туктала [Корбангалиев, 1920, б. 188].

Галимнең «Ана теле методикасы» (1918; 1920) дөрес укырга һәм язарга өйрәтү методикасының ачык мисалы булып тора. Кызганычка каршы, М.Х. Корбангалиевнең әлеге хезмәте бүгенге көндә дә җентекләп өйрәнелмәгән. Ул бик күп фәнни хезмәтләрдә, мәкаләләрдә саналып, телгә алынып кына үтелә. Бу китап 1918 елда «Укытучы» журналының 1–7 саннарында басыла. 1920 елда әлеге хезмәт тулыландырылып бастырыла.

Китапның кереш өлешендә М.Х. Корбангалиев дидактиканың мөһим тармагы булган методикага билгеләмә бирә, *«<...> милләтебезне артка калудан саклардай һәм милләтебезнең рухына ярдәм итәрдәй динле вә әхлаклы милләт балалары тәрбияләп чыгару»* дип, максатны да төгәл билгеләп куя. *«Үз эшен белеп эшләүче яхшы эшчеләр, нык халык ияләре, хезмәтне булдыручы кешеләр һәм җаны гына сәламәт булмый, бәлки тәне дә таза булган кешеләр»*не ничек тәрбияләргә? Аларга нинди мәгълүмат бирергә? Күпме күләмдә бирергә? Хәзерге тел методикалары да шушы ук сорауларга җавап эзли. *«Без тәрбиянең, укытуның төгәл максат, бурычларын белгәндә генә, аларның хак һәм тугры булуларына ышанганда гына үзебезгә йөкләнгән бөек эшне алып бара алачакбыз. Киресенчә булганда, тәгълим вә тәрбия эшләрен яхшы итеп эшләп булмаячак. Алар бөтенләй кирәкмәгән артык эш булып кына калачак»*, – дип, китапны язуның максатын күрсәтә [Корбангалиев, 1920, б. 3].

Автор башлангыч сыйныфларда уку-язуга өйрәтүнең ысулларын өч өлешкә бүлә, һәрберсенә җентеклэп туктала. Мәсәлән, 1) хәрефләрне җыеп укыту ысулының *(тәркип ысуллары)* төп гамәле – «сүзнең өлешләреннән бөтен сүзгә күчү, ягъни укыту хәрефләрдән яки авазлардан башланып, иҗекләргә вә сүзләргә күчү; 2) *тәхлил ысуллары* – укыту бөтен сүздән яки җөмләдән башланып, аларның өлешләренә, ягъни иҗекләргә, авазларга яки хәрефләргә күчү; 3) *тәхлил-тәркип ысуллары.* Болары белән укытканда, тәркип, тәхлил ысуллары бер-берсе белән төрле рәвештә багланып баралар» [шунда ук, б. 40].

Уку-язуга өйрәтү эшен җиңелләштерү максатыннан, автор рәсемнәр, шигырь-хикәяләр, уеннар, шакмакларны файдаланырга кирәклекне хуплый, дәреслекләрдә аларны иркен куллана. Рәсемле әлифбаларның тарихын тасвирлап бирә. Алты тигез өлешкә

бүленгән, һәрбер ягына берәр хәреф ябыштырылган шакмакларны XVII гасырда инглиз педагогы Локк тәкъдим иткән булган. Уйныйуйный укырга өйрәтүнең тамырлары Германиядән кергән.

Автор, хәреф белдерүне җиңеләйтү өчен, рус теле укытучылары тарафыннан балаларга, матур һәм җанлы итеп, кызыклы хикәяләр сөйләү алымына да шактый киң туктала: *«<...> бүген мин мәктәпкә килгәндә, юл буендагы бер баганага күз салдым. (Хәзер тактага шул багананың рәсемен төшерәбез дип, такта өстеннән аска таба бер тугры сызык сызган). Шул вакытта мин кинәт кенә бу баганага таба очып килә торган бер кош күрдем. Бу кош багана тугрысына очып килеп җитте дә аның өстендә әйләнеп очып йөри башлады. Моның да рәсемен төшерәбез. Мин бара торган җирдән туктадым да, ни булыр икән, дип карап тора башладым. Кош багана өстендә әйләнеп очып торды да, «э-э-э» дип кычкырып очып китте. Менә сез, балалар, моннан соң әлифбаларыгызда хәзер мин тактага исемнәрен төшергән багана белән кошка охшаган хәреф күрсәгез, кошның «ай, ы, ы» дип чыелдавын исегездә тотыгыз. Бу хәреф «ы» авазының галәмәтедер»*, – ди [Корбангалиев, 1920, б. 63]. М.Х. Корбангалиевнең «Ана теле методикасы»нда иң кызыклы, бүгенге көн өчен актуаль бер бүлек бар: укырга өйрәтү методикасы. Автор, укырга өйрәткәндә, иң элек сүзлерне күреп, зиһенгә алырга, ягъни күзнең бер хәрәкәте белән аларны берьюлы эләктереп ала белергә кирәклекне аңлата, баланың «уку даирәсен» тиз хасил итү турында уйлана. Укуның тышкы җәһәте (укуның йөгереклеге, дөреслеге һәм кычкырып уку) һәм эчке җәһәте (аңлап һәм тәэсирле уку) турында тирән мәгълүмат бирә. *«Шәкертнең фикере ничаклы ачык булса, ул ничаклы белемле булса, аерым-аерым сүзләрнең мәгънәсен ничаклы тизрәк аңласа, сүзләрнең бәйләнешләрен ничаклы җиңелрәк белсә, ул шулкадәр яхшырак укыячак. Без балаларның зиһеннәрен үстерергә тырышсак, шуның белән аларның укырга өйрәнүен җиңеләйткән булабыз»*, – дип, методист нәтиҗә ясап куя [шунда ук, б. 64].

Акрын уку уйлау гамәлен киметә, аңлап укуга зур тоткарлык ясый. Шуңа күрә автор балаларны йөгерек укуга ияләндерергә кирәклегенә басым ясый һәм аңа ирешү юлларын да тәкъдим итә:

1) сыйныфта һәм өйдә бер нәрсәне кабатлатып укыту;

2) мөмкин кадәр яңа мәкаләләрне укыту;

3) телдән әйтергә читен булган сүзләрне күчереп яздыру;

4) укытучының үрнәк өчен укып күрсәтүе.

М.Х. Корбангалиев балаларның укуларында китә торган түбәндәге җитешсезлекләрне күрсәтә: а) сүзләрнең хәрефләрен төшереп уку яисә хәрефләрне бутап уку, б) сүзләрне бозып әйтү, в) сүзләрнең басымнарын ялгыш кую, г) сүзләрне язылганча уку. «Кычкырып укырга дигәч тә, ул акыру дәрәҗәсендә каты булырга тиеш түгел. Балаларның кычкырып укуына ирешү өчен, укытучының гел «ишетмим, кычкырыбрак укы!» дип әйткәләп торуы шарт», – дип искәртә галим [шунда ук, б. 65].

Башлангыч мәктәпләрдә үк баланы аңлап, тәрбияле укырга гадәтләндергәндә, һәр сүзнең тәэсир итү көченә игътибар итү, аерым-аерым фикерләр һәм әсәрнең өлешләре арасында булган бәйләнышны күрү, бөтен әсәрнең төп нәтиҗәсен аермачык белүне күз уңында тота. Алга таба М.Х. Корбангалиев укылган әсәрне, мәкаләне логик тикшерү тәртибен бирә. «Аю белән бабай», «Бүре белән торна» хикәяләре, Г. Тукайның «Туган авыл» шигыре, М. Гафуриның «Маймыл белән күзлекләр» мәсәле һ.б. өстендә эшләгәндә, сорау-җавап формасында аңлау-аңламауларын тикшереп карау, сүзлек эше, нәтиҗә чыгару өчен план төзү, план төзүне уку белән бәйләү, өлешләргә бүлеп исемләү кебек бүленешне тәкъдим итә. Биредә «Бүре белән торна» хикәясенең таблица-үрнәк планы да урын ала:

| Кыскача җөмләләр төзү тәртибендә | Хикәя өлешләрен исемләү тәртибендә | Сораулар бирү тәртибендә |
|---|---|---|
| 1) Бүренең тамагына сөяк кадалган. | 1) Бүренең бәласы | 1) Бүре нинди бәлага дучар була? |
| 2) Ул торнадан тамагындагы сөякне алуны үтенгән. | 2) Бүренең торнадан ярдәм соравы | 2) Бүре торнадан нәрсә дип ялвара? |
| 3) Торна аның тамагындагы сөякне алган. | 3) Торнаның бүрегә иткән ярдәме | 3) Торна бүрегә ничек ярдәм иткән? |
| 4) Бүре торнага рәхмәт укыган. | 4) Безнең рәхмәт сүзебез | 4) Бүре торнага ничек ярдәм иткән? |

Укытучының тәэсирле уку чараларына да бәйнә-бәйнә туктала. Мәсәлән, уку тәэсирле булсын өчен, салмак, җиңел, һәм ачык булырга тиеш, сүзләрнең ахыры йотылмасын, әйтелеп бетсен, ачык тавыш белән укылсын [Корбангалиев, 1920, б. 119]. Шулай итеп, автор башлангыч сыйныфларда ук тавыш дәрәҗәсе, басымны куя белү, тавышны үзгәртә белү, тукталышларны эшләүнең зарурлыгын ассызыклый.

Уку китапларын төзегәндә, иң әүвәл галим балаларның «нәрсә укуга зәвыклары барлыгын тикшереп белергә кирәклеген» әйтә. Нәтиҗәләре дә уйланырлык:

*1. Күбрәк нәрсә укырга яратасың?*

*а) хикәяләр укырга – 73%;*

*ә) шигырьләр укырга – 22%;*

*б) әмсалар (кыйссалар) укырга – 5%.*

*2. Үзебез укырга яратабызмы, әллә кеше укыганны тыңларга яратасызмы?*

*а) үзебез укырга яратабыз – 77%;*

*ә) кеше укыганны тыңларга яратабыз – 23%.*

*3. Кешеләр хакында укырга яратабызмы?*

*а) кешеләр хакында укырга яратабыз – 38%;*

*ә) хайваннар хакында – 38%;*

*б) табигать хакында – 24%.*

*4. Бигрәк тә нинди хикәяләр укырга яратасыз?*

*а) озын хикәяләр укырга яратам – 80%;*

*ә) кыска хикәяләр – 20%.*

*5. Булган эш хакында укырга яратасыңмы, әллә әкият укыргамы?*

*а) булган эш хакында укырга яратам – 76%;*

*ә) әкият укырга яратабыз – 24%* [Корбангалиев, 1920, б. 90].

Димәк, балалар өчен төзелгән уку китапларында кешеләр турында булган озын хикәяләрнең күбрәк булуы шарт. Укучылар кешеләр белән булган вакыйгалар турында озын хикәяләрне үзләре укырга яраталар икән.

Галим әхлакый һәм фәнни мәкаләләр, кыйссалар, әкиятләр, шигырьләр укыганда, төп фикерне аңлап, ачык итеп аңлата белү, төрле фәннәрдән хакыйкый мәгълүмат биреп, шуларны хасил итәргә зәвыкландыру һәм укучыны китап укырга гадәтләндерү кебек эшләрне ваклап-ваклап тикшерә.

Әлеге хезмәттә укырга һәм сөйләргә өйрәтү белән бер дәрәҗәдә рәсем ясау зур урын алып тора. Дөрестән дә, 1917 елга кадәрле булган мәктәпләрдә рәсем дәресләре юк дәрәҗәсендә. М.Х. Корбангалиев ана теле дәресләрендә балаларның рухын тәрбияли торган бер зур чараның рәсем икәнлеген ассызыклый. Укыган вә сөйләгәнне рәсемгә төшертү укучының «рухи тормышын аңларга, эчке галәмен һәм мәнфәгатьләрен өйрәнергә» мөмкинлек бирә, ди автор. «Ана теле методикасы»нда уку һәм сөйләү рәсем ясау белән бергә тыгыз үрелеп бара. Укылган әсәр яки мәкаләне җентекләбрәк истә калдыру максатыннан, туган тәэсирләрне рәсемгә төшертү, рәсемле планнар төзетү кебек эш төрләре укучыны уйларга, фикерләргә өйрәтә. «Иң элек шәкертнең күңелендә укыган әсәрләреннән дөрес тәэсирләр хасил булырга кирәк; соңра бу тәэсирләр бергә теркәлеп, бер рәсем булырга тиеш; шәкерт сөйләгәндә, бу рәсемне күз алдына китерә белергә кирәк: ул бу рәсемне хәтта, вакыйгага карап, фараз кылып төзергә һәм аларның үзләренең тәртибенчә хәтерендә тотарга тиеш», – ди автор [шунда ук, б. 99].

Мәгълүм булганча, бүгенге тел дәресләренә *фәнни, коммуникатив һәм тәрбияви максатлар* куела. Тәрбияви максат үз эченә инсафлы, гадел, зәвыклы һәм шәфкатьле балалар тәрбияләүне ала. Мондый балаларны тәрбияләүдә, һичшиксез, рәсемнәр, картиналар зур роль уйный. Кызганыч, ана теле дәресләрендә әле хәзер дә картиналар белән эшләү техникасы нык аксый: алгы һәм арткы планда картинаны тикшерү, сүзсез уку, терәк сүзләр, күләгәләр, тамгалар һ.б. эш алымнары юк дәрәҗәсендә.

Гомумән алганда, XX гасыр башларында күтәрелгән проблемалар – укырга, сөйләргә, язарга өйрәтү методикасы һәм аларның рәсем сәнгате белән бәйләнешы – бүген дә актуаль.

М.Х. Корбангалиев грамматиканың (сарыф вә нәху дәресләре) сөйләү һәм язу телен үстерүдәге әһәмиятен, өйрәтү ысулларын

барлый. Шулардан бер ысулга аерым тукталып үтәсе килә. Тикшерү (тәхлил) ысулы методикада фәнни һәм гамәли ысуллардан санала. Галим җөмләгә яки сүз төркемнәренә анализ ясаганда, синтаксисны һәм морфологияне тирәнтен үзләштереп, гамәли куллана белү дә кирәк, ди. Мәсәлән, *«Гали балык тотты», «Гали балык тоткан»* дигән җөмләләрдә ия дә, хәбәр дә ачыклангач, автор «*тотты*» белән «*тоткан*» фигыльләренең бер-берсеннән аермасын таптыра: «*тотты» дигәндә, Галинең балык тотканын сөйләүче күзе белән күргән буламы? «Тоткан» дигәндә, Галинең балык тотканын сөйләүче күзе белән күргән буламы*? [Корбангалиев, 1920, б. 158].

*«Укыттырмак»* дигән сүзне сүз төзелеше ягыннан тикшергәндә (тамыр *-укы-; -т, -тыр* – мәҗбүр итү өчен булган ялгаулыклар) иң элек кемне кемнән укыту мәгънәсен ачыкларга куша. Тикшерү барышында балага «сүзнең мәгънәсе һәм сүзнең тышкы рәвеше алмашыну белән ул мәгънәнең үзгәрүенә (*китап, китапчык, йөртмәк, йөрттермәк*)» сәбәп булуын искәртә. Шулай итеп, тикшерү ысулы белән эшләгәндә, кагыйдәләр кабат искә төшерелә, ныгытыла. Укучы иҗади эшли.

М.Х. Корбангалиев шәкертләрнең чыгарган кагыйдәләрен белү дәрәҗәсен тикшерү, сынау максатыннан ике алым тәкъдим итә:

1. Балаларга әзер материал бирелә һәм алар бу материал эчендә булган сарыф һәм нәхү кагыйдәләрен табып күрсәтәләр. Мәсәлән, балалар җөмләнең иясе белән танышкан булсалар, аларга ияне табып күрсәтү өчен җөмләләр бирелә.

2. Шәкертләр яңа чыгарылган кагыйдәгә туры килгән сүз һәм җөмләләрне үзләре уйлап табалар.

Авторның икенче алымы уңышлырак тоела, чөнки балалар мөстәкыйль эшли. Мисалларны халык авыз иҗатыннан, матур әдәбияттан яки тарих, табигать кебек предметлардан алырга була.

М.Х. Корбангалиев шәкертләргә асылына төшенмичә өстән генә карап эшләрдәй үрнәкләр биреп, күнегүләр эшләтүне кискен тәнкыйтьли: «гади сыйфаттан чагыштыру сыйфаты ясату өчен сүзләр бирелгәндә, шәкерт башта бу эшне аңлап эшләсә дә, соңга таба автомат рәвештә генә кушымчадан файдалана, аның мәгънәсен уйлап та карамый. Шул рәвешле һичбер уйлап тормыйча «*алтын – алтынрак*» дип язып куячак. Укучыларга кызыклы, катлаулы, тормышта кирәк була торган күнегүләр бирергә кирәк».

Дөрес язарга өйрәтү эше мәктәпләрдә иң авыр мәсьәләләрдән санала. Чынлап та кагыйдә ятлатып кына укучыны дөрес язарга өйрәтеп булмый. М.Х. Корбангалиев инша (язма өслүп) дәресләренә игътибарны күп бирә. «Инша дәресләре, – ди автор, – шәкертне күргән, белгән, ишеткән һәм тәҗрибә кылган нәрсәләре хакындагы «үз» фикерләрен, «үз» тәэсирләрен һәм «үз» тойгыларын башкаларга белдерә белергә өйрәтү дәресләре». Галим балаларның аңы югары, камил дәрәҗәле булуын ассызыклап, болай ди: «*Биш-алты яшьлек баланың рухы үзенең биш-алты еллык гомерендә олы кешенең аңына сыя алмаслык дәрәҗәдә күп яңа тәэсирләр хасил иткән була. Балаларның*

*моннан соңгы рухи эшләре, үсеше фәкать бу балалык вакытында хасил иткән материалларына гына нигезләнеп башкарыла*» [Корбангалиев, 1920, б. 136].

Методист хикәя төзетү, инша яздыруның ни тәртиптә уздырыларга тиешлеген дә ачыклый: «Хикәят төзетү өчен *«Чана белән таудан шуу»* темасын алыйк. Бу хикәятне эшләгәндә шәкертнең хәтерендә булган материал белән файдаланырга бик мөмкин. Чөнки аларның бик азы гына бу уенны уйнамаса, уйнамагандыр; аларның күңеленнән бу материалны алып чыгару өчен күбесенчә «Тагы нәрсә хакында язарсың?» дигән бер сорау бирү дә җитә. Балалар шунда ук нәрсә хакында язарга уйлаганнарын әйтергә ашыга башлаячаклар. Фәкать алар әйткәннең барысын «кабул итеп, үзләре белән бергәләп «Нәрсә хакында язсак яхшы булыр, моны ничек итеп яхшырак, тәэсирлерәк итәргә мөмкин?» соравына җавап рәвешендә үткәрергә кирәк [шунда ук, 137]. Чынлап та, шундый мисалларны укучыларның үз тормышларыннан алсак, аларның фикерләре булыр иде, алар аны башкаларга ачык, аңлаешлы итеп сөйләп тә, язып та аңлатырлар иде.

Дөрес язуга ирешүгә тәэсир итүче иң мөһим нәрсә – уку. Күрү хәтере –сүзләрнең дөрес язылу рәвешләрен күз алдына китерү белән дөрес язуны бераз җиңеләйтә. М.Х. Корбангалиев дөрес язуга ирешүнең түбәндәге шартларын билгели:

– шәкерт һаман дөрес язуны гына күреп торырга тиеш,

– дөрес һәм ачык сөйләнгән сүзләрне генә ишетергә тиеш,

– дөрес язу белән генә шөгыльләнергә тиеш,

– шәкертнең күрү һәм ишетү әгъзасы һәм кулы фәкать дөрес язу өстендә генә тәрбияләнсен [шунда ук, б. 138].

Бу бүлектә шулай ук. М.Х. Корбангалиевнең бик тә кыйммәтле бер фикерен ассызыклап үтәргә кирәктер: сүзне ничек язарга читенсенгән вакытта сүзлек китабыннан («Справочный орфографический словарь») карап, дөрес язарга, балаларны кечкенәдән сүзлекләр белән эшләргә күнектерергә. Бу гына да түгел, дөрес язарга өйрәтүдә имла, дөрес күчереп язу, ятлаганнарны язып карау кебек эш алымнарына да туктала. Әлеге китапта унтугыз дәреснең үрнәкләре, сарфый вә нәхви тикшерү, дәрескә анализ ясау кебек мөһим эшләр урнаштырылган [шунда ук, б. 188].

М.Х. Корбангалиев үзенең «Ана теле методикасы» дигән хезмәтенең йомгаклау өлешендә дәресләрне өч төргә бүлә:

1) башлау дәресләре,

2) хәзерлек дәресләре,

3) әлифба укыта башлау дәресләре.

Галим дәресләрнең һәр төренә җентекләп туктала. Бигрәк тә әлифба укыта башлау дәресләре турында тулы мәгълүмат бирә, 19 дәрес үрнәген тәкъдим итә: 1 нче дәрес – сүзтезмәләр, 2 нче дәрес – иҗекләр, 3 нче дәрес – авазлар, 4 нче дәрес – а авазының галәмәте, 5 нче дәрес – авазларны өйрәнүне дәвам итү, 6 нчы дәрес – язу (рәсем дәресе) һ.б.). Мәсәлән, 15 нче дәрескә тукталып үтик.

Дәреснең темасы: *Урманның файдасы һәм матурлыгы дигән темага инша язу.*

*– Урман хакында булган нәрсәнең барын язабызмы?*

*– Юк, аның фәкать матурлыгы һәм файдасы хакында гына язабыз.*

*– Монда баш фикер нинди?*

*– Урман матурлыгы һәм аның киләчәге.*

*– Иншаны язганчы әүвәл нәрсә эшләргә кирәк?*

*– План төзергә кирәк.*

*– Язма эшебездә ничә мөһим өлеш булыр дип уйлыйсыз?*

*– Ике.*

*– Нindиләр?*

*– 1) урманның матурлыгы; 2) урманның файдасы.*

*– Хәзергә икенче өлеше белән эшләмичә, урманның матурлыгы хакында гына язарбыз. Урманда нәрсә матур, нәрсә яхшы? Моны кем белә?*

*– Укытучы балаларның урман матурлыгы хакында әйткән фикерләрен үзләре әйткән тәртиптә тактага язып куя, язу ошбу рәвештә булыр дип фараз итик: матур яфраклар, чәчәкләр, үләннәр, биек-биек агачлар, кошлар сайравы. Моның соңында фикерләрне бер тәртипкә китерү мәсьәләсен хәл кылу өчен, әйтелгән җирләр тикшерелер, ягъни кайсын алдан, кайсын арттан язу һәм ни өчен алай язу мәсьәләсе каралыр.*

*– Урман кай вакытта матур була?*

*– Җәй көнендә.*

*– Елның башка вакытларында урман нәрсә белән матур була? Урман нинди файда китерә?*

*– Урманның файдасы:*

*1) урманны ягарга истигъмаль булуы;*

*2) урманда җиләк һәм гөмбә җыю;*

*3) сәламәтлек өчен кирәкле булган саф һава;*

*4) урманда юешлекнең саклануы;*

*5) урманның матурлыгы:*

*а) җәй көнендә:*

*– матур яфраклар,*

*– чәчәкләр,*

*– үләннәр,*

*– кошлар сайрый.*

*ә) яз көнендә: яңа саф ачык яфраклар.*

*б) көз көнендә: яфракларның төрле төстә булулары.*

*в) кыш көнендә: агачлардагы бәснең кояшта ялтыравы.*

*Урманның файдасы:*

*1) каралты салырга китә;*

*2) ягарга китә;*

*3) әйберләр ясарга китә;*

*4) юешлек саклый;*

*5) сәламәтлек өчен файдалы булган саф һава;*

*6) гөмбә һәм җиләкләр* [Корбангалиев, 1920, б. 239].

Автор шәкертләрнең көче җитә алырдай эшләрне генә тәкъдим итәргә куша: «Көч җитә торган эш һәрвакыт файдалы була; көч җитми торган эш һәрвакыт кызыксыз һәм шуңа күрә файдасыз була» [шунда ук, б. 240]. Хезмәтне тикшереп чыкканнан соң, шуны әйтәсе килә: Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев – чын мәгънәсендә үз эшен белеп, яратып башкаручы методист, тәҗрибәле укытучы. Аның методик кулланмалары, мәктәп дәреслекләре бүген дә үрнәк булып торырлык.

1936 елларда М.Х. Корбангалиевнең «Мәгариф» журналында «Матур язу методикасы», «Укыту методикасы», «Грамматика укыту методикасы» исемле мәкаләләре дөнья күрә. Авторның «Матур язу методикасы» дигән мәкаләсендә язу техникасы һәм гигиенасы, гәүдә торышы, кулларның һәм иңбашларның, аякларның торышы, язганда бармакларның урыннары, ручканың дөрес тотылу-тотылмавын белү серләре, 11 төрле язуда хәзерлек күнегүләре башлангыч сыйныф укытучыларын күздә тотып язылган [Корбангалиев, 1936, 21].

М.Х. Корбангалиев «Укыту методикасы»нда әһәмиятле булган ике этапка туктала:

1. Укырга-язарга өйрәтү эшләренә хәзерлек этабы. Әлеге этапта уку дәресләрен укылганның эчтәлеген рәсемли торган картиналарны җентекләп тикшерү юлы белән, укылган нәрсә турында укытучының сорауларыннан әңгәмә юлы белән шигырьләрне күңелдән ятлау һәм сөйләү белән бәйләргә туры килә. Бу очракларның һәрберендә укыла торган нәрсәнең эчтәлеген сүзләрнең хәрефле сурәте белән бәйләргә кирәк.

2. Язуда әйтелешеннән аермасы булмаган кыска сүзләрне һәм фразаларны уку һәм язу, сүзләрнең хәреф-аваз составын акрынлап катлауландыра бару этабы:

– *язуда әйтелешеннән аерылмый торган яңа сүзләрне уку-язу дәресе;*

– *язуда әйтелешеннән аерылмый торган яңа сүзне язу-уку дәресе;*

– *язу дәресе;*

– *әлифба уку дәресе;*

– *дидактик материалдан файдалану юлы белән уку дәресе* [Корбангалиев, 1936, б. 26].

Дидактик материалдан файдалану юлы белән уку дәресләре сүз һәм фразаларның урыннарын алмаштырырга, кайбер сүз һәм фразаларны икенче сүз һәм фразалар белән бирергә, фразаларны яңа сүз кертү юлы белән җәелдерергә мөмкинлек бирә. Биредә шунысын да ассызыкларга кирәк: фразаларны үзгәртеп ясауның югарыда күрсәтелгән һәр алымы эшкә кирәкле булган төрлелек кертеп кенә калмый, укучыларның белемнәрен тикшерергә дә мөмкинлек бирә.

Галим, «Грамматика укыту методикасы» дигән күләмле мәкаләсендә ике иҗекле сүзләрне өйрәткәндә балаларга сүзләрнең иҗек составы принципларына тизрәк төшенергә ярдәм итә торган алымнарны күрсәтә:

1) иҗекләрне алмаштырып кую юлы белән бер мәгънәле сүзне икенче мәгънәле үзбаш сүзгә әйләндерү (*ята ~ тая, бата ~ таба* һ.б.);

2) бирелгән сүздән үзбаш мәгънәле яңа сүз итеп, аның бер кисәген аерып алу (*Төй-мә Мә төймә; Са-бир Бир Сабир* һ.б.);

3) тикшерелергә бирелгән сүзне кәгазь кисәгенә басма шрифт белән аерып, бу сүзне балалар белән бергә бөтен килеш уку;

4) укучылар белән бергә күреп зиһенгә алу өчен, һәрбер иҗекне аерып кую;

5) ахырдан кәгазь кисәген җәеп салу һәм балаларга сүзне бөтен килеш укып чыгарга кушу [Корбангалиев, 1936, б. 16].

Шулай итеп, беренчедән, әлеге алымнар ярдәмендә укытучы балаларны берничә тартык белән бергә җыелып килгән сүзләрне тиз итеп укырга өйрәтә ала, икенчедән, төрле кушымчалар ялгау аркасында сүзләрнең мәгънәләрендәге аерманы аңларга юнәлдерелгән сүзлек эшен бик җиңел үткәрә ала.

1920–1930 елларда татар теле рәсми рәвештә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелгәч, рус мәктәпләрендә, төрле уку йортларында, курс, түгәрәкләрдә татар телен өйрәнә башлыйлар. Бу елларда М.Х. Корбангалиев җитәкчелегендә (Р. Газизов, Х. Бәдигый, Г. Шәрәф, З. Бәдигуллин, М. Сафин, Ә. Бикбулатов һ.б.) программалар һәм дәреслекләр төзеп бастырыла [Сафиуллина, 2000, б. 25]: «Руслар өчен татар теле дәреслеге» (1924), «Грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» (1924), «Русларга татар телен өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» (1925), «Комплекс системасында ана теле укыту юллары» (1926) һ.б..

М.Х. Корбангалиевнең «Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен» (1938), «Татар теле дәреслеге. Грамматика һәм дөрес язу» (1945) дигән китаплары кат-кат бастырыла. Автор әлеге дәреслекләрне төзүдә текстлар сайлауга да зур игътибар бирә. Галимнең «Татар теле дәреслеге» (1938) беренче сыйныфларны күз уңында тотып язылган. Әлеге дәреслек мәктәп бусагасын атлап керүче сабыйларны кечкенә генә өзекләр аша тормыш, тирә-як белән таныштыра. Дәреслектә рәсемнәр, күренекле шәхесләрнең портретлары (Ленин, Стаханов, Паша Ангелина, Максим Горький һ.б.) урын алган, плакатлар һәм таблицалар («Бәйлек сүзләр», «Күрсәтү алмашлыкларының килеш белән төрләнеше», «Исемнәрнең берлек һәм күплек саны» һ.б.) урнаштырылган. Текстлар аңлап укырга-язарга өйрәтү, балаларны матур язуга күнектерү, җөмләләр төзү, аларның фикерләү сәләтләрен, сөйләм телен үстерүне күздә тотып сайлап алынган.

Текстларның эчтәлегенә карап, өч өлешкә бүләбез:

1) хайваннар дөньясы,

2) ел фасыллары,

3) сугышта дошманны җиңү.

«Сугышта дошманны җиңү» дигән циклга караган текстлар бер-берсе белән логик эзлеклелектә бирелгән:

*«Алмаз абый» (2 бирем, 15 бит);*

*«Без» (3 бирем, 15 бит);*

*«Диңгездә» (7 бирем, 16 бит);*

*«Кыйна дошманны» (6 бирем, 18 бит);*

*«Батыр бул» (7 бирем, 19 бит);*

*«Илеңне сакла» (8 бирем, 19 бит);*

*«Фашистларга үлем» (1 бирем, 23 бит*) [Корбангалиев, 1938, б. 23] һ.б.

Ике шигырьнең авторы күрсәтелгән, димәк, калган текстларны үзе уйлап чыгарган. Укучылар хайваннарны, кошларны фигыльләр белән бергә үреп өйрәнгәннәр: *Эт өрә. Бүре улый. Күгәрчен гөрли. Ат кешни. Сыер мөгри. Сандагач сайрый. Тавык кытаклый* [Корбангалиев, 1945, б. 3]

Дәреслектә сузык, тартык авазлар, хәрефләр, алфавит, иҗек, сүзләрне бер юлдан икенче юлга күчерү турында да мәгълүмат бар.

Автор иҗеккә билгеләмә бирә һәм, укучылар хәтерләрендә озаграк калдырсыннар өчен, рамкалар эченә ала [шунда ук, б. 17]:

| |
|---|
| Сүз кисәкләргә бүленә. Сүзнең мондый кисәкләре иҗек дип атала. Без сүзне әйткәндә ничә сулыш алсак, анда шулкадәр иҗек була. |

М.Х. Корбангалиевнең «Татар теле дәреслеге. Грамматика һәм дөрес язу» (1945) китабы бай мәгълүматлы: хикәя, сорау, өндәү җөмләләр, эндәш сүз, берничә ияле һәм хәбәрле, тиңдәш иярчен кисәкле җөмләләр, баш һәм иярчен җөмлә, туры сөйләм; исемнәрнең тартым белән төрләнеше, тартым кушымчалары белән төрләнгән исемнәрнең килеш белән төрләнеше, чагыштыру һәм арттыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар, боерык фигыль, рәвеш, бәйлекләр, теркәгечләр, кушма сүзләр, кыскартылган сүзләр һ.б. Китапта өч схема үрнәк итеп тәкъдим ителә. Бу дәреслектә галим текстларны шулай ук өч өлешкә бүлә:

1) Кызыл Армия,

2) күренекле әдипләр, шәхесләр,

3) файдалы киңәшләр.

Биредә текстларның кайдан, кемнән алынуы төгәл күрсәтелгән [шунда ук, б. 37].

Галимнең китаплары тагын шунысы белән үзенчәлекле: дәреслек ахырында татарча-русча терминнар сүзлеге урнаштырылган. Хикәя, шигырь, табышмак, җыр, мәкаль кебек әдәби материаллар да бар: *Ябага тайны хурлама, язга чыккач ат булыр; Яхшы белән юлдаш булсаң, эшең бетәр, Яман белән юлдаш булсаң, башың бетәр; Чебешне көз көне саныйлар* һ.б. Текстлар нигездә Г. Тукай, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Г. Гобәй, К. Нәҗми, М. Максуд, Һ. Такташ, Т. Гыйззәт һ.б. әсәрләреннән алынган. Бу өзекләргә карап, автор укучыларда әхлакый сыйфатлар булдыру, туган илне саклау, үз эшен белеп эшләүче яхшы белгечләр тәрбияләүне күздә тота.

М.Х. Корбангалиевнең татар теле дәреслекләрендә тел материалын ныгыту күнегүләре дә уңышлы эшләнгән: текстны укып чыгыгыз, мәгънәләренә карап, җөмләләрнең төрләрен билгеләгез; җөмләләрнең иярчен кисәкләрен төшереп калдырып, текстны күчереп языгыз; тиешле тыныш билгеләрен куеп, текстны күчереп языгыз;

«Яңа елны каршы алу», «Чаңгы ярышында», «Ёлка көннәре» дигән темаларның берсенә сочинение языгыз һ.б. [шунда ук, б. 10].

Гомумән алганда, М.Х. Корбангалиевнең татар теле дәреслекләре бик уйлап эшләнелгән: текстлар белән эшләү, сүзлек эше, грамматик материалны үзләштерү, сәнгатьле уку, грамоталы итеп язу күнекмәләрен булдыру, иҗади характердагы күнегүләр белән эшләү. Галимнең методик хезмәтләрен барлап, татар теле дәреслекләренә күзәтү ясап чыккач, шундый фикергә киләсең: ул оста укытучы да, методист та, балаларның холкын белгән сизгер психолог та, тәрбияче дә. Аны XX гасырның беренче яртысында үз халкына армый-талмый хезмәт иткән, күләмле методик хезмәтләр язган педагоглар арасында иң тәҗрибәлесе дип әйтергә тулы нигез бар.

### Әдәбият


*Вәлиева Ф.С.* М.Х. Корбангалиевнең татарларга һәм татар булмаганнарга татар теле укыту буенча методик системасы: пед. фән. канд. ... дис. Казан, 1951. 286 б.

*Ибраһимов Ф.И.* Белем әлифбадан башлана. Казан: Мәгариф, 1994. 256 б.

*Корбангалиев М.* Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты // Мәктәп. 1914. № 5–6. Б. 116–118.

*Корбангалиев М.Х.* Ана теле методикасы. Казан: Корылтай, 1920. 245 б.

*Корбангалиев М.* Укыту методикасы // Мәгариф. 1936. № 8. Б. 20–26.

*Корбангалиев М*. Матур язу методикасы // Мәгариф. 1936. № 8. Б. 26–31.

*Корбангалиев М.* Грамматика укыту методикасы // Мәгариф. 1936. № 9. Б. 16–20.

*Корбангалиев М.Х.* Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен, дүртенче кисәк. Казан: Татгосиздат., 1938. 68 б.

*Корбангалиев М.Х.* Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен, дүртенче кисәк. Казан: Татгосиздат., 1945. 30 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Галим һәм замана // Фән һәм тел. 2000. № 2. Б. 25–28.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Ханбиков Я.И.* История развития педагогической мысли татарского народа. Казань: КГПИ, 1975. 160 с.

*Шакурова М.М.* Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. 2010. № 3. С. 207–214.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

*Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И.* Педагогическая деятельность и педагогические взгляды Мухутдина Курбангалиева // История педагогики Татарстана. Казань: Изд-во КГПИ, 1998. 340 с.



***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 371.214.41

***Ф.Ш. Зарипов,***
***И.И. Вәлиев***

# ЛИНГВИСТИК ТӨРЛЕЛЕК ШАРТЛАРЫНДА МАТЕМАТИК БЕЛЕМ БИРҮ

В настоящее время теоретические аспекты преподования математики в условиях языкового многообразия стали актуальными направлениями научных исследований. Заинтересованность многих специалистов вопросами математического образования в полилингвальном контексте требует обращения к современным направлениям исследований в этой области и выявление новых траекторий.

В статье рассматриваются предпосылки развития современных направлений по исследованиям проблем преподования математики в условиях языкового многообразия. Авторами выделяются несколько направлений, а также определяется новое, актуальное для Республики Татарстан.

В целом работа посвящена выявлению проблемных аспектов обучения математики и информатики в условиях языкового многообразия.

**Ключевые слова:** многоязычное обучение, направления исследований, преподавание математики и информатики, образование.

Currently, the theoretical aspects of teaching mathematics in the context of linguistic diversity have become relevant areas of scientific research. The interest of many specialists in the issues of mathematics education in a multilingual context requires an appeal to modern directions of research in this area and the identification of new trajectories.

The article examines the prerequisites for the development of modern trends in researching the problems of teaching mathematics in the context of linguistic diversity. The authors identify several directions, and also define new directions that are relevant for the Republic of Tatarstan.

In general, the work is devoted to identifying problematic aspects of teaching mathematics and computer science in the context of linguistic diversity.

**Keywords:** multilingual education, research areas, teaching mathematics, teaching computer science, education.

Дөньядагы телләр төрлелеге заманча белем бирүнең характерлы үзенчәлегенә әверелде. Әлеге фактор мәгариф өлкәсенә ничек йогынты ясый соң дигән сорау туа. Математика һәм информатика кебек фәннәрне туган телдә яки күптелле контекстта өйрәткәндә нинди кыенлыклар туа? Әгәр күптелле укыту хәзерге заман белем бирү даирәсендә өстенлек итә торган юнәлешләрнең берсенә әверелгән икән, әлеге фәннәрне укытканда, укытучылар әзерләгәндә, уку программаларын булдырганда нинди нәтиҗәләргә китерер соң?

Соңгы елларда күп телле мәктәп яки югары уку йортларында математик белем бирүгә йөз тоткан тикшеренүләр өлкәсе формалашып килә. Ул билингваль белем бирү контекстында барлыкка килә торган

ситуацияләрнең киң даирәсен колачлый. Хәзер исә билингваль белем бирү өлкәсенә багышланган берничә тенденцияне билгеләргә мөмкин. Моңа берничә мөһим вакыйга этәргеч булды.

Беренчедән, математик белем бирү буенча Халыкара комиссия (ICMI) фәнни тикшеренүләрен үз эченә керткән чаралар уздырылды. Әлеге тема буенча төрле конференцияләр эшчәнлеге дә активлаша. Мисал өчен, 2016 елда Гамбургта «Күпмәдәни һәм күптелле контекстта математик белем бирү» темасына багышланган Халыкара конгресс (ICME) узды.

Төрле илләрнең мәгариф өлкәсе вәкилләре үз мәктәпләренең үсә баруын, үзгәрүен аңлап эш итә. Шуңа күрә, алар махсус математик белем бирү өлкәсе сәясәтен булдыру, практика һәм укыту программаларын эшләү мәсьәләсе буенча галимнәргә һәм тикшеренүчеләргә мөрәҗәгать итәләр. Бу исә тикшеренүләр өлкәсенең тагын да киңәюенә китерә.

Россиядә математиканы билингваль нигездә укыту мәсьәләләренә 2000 еллар башында зур игътибар бирелә башлый. Бу вакытта дәүләтебезнең кайбер субъектлары мәгарифтә рус һәм башка милли телләр кулланылышын камилләштерү теләген белдереп чыкты. Аңа кадәр 1990 елларда Казан дәүләт педагогика институтының математика факультетында милли мәктәпләр өчен татар телендә математика һәм информатика укытучылары әзерләү төркемнәре булдырылды [Салехова, 2015].

Математиканы рус һәм башка милли телләр кулланылышына нигезләнеп укыту мәсьәләләре Л.Т. Зембатова хезмәтендә яктыртыла. Ул башлангыч сыйныф укучыларына математиканы билингваль нигездә (математик белем бирүнең сыйфатын күтәрү факторы буларак) өйрәтүнең максатчанлыгын дәлилләгән һәм нигезләгән. Автор үз хезмәтендә укучының билингваль математик компетенциясен дидактик категория буларак билгеләргә мөмкин, дигән нәтиҗәгә килә. Әлеге категория үз туган теле (осетин) һәм рус телләрендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган мәдәниятара һәм махсус математик белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр җыелмасын үз эченә ала [Зембатова, 2013].

Н.И. Спиридонова үзенең хезмәтендә мәктәп укучыларында билингваль белем бирү нигезендә математик төшенчәләрнең формалашу үзенчәлекләрен ачыклаган. Автор раславынча, рус һәм башка милли телләр кулланылышы шартларында математик төшенчәләрне үзләштерү махсус эшләнгән методика нигезендә гамәлгә ашырылырга, һәм әлеге методика укучылар белемнәрен үзләштерүнең төрле психологик-дидактик концепцияләре һәм билингваль белем бирү концепцияләре спецификасын исәпкә алырга тиеш [Спиридонова, 2017].

Икенчедән, хәзерге вакытта төрле ил галимнәре математик белем бирүдә телнең күптөрлелегенә бәйле булган мәсьәләләр өстендә эшли. Әйтик, 2019 елда Дортмунд Техник университетында (Германия) узган Европа тикшеренүләренең соңгы эшлекле конференциясендә

Германия, Дания, Норвегия, Швеция, Финляндия, Испания (Каталония), Нидерланд, Канада, АКШ, Колумбия, Россия (Татарстан) һәм Һиндстан вәкилләре катнашты.

Өченчедән, тикшеренү юнәлешләре, стильләр төрлелеге арта. Бу, үз чиратында, теоретик перспективалар барлыкка килү өчен алшартлар тудыра.

Хәзерге вакытка кадәр әлеге өлкәдә төп өч юнәлешне аерып күрсәтергә мөмкин иде [Barwell, R., 2017]:

1. *Когнитив тикшеренүләр*. Бу очракта шәхси математик фикерләү сәләте укучының белем ала торган телләрендә, аларның ике теллелек һәм күптеллелек дәрәҗәсендә карала.

2. *Дискурсив тикшеренүләр*. Әлеге очракта күмәк математик фикерләүгә һәм күп телле сыйныфларда үзара бәйләнешкә игътибар ителә.

3. *Иҗтимагый-сәяси тикшеренүләр*. Бу очракта математиканы өйрәтүгә, укыту һәм нәтиҗәләрне бәяләүгә карата тигезсезлек, тел һәм хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрне, мәгариф өлкәсендәге сәясәтне дә күз алдында тоту карала.

Бу юнәлешләр хронологик тәртиптә саналса да, алар барысы бер үк вакытта тикшеренү эшенең актив өлкәләре булып кала бирә. Шулай да, соңгы вакытта без тикшеренү методларында инновацияләр һәм тел төрлелеге үсешен күзәтәбез. Мәсәлән, кайбер галимнәр лингвистик антропология, этнография, деколонизация методологиясе кебек махсус темаларны тикшерә башлады.

Ниһаять, бу өлкәдә телнең гомуми аңлатмасы катлаулана бара, лингвистик теорияләр һәм методлар кичәгегә караганда күпкә җентеклерәк кулланыла башлый. Чагыштырма тел белеме, интерактив дискурс анализы, системалы лингвистика, Бахтинның транслингваль алымы кебек теорияләрне актив куллану белән бергә, хәзерге заман публикацияләрендә тел проблемалаштырылуга, методологик һәм теоретик нигезләүгә таяна башлый.

Вакланма, югары математиканың кайбер темалары, сызыкча функцияләр, ихтималлык теориясе кебек математиканың конкрет аспектларын өйрәнүгә бәйле тел төрлелегенә йөз тоткан темалар да яктыртыла.

Математиканы күптелле контекстта өйрәнә һәм укыта торган студентлар һәм укучылар саны арту белән, бу фәнне берничә тел кулланып нәтиҗәле өйрәнүне башлау турындагы мөһим фәнни-гамәли мәсьәләләр алгы планга чыга. Бу юнәлештәге тикшеренүләр галимнәр өчен дә, укытучылар өчен дә актуаль, чөнки алар белем бирү стратегияләрен трансформацияләү, үзгәрешләргә җавап бирү һ.б. шундый сорауларга җавап эзли башлый.

Шулай итеп, күптелле контекстта математик белем бирү проблемаларын тикшерү өлкәсенең төп өч юнәлешен аерып чыгарырга мөмкин. Әмма, безнең фикеребезчә, аларны алга таба үстерүнең төп максаты – күп телле белем бирү шартларында математика укы-

туның фәнни-нигезләнгән методларында җитешсезлекләрне бетерү. Шуны истә тотып, булачак үсеш этаплары кысасында математика укытучыларын билингваль мохиттә эшләүгә әзерләү механизмнарын булдыру белән бәйле перспективаларны системалы рәвештә исәпкә алырга кирәк. Бу идеяләр математик белем бирү проблемаларын күптелле контекстта өйрәнүдә булган тенденцияләрне яңа юнәлеш белән тулыландырырга һәм аны җентекләп тасвирларга мөмкинлек бирә, яңа тикшеренү юнәлешләрен үстерү өчен перспективалар ача һәм математика укытуда тел төрлелегенә тирәнрәк анализ ясауны күздә тота.

Гамәлдәге тикшеренү юнәлешләрен анализлауга йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: күптелле укыту төрле тел контекстлары күзлегеннән җенлекләп анализланса да, укыту методлары, бурычларны проектлау алымнары, өйрәнү һәм укыту механизмнарын эшләү һәм бәяләү принциплары турында фәнни нигезләнгән белемнәрдә җитешсезлекләр бар. Әлеге кимчелекләрне төзәтеп җибәрсәк, математика фәнен генә түгел, ә аңа якын информатика һәм физика фәннәрен тирәнрәк аңлауга ирешү өчен бер телле һәм күптелле укучыларның тел чараларын активлаштырып һәм үстереп булыр иде.

Югарыда аталган җитешсезлекләрне актив фәнни алмашыну ярдәмендә җиңеп чыгарга да мөмкин. Ул төрле тел контекстлары галимнәре арасында гына түгел, ә укытучылар һәм тикшеренүчеләр арасында да, шул исәптән теоретик эшләнмәләрне, идеяләрне тарату юлы белән дә башкарыла ала.

Моннан чыгып сораулар туа: әгәр туган телдә белем алу хокукы кайтарыла икән, математика, информатика, физика укытучыларын әзерләүдә бу ничек чагылырга тиеш? Булачак укытучыларның күптелле контекстта укытуга карашлары нинди? Алар күптелле контекстта укыту турында нәрсәләр белергә тиеш?

Бу сораулар тел хокукларын таный торган белем бирү тикшеренүләрендә әлегә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. Шулай ук, күптелле контекстларда «Профессиональ үсешне ничек проектлый алабыз?», «Математика, физика һәм информатика буенча мәктәп укытучыларын әзерләү буенча университет курсларын ничек эшләргә?» кебек сорауларга канәгатьләнерлек җавап алган юк. Болар барысы да бездә төп сорауны уята: әгәр белем бирү процессында катнашучыларга туган телләрендә белем алу хокукы бирелсә, тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өчен аның нәтиҗәсе нинди булыр?

Без математика укытучыларын теоретик яктан үстерү зарурлыгын күрәбез. Ул тел төрлелеге шартларында математиканы укыту һәм укытуга юнәлдереләчәк.

Бу укытучыларның һөнәри-педагогик белемнәре эчтәлегенең тел аспектларын яхшырак аңларга да ярдәм итәчәк. Әлбәттә, укытучылар әзерләү процессларын тирәнтен төшенү белән беррәттән, аларның фикер-карашларын һәм кыйммәтләрен дә өйрәнергә була. Бу укыту практикасын үзгәртергә омтылган вакытта бигрәк тә актуаль.

Күп телләрдә һәм төрле контекстларда тикшеренүләр үткәрү, һичшиксез, зур казаныш булып тора. Әмма мондый авторлар халыкара фәнни журналларда үзләренең хезмәтләрен бастырганда кыенлыклар белән очраша. Инглиз телле булмаган илләрдә үткәрелә торган тикшеренүләр өчен кирәкле мәгълүмат яки студентлар хезмәтләренең транскриптларын тәрҗемә итү бик кыен була. Моннан тыш, ике (яки аннан да күбрәк) телдә мәгълүмат бирү күп урын сорый. Халыкара инглиз телле журналларда күпчелек мәкаләләр Европа контекстларыннан мисаллар булып тора. Барлык җирле яки аерым төбәк телләре дә (мәсәлән, татар теле) халыкара контекстта кулланылмаска да мөмкин. Бу очракта тикшеренү эшләре алып барганда җитди генә проблемалар барлыкка килә ала.

Гамәлдәге тикшеренүләр һәм методологик алымнарга (когнитив, дискурсив, социаль-сәяси тикшеренүләр) нигезләнеп, аларның исемлеген киңәйтергә, тагын берсен – дүртенчесен өстәргә тәкъдим ителә:

4. *Укыту методикасы, биремнәрне проектлау, математика һәм информатика фәннәрен укыту принциплары буенча фәнни белемнәрне тулыландыру максатыннан методик һәм проект тикшеренүләре*. Әлеге юнәлеш укытучыларның квалификациясен күтәрүне, укыту алымнарын һәм конструкцияләрен тикшереп карау максатыннан контроль эшләр вакытында методик эшләнмәләрнең нәтиҗәлелеген сынау буенча тикшеренүләрне һәм билингваль белем бирүнең дисциплинаара теориясен дә күздә тота.

Ачыкланган юнәлеш беренче өч траектория кысаларында булдырылган фәнни эшләнмәләргә һәм теориягә таянып, математиканы укыту механизмнарын эшләүне, математика укытуны, уку программаларын өйрәнүне үз эченә алырга тиеш. Тикшеренүләрнең әлеге юнәлеше Татарстан Республикасы өчен актуаль булып тора.

Татарча-русча математика укытырга сәләтле укытучыларны әзерләү проблемалары безнең алдагы мәкаләдә [Зарипов Ф.Ш, 2018] китерелгән иде. Соңгы ике елда аларны чишү юнәлешендә кайбер чаралар күрелде, чөнки Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча Казан федераль университетында (КФУ) 2018 елда Татарстан Республикасындагы полилингваль мәктәпләр өчен математика укытучылары әзерләү башланды. Бүгенге көндә 1 һәм 2 курсларда 150 студент белем ала. Алар барысы да математика, рус теле һәм җәмгыять белеме буенча Россия Федерациясе Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 1 курска кабул ителде. Студентларның лингвистик портреты бик төрле, ләкин күбесе татар-рус билингвлары булып тора. Өйрәнү һәм укыту механизмнарына килгәндә, быел безнең тарафтан «Геометриядә сызыкча операторлар теориясен куллану», «Сызыкча операторлар һәм икенче тәртиптәге өслекләр», «Сурәтләр методы» кебек темалар буенча индивидуаль эшләр һәм укыту өчен методик ярдәмлекләр дөнья күрде. Әлеге материаллар татар телендә чыгачак «Аналитик геометрия һәм сызыкча алгебра» китабына кертеләчәк.

Билингваль татар-рус мохитендә математика һәм информатика укытучылары әзерләү традицияләрен дәвам итеп, киләсе уку елыннан КФУда полилингваль мохиттә эшли ала торган математика һәм инглиз теле укытучылары әзерләү башланачак.

Билингваль белем бирү төркемнәрендә эшләүче укытучылар алдында методик характердагы бик күп сораулар һәм бурычлар тора. Бу сорауларга җаваплар математик белем бирү өлкәсендә дөньякүләм тикшеренүләрнең яңа юнәлешендә, гамәлдәге фундаменталь юнәлешләрне саклап калу юлы белән табылырга мөмкин.

**Әдәбият**

*Салехова Л.Л, Зарипов Ф.Ш.* Математическое и дидактическое моделирование как основа подготовки учителей двойного профиля (математика и информатика). Изд-во Казан. ун-та, 2012. 47 с. Электронный вариант http://libweb. ksu. ru/ebooks/publicat/05_A5m-000001.pdf

*Зембатова Л.Т.* Билингвальное обучение как фактор повышения качества математического образования в национальной школе // Мир науки, культуры, образования. 2013. № 6 (43). С. 86–88.

*Спиридонова Н.И.* Особенности формирования у школьников математических понятий на основе билингвального обучения // Самарский научный вестник. 2017. № 1 (18). С. 219–225.

*Barwell, R. Moschkovich, J., & Setati Phakeng, M.* Language diversity and mathematics: second language, bilingual, and multilingual learners. Compendium for Research in Mathematics Education. 2017; 7: 583–606.

*Зарипов Ф.Ш., Сафина Р.И.* Математика фәнен татар телендә укыту һәм телне саклау // Фәнни Татарстан. 2018 . № 2. Б. 134–140.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Зарипов Фәрхәт Шәүкәт улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының педагогик белем бирү бүлеге мөдире*

***Вәлиев Ильмир Ирек улы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты аспиранты*

УДК 7,071,1

*Л.Н. Донина*

# ҺӘРВАКЫТ САФТА
## *(В.А. Попов иҗаты турында)*

Статья посвящена творчеству живописца, графика, каллиграфа Владимира Александровича Попова, заслуженного деятеля искусств ТАССР, народного художника ТАССР, заслуженного художника России, лауреата Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая (2014) и Фаизхановской премии Совета муфтиев России в области науки, образования и культуры (2014). Премии вручены за вклад в возрождение традиций мусульманской каллиграфии, за укрепление международных связей средствами изобразительного искусства и продвижение исламских ценностей в общемировой культуре. Будучи приверженным сторонником реалистической школы живописи, художник в семьдесят лет постигает основы восточной каллиграфии и становится уникальным представителем арабографического направления современного искусства Татарстана и первым русским художником-каллиграфом, признанным исламским миром.

**Ключевые слова:** живопись, графика, каллиграфия, арабографическая композиция, реалистическая школа.

The article is dedicated to the work of Vladimir Alexandrovich Popov. Painter, graphic artist, calligrapher, Honored Art Worker of TASSR, People’s Artist of TASSR, Honored Artist of Russia, laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan named after Gabdullah Tukay and the Faizhan Prize of the Council of Muftis of Russia in the field of science, education and culture. Prizes were awarded for his contribution to the revival of the traditions of Muslim calligraphy, for the strengthening of international relations by means of fine art and the promotion of Islamic values in the global culture. A loyal supporter of a realistic school of painting, the artist at the age of seventy perceives the basics of oriental calligraphy and becomes a unique representative of the Arabographic direction of modern art in Tatarstan and is the first Russian calligrapher recognized by the Islamic world.

**Keywords:** painting, graphics, calligraphy, arabographic composition, realistic school.

Владимир Александрович Попов. Рәссам. График. Каллиграф. Татарстанда һәм Россиядә киң билгеле сәнгатькяр. Ватаныбыз аның сынлы сәнгатьне үстерүдәге казанышларын югары бәяләде, ул ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1975), ТАССРның халык рәссамы (1986) дигән мактаулы исемнәргә лаек булды, ә инде яңа заманда мөселман каллиграфиясе традицияләрен торгызуга керткән өлеше өчен аңа Россиянең атказанган рәссамы (2003) исеме бирелде. В.А. Попов – Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (2014) һәм Фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә Россия Мөфтиләр шурасының Фәезханов премиясе лауреаты (2014). Бу бүләкләр аңа сынлы сәнгать чаралары белән халыкара элемтәләрне ныгытуга һәм гомумдөнья мәдәниятендә ислам кыйммәтләрен күтәрү-

гә керткән өлеше өчен тапшырылды. Сынлы сәнгатьтә реалистик мәктәп тарафдары буларак, рәссам җитмеш яшендә көнчыгыш каллиграфиясе нигезләрен үзләштерә һәм хәзерге заман Татарстан сәнгатендә гарәп-каллиграфия юнәлешенең уникаль вәкиленә әверелә. Ислам дөньясы аны беренче рус рәссам-каллиграфы буларак таный.

В.А. Попов 1924 елның 24 июнендә Украина Совет Социалистик Республикасының Мариуполь шәһәрендә кадровый хәрби гаиләсендә туа. Унҗиде яшендә үзе теләп сугышка китә. Коммунистлар партиясе сафларына кабул ителә, ике Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм сугышчан медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан соң ике ел Германиянең оккупация гаскәрләрендә хезмәт итә. Рәссам булу хыялы белән ул сугыш юллары буйлап меңнәрчә чакрымнар үтә: хәрби рәссамнарның күчмә күргәзмәләрендә катнаша, ә сугыштан соң Германиядә югары комсоставның армия госпиталендә аның беренче шәхси күргәзмәләре уза. 1947 елда ул туган ягына – бу вакытка Башкортстан белән Татарстан чигендә урнашкан Туймазы авылына күченеп яши башлаган әти-әнисе янына әйләнеп кайта. Тиздән язмыш җепләре аны Казан белән бәйли.

Владимир Попов Казан сәнгать училищесының сәнгать-педагогика бүлеген (1947–1951) тәмамлый. Аның укытучылары – Василий Кириллович Тимофеев (Н.И. Фешинның укучысы), Николай Михайлович Сокольский, Виктор Степанович Подгурский, Виктор Иванович Куделькин, Семен Аронович Ротницкий, Харис Габдрахман улы Якупов. Осталык серләре белән уртаклашкан өчен, ул аларның һәркайсын зур хөрмәт белән искә ала.

1951 елның чыгарылыш дәүләт имтиханы училищеда ачык итеп уздырыла: күренекле рәссамнар, укучы яшьләр бирегә җыела. Дәүләт квалификация комиссиясе рәисе итеп РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе П.Т. Сперанский билгеләнә. Бу елны әлеге иң борынгы училищеларның берсен утыз егет һәм кыз тәмамлый. В. Попов, Б. Кожевников, А. Холмогоров, С. Кульбака, А. Визель, И. Язынин кызыл диплом алалар. «Красная Татария» газетасы корреспонденты үзенең мәкаләсендә Владимир Поповның диплом эшен яклау барышында дулкынланып сөйләгән чыгышын сүзгә-сүз диярлек өземтә итеп китерә [Вылегжанина, 1951]. Егетнең диплом эше тынычлыкны ныгытуга юнәлтелгән иҗади хезмәткә багышланган була. Күпчелек курсташларыннан аермалы буларак, гомуми белем бирү мәктәбе белән һөнәри училище арасында тагын бер мәктәп – сугыш мәктәбен узган рәссамның иҗатында тынычлык саклау идеяләре, һичшиксез, һәрвакыт өстенлек итәчәк. Ләкин ул чагында аның илле елдан соң каллиграф – иҗатын бөтен дөньяда тынычлык идеяләренә хезмәт итүгә багышлаган каллиграф – рус каллиграфы буларак танылачагын әле беркем дә белми... Дөньяга караш һәм дөньяның бердәмлеген, универсальлекне аңлауга юнәлтелгән мәдәни күрсәтмәләр рәссамга ихлас күңелдән бөтен кешелек дөньясына Көнчыгыш һәм Көнбатышны, реалистик сәнгатьне һәм гарәп каллиграфиясен, рус һәм татар

мәдәниятләрен берләштерүгә чакырып мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Ә рус реалистик мәктәбе вәкиле Владимир Попов иҗатын Төркия, Марокко, Яңа Зеландия, Кувейтның танылган каллиграфлары сәнгатен берләштергән «Каллиграфия тынычлык сагында» күргәзмә проекты глобальләшү чорында мәдәниятләрнең милләтара һәм динара хезмәттәшлеген чагылдыра. Бу уникаль күренешкә рәссамны илле ел вакыт аралыгын колачлаган озын юл китерә, аның белән танышмыйча «Поповның каллиграфия сәнгате феноменын» аңлау мөмкин түгел.

Казан сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, Владимир Попов башкаланың сәнгать тормышында актив катнаша башлый. 1955 елда партия өлкә комитеты кушуы буенча ул Алтайга китә, анда комсомол юлламалары буенча беренче тимер юл составы белән Мәскәүдән килгән чирәм җирләрне эшкәртүчеләр белән айдан артык бергә яши. Ирекле Кулунда даласының кеше тарафыннан ни рәвешле буйсындырылуы турында табигый материал җыя. «Алтай. Чирәм җирләр күтәрелде!» картинасы РСФСР рәссамнарының Бөтенроссия күргәзмәсенә [Выставка, 1955, с. 31, 102] кабул итеп алына. Ике елдан соң ул 1957 елның июнендә Мәскәүдә Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы кысаларында Сәнгать академиясе залларында уздырылган Татарстан АССР рәссамнарының сынлы сәнгать күргәзмәсендә сюжетлы-тематик картиналар язу остасы буларак катнаша. Анда җиде йөздән артык иң яхшы һөнәри сәнгать һәм халык иҗаты әсәрләре куела [Выставка, 1957, с. 29–30]. Чирәм җирләргә экспедиция материаллары буенча иҗат ителгән «Казакъстан язы» картинасы СССР Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы П.П. Соколов-Скаль мәкаләсендә югары бәя ала: «В. Попов картинасы күргәзмәдә, мөгаен, иң көчлесе булгандыр. Ул динамик рәвештә зур осталык белән язылган. Тамашачы бу әсәргә ышана» [Соколов-Скаля, 1957].

1960 еллар башында яшь рәссам язмыш кушуы буенча СССР Сәнгать академиясе президенты А.М. Герасимов инициативасы белән ачылган «Челюскинская» иҗат йортында (Мәскәү янында) стажировка үтә. Ул Советлар Союзы территориясендә график сәнгатьне үстерүдә иң әһәмиятле мәдәни үзәкләрнең берсе булып санала, анда тәҗрибә уртаклашу, танылган осталар кул астында эшләү максаты белән илнең төрле шәһәрләреннән рәссамнар килә торган була. Билгеле булганча, нәкыш һәм, барыннан да элек, тематик картина (аның чишмә башында рус мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре тора) һәрвакыт Татарстан сынлы сәнгатенең көчле ягын тәшкил итә. Ә менә станок графикасы сугыштан соңгы елларда нәкыштән шактый калыша. Сәнгатьнең әлеге төренә төшенү өчен, танылган рәссамга әйләнә-тирә чынбарлыкка график күзе белән яңадан карарга өйрәнергә туры килә. Иҗат йорты остаханәләрендә ул линогравюра, офорт, ксилография техникларын үзләштерә. Әсәрләр индустриаль пейзаж жанрында ике серия тәшкил итә («Шәһәрләр үсә», «Иске һәм яңа»). Һәм шаккаткыч хәл була! «Трассалар» һәм «Яңа районга. Черемушки» линогравюралары Бөтенсоюз сәнгать күргәзмәсенә алына

[Всесоюзная, 1961, с. 83, 365], конкурс аша «Совет графикасы һәм скульптурасы» халыкара күргәзмәсенә (Пхеньян, 1963) үтә, «Художник» һәм «Юность» журналларында басылып чыга.

График рәссам Владимир Попов белән Казан тамашачысы 1961 елда ТАССРның Сынлы сәнгать музеенда узган һәм Казанның сәнгать тормышында күренекле вакыйгага әверелгән рәссамның беренче шәхси күргәзмәсендә таныша алды [Выставка, 1961]. Газеталарда: «Үткән ел гына график Владимир Попов турында беркем дә хәбәрдар түгел иде. Чөнки ул юк иде. Рәссам Владимир Попов кына бар иде. Һәм кинәт шундый гравюралар!»; «Попов-рәссам һәм Попов-график бер-берсен үзара баета, тулыландыра: рәсем сәнгатенә мәхәббәт әсәрләрне тагын да мәгънәлерәк, көчлерәк итәргә омтылыш тудыра, ә графика теленең кыска һәм катгыйлыгы аны картиналарының композицион чишелешенә кырысрак якын килергә мәҗбүр итә» [Галеев, 1961]. Эстампка багышланган беренче республика күргәзмәсендә рәссам егерме яңа линогравюра тәкъдим итә [Первая, 1963, с. 5, 13, 14], шуларның дүртесе Мәскәүгә эстамп буенча икенче бөтенсоюз күргәзмәсенә сайлап алына [Вторая, 1963, с. 29, 75].

Бу елларда сәнгатьтә тамырдан борылыш күзәтелә: станок графикасына мөнәсәбәт үзгәрә. Һәм бу очраклы хәл булмый. 1961 елның октябрендә Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXII съезды була. Трибунадан Н.С. Хрущевның түбәндәге сүзләре яңгырый: «Яшьләр алдында безнең җир асты байлыкларын чыгару, фабрикалар, совхозлар, заводлар, шәһәрләр төзү бурычы тора, Әмма җир асты байлыклары Мәскәү, Ленинград шәһәрләре астында түгел, ә тайгаларда, тауларда, чүлләрдә ята...». Комсомоллар «коммунизм төзелешләренә» китә, ә рәссамнар алдына мөһим агитация бурычлары куела. Графиканың публицистик характеры, аның көн вакыйгалары белән тыгыз бәйләнеше, бу эшне белгән осталарның киң диапазоны совет сәнгате үсешенең беренче дәверләрендә үк билгеле була һәм сугыш чорында аеруча актуальләшә. Һәм менә тагын Владимир Попов кебек рәссамнар заманы килә: алар һәрвакыт иң мөһим вакыйгалар шаулаган җиргә, иҗатларына ихтыяҗ аеруча зур булган урынга омтыла.

Татарстанның нефть районнары ун ел дәвамында рәссам иҗаты өчен бай образлар һәм сюжетлар чыганагы булып тора [Попов, 1961]. Аның күз алдында Бөгелмә, Алабуга, Минзәлә, Зәй, Норлат кебек иске шәһәрләр үсеш-үзгәреш кичерә; өр-яңа шәһәрләр калкып чыга: Әлмәт, Лениногорск, Түбән Кама, Азнакай, Баулы; бөек нефть артериясе – «Дружба» трансевропа нефть үткәргече төзелә. Бу чорда Владимир Александрович индустриаль пейзажларны, символик-аллегорик характердагы композицияләрне, портретлар галереясын үз эченә алган «Татарстан нефте» линогравюраларының зур сериясен иҗат итә: ул хезмәт һәм тормыш сөючән кешеләргә карап соклануын яшерми. Нефть ятмаларын эшкәртү, скважиналар бораулау, гигант вышкаларны монтажлау, юл салу темалары рәссам картиналарында тантаналы, героик-романтик яңгыраш ала. Аның һәрбер әсәренең сәнгати-образлы

чишелеше – уникаль. Кара һәм ак төсләр контрасты, күләмнәр нисбәте, силуэтлар һәм сызыклар ритмы, гомуми композицион чишелеш – бөтенесе тәэсирле. «Баһадирлар симфониясе» линогравюрасында чылбырлы катокларга утыртылган гаять зур нефть вышкасы сурәтләнгән. Ул корыч трослар белән нык итеп тарттырылган тракторлар артыннан теләр-теләмәс кенә бара. Моторларның үкерүе аркасында бернәрсә ишетелми, әмма кечкенә генә кеше гәүдәсе әйтерсең техникага дирижерлык итә. Иҗатчы кеше тимер алыпның сукырларча каршылык күрсәтүен йөгәнли... Мәскәүдә Үзәк күргәзмәләр залында ватаныбыз сәнгати мәдәнияте тарихына кереп калган РСФСР автономияле республикалары рәссамнары әсәрләренең бөтенроссия күргәзмәсендә [Выставка, 1971, с. 69; Изобразительное, 1973, с. 302] В.А. Поповның бу картинасы үзенең лаеклы урынын ала.

Производство темасы совет сәнгатен үстерүнең магистраль линиясе булып тора. «Зур Идел» зона сәнгать күргәзмәләренең тематик эчтәлеге – моның ачык дәлиле. Аларның лейтмотивын чынбарлыкны образлы чагылдыру, совет кешеләренең көндәлек иҗади хезмәтен һәм тормышын күрсәтү тәшкил итә. Экспозицияләр, кагыйдә буларак, Идел буендагы Калининнан алып Әстерханга кадәр җәелгән автономияле республикалардан һәм өлкәләрдән килгән меңнән артык кызыклы әсәрне үз эченә ала. Алар нигезендә күчмә күргәзмәләр оештырыла. 1964 елдан В.А. Попов «Зур Идел» күргәзмзсендә һәрвакыт хезмәттәшләрен һәм тамашачыларны әледән-әле хезмәт темасының көтелмәгәнчә чишелеше белән шаккатыра.

1970 еллар башыннан поход шартларында да эшләргә мөмкинлек биргән акварельне рәссам үзенең төп техника төре итә. Бу вакытта СССР рәссамнар берлеге линиясе буенча бөтен илдән акварельчеләр төркемнәре формалаша. Алар иҗади командировкаларга чыгалар. Традицион культура үзәкләрендә һәм яңа индустриаль шәһәрләрдә рәссамнар бай табигый материал җыялар. В.А. Попов шундый төркемнәрнең берсе составында Урта Азия республикаларында – Таҗикстан, Үзбәкстан, Кыргызстанда... ике ай эшли [По Таджикистану, 1972; Мелихова, 1972]. Рәссам тупламасында үзенчәлекле этюдлар саклангән. Аларда Вахш елгасындагы Нурек ГЭСының гигант плотинасы төзелеше, Шураб шахталары, кырыс Памир таулары, Исфарадагы тын кышлак урамнарының уйчан гүзәллеге... сурәтләнгән. Кайбер акварельләр Россия Федерациясе рәссамнарының «Туган ил буйлап» дип исемләнгән Бөтенсоюз күргәзмәсендә (Мәскәү, 1972) тәкъдим ителгән.

Шул ук елларда СССР төзелүнең 50 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек чаралары кысаларында махсус иҗади төркемнәр оештырыла, алар алдына Республиканың IX бишьеллык төзелешләрендә сәнгать елъязмасын булдыру бурычы куела. Әлеге бурычны хәл итү өчен, Татарстанның иң яхшы иҗат көчләре җәлеп ителә. Нәкъ менә шул вакытта Кама буендагы гаять зур, бөтен халык катнашындагы, үзенең тәмамлану сроклары ягыннан һәм техник җиһазланыш дәрәҗәсе буенча уникаль булган автогигант төзелеше бик күпләрне үзенә тартып китерә.

Владимир Попов КамАЗ темасына иң беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә: «Завод минем күз алдында туды. Меңләгән машиналарның иксез-чиксез хәрәкәтендә ниндидер бер сихри көч бар, алар өзлексез хәрәкәттәге кан әйләнеше системасын хәтерләтә иде. Мин картиналарымның журналистлар репортажына охшавын теләдем...». Әлеге үзгә форманы рәссам натурадан язылган ике зур сериядә гамәлгә ашыра: «КамАЗ төзелә» һәм «Яр Чаллы төзелә». Аларда рәссамның кискен тәэсирләрне дә, якты хис-кичерешләрне дә, тормыш тулы детальләрне дә бирергә сәләтле монументаль гомумиләштерүләргә омтылышы чагыла. «КамАЗ» темасы астында берләшкән акварельләр Татарстан шәһәрләрендә узган «КамАЗга багышлана» республика күргәзмәсе экспозициясендә [Художники, 1974, с. 3; Валеева, 1973], аннары Үзәк күргәзмәләр залында ачылган «Совет Россиясе» Бишенче республика күргәзмәсендә (Мәскәү, 1975) алдынгы урыннарның берсен алалар.

1974 елда В.А. Поповның икенче шәхси сәнгать күргәзмәсе аеруча истә калырлык була: бөтен Советлар Союзы буйлап үзенә күрә күргәзмә-сәяхәт оештырыла [Файнберг, 1974; В. Попов, 1974]. Экспозициядә төрле техникаларда (майлы буяу, линогравюра, офорт, ксилография, шелкография, акватинта, акварель, карандаш, гуашь, фломастер, күмер һ.б.) иҗат ителгән әсәрләр тәкъдим ителә. Рәссам, ялгышмыйча, нәкъ менә вакыт чакыруына җавап бирә алырдай материал сайлый, әсәр идеясен гәүдәләндерү өчен, аның тәэсирле мөмкинлекләреннән ахыргача файдалана. Әйтик, 1960 елларда ул үзенчәлекле монументаль графика иҗатчыларының берсе буларак танылa. Соңрак Татарстан сәнгате өчен яңа акварель почеркына ия оста буларак та дан казана. Бу әсәрләрендә эпик-мәһабәт образлар булдыруга һәм панорамалы планнар тудыруга һәвәслек тоемлана.

1980 елларда В.А. Попов бик озак илебез рәссамнарының «Академик дачасында» (Тверь өлкәсе) эшли. Анда И.Е. Репин, И.И. Левитан, А.И. Куинджи, А.М. Васнецов, Н.К. Рерих кебек рус рәссамнарының исемнәре белән бәйле матур традицияләргә аеруча хөрмәт белән карыйлар. Яңа иҗади даирә йогынтысында Владимир Попов майлы буяу нәкышенә әйләнеп кайта; пленэрда күп эшли, аның палитрасы яктыра һәм куера бара, рәссам иҗатының диапазоны да киңәя. Ул тирән фәлсәфи мәгънә белән тулы сюжетлы-тематик картиналар яза башлый: «Ялгызы» («Одна»), «Тагын бер яз» (1983). Элеккеге еллардагы юл-сәяхәт зарисовкалары нигезендә рәссам романтик пейзаж жанрында картина-уйланулар иҗат итә: «Салкын иртә», «Коммунизм пигы», «Көньяк-Көнчыгыш Памир. Тоз күл» (1980) һәм кеше тарафыннан үзгәртелгән табигатьнең сәнгати-гомумиләштерелгән образлары: «КамАЗлар һәм таулар» сериясеннән «Нурек этажлары», «Уходящее – приходящее» (1979). Попов романтикасында һәрвакыт хәвеф элементы, үзенчәлекле вазгыять яки характерлы элементы бар...

КПСС Үзәк Комитетының «Сынлы сәнгатьне алга таба үстерү чаралары турында» карары бу елларда рәссамнар өчен программа

булып тора, ул «сәнгати процессны яңарту, торгынлыкны, инертлыкны, консерватизмны һәм тынычлануны җиңеп чыгу чараларын» билгели һәм «социаль-икътисади өлкәне үзгәртеп кору һәм сыйфатлы яңа рухи тәҗрибә туплау» турында магистраль бурычлар куя. Җәмгыять тормышындагы борылышларны төшенүгә ихтыяҗ туганда, шәхесләр пәйда була. Владимир Александрович Попов – әнә шундый шәхесләрнең берсе. Бөтен гомере буена ул чынбарлыкны сәнгати аңлауда башлап юл ячучы, энтузиаст һәм аны новаторларча образлы формада гәүдәләндерү инициаторы булып тора. Аның бөтен иҗаты эпик киңлек һәм лирик самимилекнең гармонияле синтезы, экспрессив якын килү, гадәти булмаган карашлар, көндәлек тормышта каһарманлык күрергә һәм аны монументаль образларда тормышка ашырырга омтылу белән сугарылган. Гаҗәеп дәрәҗәдә яшәешне сөю һәм яңа тойгыларга омтылу, кешеләрне ярату, зирәк акыл аны һәрвакыт юлга чыгарга этәрә, кайчак бу юл шактый экстремаль булып чыга...

Мәсәлән, 1985 елда СССР рәссамнар берлеге юлламасы белән В.А. Попов БАМда, магистральнең иң катлаулы участокларының берсе булган Төньяк Муйск тоннеленең көнбатыш һәм көнчыгыш порталларында эшли. Бу – мәңгелек туңлык, көчле салкыннар иле, бик матур урыннар булса да, кыргый, яшәү өчен җайлаштырылмаган, сейсмик активлык югары, тектоник ярылулар булган өлкә... Иҗади командировканың нәтиҗәсе буларак, «Юность» мәдәният йортында рәссамның йөздән артык картинасын үз эченә алган күргәзмәсе оештырыла. Ул БАМдагы Тоннельный бистәсенең мәдәни тормышында күренекле вакыйгага әйләнә [Андреев, 1986]. Балаларга рәссам картиналарның ничек язылуы һәм аларга күпме хезмәт салынуы турында сөйли. Өлкәннәр аңа рухи яктан баеткан, алар белән янәшә атлаган өчен, төньяк табигатьнең матурлыгын һәм бөеклеген җырлаган өчен рәхмәт белдерә. Өйгә кайткач, ул монументаль әсәрләр иҗат итә: «БАМ. Ангаракан сөзәклекләрендә» (1987), «Байкал аръягы. БАМ. Кадар» триптихы, «Памир. Тау ташкыны» (1990). Аларда чын мәгънәсендә Рерихның сәнгати принциплары өстенлек итә: «торжественность постигающего созерцания, утверждение общего в дробном, совлечение с вечного лика жизни ее преходящих покровов».

1990 еллар башында Татарстан сәнгатендә милли тарихны аңлау һәм интерпретацияләүгә юнәлтелгән картиналар языла: портретлар, тарихи-эпик әсәрләр. Владимир Александрович шулай ук дини һәм этник эчтәлекле «Дини архитектура җәүһәрләре. Православиенең изге урыннары» сериясенә керәчәк әсәрләре өстендә дә эшли башлый. Шуңа бәйле рәвештә Рус Төньягына берничә тапкыр сәфәр кыла. Останың сүзләренә караганда, бу кеше куллары белән булдырылганнарның үзенчәлекле елъязмасын тудыру омтылышы була. Ул Соловецкий монастырь-ныгытмасы архитектура ансамбле комплексын, Анзер утравы һәм Троица скитын (1991), Карелия архитектурасын (1994) яза. Әсәрләре ике шәхси күргәзмәдә – Зөядәге Иоанн-Предтеча монастыренең Зур соборында [Выставка, 1994] һәм

Казанда Татарстан Республикасы Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залында [Персональная, 1994; Ильина, 1994] күрсәтелә.

Соңрак «Дини архитектура җәүһәрләре» сериясен дәвам иттерү һәм аның икенче өлешен – «Исламның изге урыннары»н булдыру теләге дә рәссам планнарының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Ул натурадан Казан һәм Урта Азия шәһәрләре мәчетләрен яза. Әмма оста моның үз эшләренең репликасы гына икәнен яхшы аңлый; башкача якын килү, бөтенләй яңа сәнгати образ тудыру сорала. Бу эштә аңа танылган театр рәссамы Л.Л. Сперанская ярдәм итә: ул рәссамның игътибарын Казан духовный академиясе профессоры И.М. Покровскийның шәмаилләр коллекциясенә юнәлтә. Любовь Львовна рәссамның музасына, иҗади карьерасының яңа векторында юл күрсәтүче йолдызга, аның беренче тамашачысына, тәнкыйтьче һәм зирәк киңәшчесенә әверелә. Ул аңа ул чиксез ышана. 1996 елда декоратив, темпера белән язылган беренче картиналар пәйда була, аларда композиция үзәген каллиграфик тексттан гыйбарәт бордюр белән әйләндереп алынган архитектура һәйкәле тәшкил итә: «Бохара. Чар-Минар мәдрәсәсе», «Гүзәлләрнең гүзәле – Биби-ханым мәчете», «Сәмәрканд. Гүр-әмир мавзолее. Явыз Тимур төрбәсе» (1996). Бу – рәссам иҗатында ислам чоры башланган вакыт була…

Күренекле татар галиме һәм каллиграфы Н.Ф. Исмәгыйлев (Нәҗип Нәккаш) озак еллар дәвамында каллиграфиядә В.А. Поповның остазы була. Аның җитәкчелегендә реалист рәссам В. Попов классик гарәп язуының төп стильләрен – куфи, сөлс, нәсехне үзләштерә. Рәссам-график В. Поповның язуны үзгә образлы-эмоциональ кабул итүе тугралар – танылган җәмәгать һәм сәяси эшлеклеләрнең, күренекле фән һәм сәнгать әһелләренең исемнәре сериясендә үзенчәлекле яңгыраш ала. Бу елларда рәссам һәм яшь каллиграф В.А. Попов, мөгаен, үзенең иң яхшы әсәрләрен тудыргандыр: «Кара таш. Мәккә», «Барлыкка китерүче» («Создатель»), «Яралтучы» («Творец»), «Болгар», «Сәмәрканд» (1997), «Яңадан торгызылучы Кол Шәриф мәчете» (1999).

Берничә елдан соң киндердә темпера белән язылган шул ук әсәрләр, В.А. Попов үз картиналарын компьютер кулланып яза башлагач (бу процесста аңа дизайнер И.П. Чирков ярдәм итә), башкача яңгыраш ала. Рәссам композицияләр фонын принципиаль рәвештә үзгәртә: нигездә алар – 1970 елларда натурадан язылган пейзажлар яки космик киңлекнең чиксезлеге темасына фантазияләр. Барлык билгеле кануннарны һәм стереотипларны җимерә торган гадәти булмаган чишелешләрне В.А. Попов эмоциональ тәэсир көче гаҗәеп көчле булган картиналарында эзләп таба: «Барыбыз да Аллага буйсынулы» («Подвластно Богу все»), «Башы да, ахыры да – Ул» («Начало и конец – Он») (2008). Рәссам-фикер иясе В.А. Поповның монументаль триптихлар рәвешендә иҗат ителгәнән гарәп язулы композицияләрендә («Ислам дине нигезләре» («Основы религии ислам») (2008), «Тормыш көчләре. Яралтучы боерыгы» («Силы жизни. Наказы творца») (2010), «Сәлам сезгә, Җир кешеләре» («Мир вам, земляне») (2012))

рәссамның иксез-чиксез иҗади потенциалы һәм рухи-әхлакый эзләнүләре чагыла. Масштаблы фикер йөртү сәләте һәм глобаль, гомумкешелек кыйммәтләренә төшенергә омтылу Владимир Поповның төп һәм какшамас сыйфатлары булып кала.

**Литература**


*Андреев А.* Отчёт перед бамовцами // Северный Байкал. № 127 (7175). 21 окт., 1986.

В. Попов. Каталог. Вступительная статья Р. Шагеева. Казань: Типография издательства Тат. ОК КПСС, 1974. 8 с.

*Валеева Д.* В сердце художника // Советская Татария. № 59 (16330). 11 марта, 1973.

*Вылегжанина В.* Молодые художники // Красная Татария. № 127 (9680). 22 июня, 1951.

Выставка в Соборе // Вечерняя Казань, № 106 (703). 4 июля, 1994.

Выставка изобразительного искусства Татарской АССР. Вступительная статья: Н. Черкасова / сост.: М. Мавровская, С. Ишмуратова, Г. Скопин. М.: Советский художник, 1957.

Выставка произведений Владимира Александровича Попова. Живопись, графика. Каталог / сост. Л. Елькович. Казань, 1961. 12 с.

Выставка произведений художников автономных республик РСФСР / сост.: Н.В. Альбова и др. М.: Советский художник, 1971.

Выставка произведений художников РСФСР 1955 года. Живопись, скульптура, графика, прикладное искусство / сост.: С.Л. Веллер, В.Я. Назаров, Л.В. Терентьева. М.: Советский художник, 1955.

*Галеев Б.* Рождение гравюры // Комсомолец Татарии. 1961. № 141 (2478). 26 нояб.

Изобразительное искусство автономных республик РСФСР / сост. В.А. Юдичев. Л.: Художник РСФСР, 1973. 450 с.

*Ильина М.* Гимн во славу красоты // Вечерняя Казань. 1994 № 176 (773). 3 нояб.

*Мелихова Е.* Республика в акварелях // Коммунист Таджикистана. 1972. № 100 (12584). 28 апр.

Первая республиканская выставка эстампа / вступ. статья Л. Елькович; сост. Б. Яхлиель. Казань, 1963.

Персональная выставка Владимира Попова. Живопись. Буклет. Казань, 1994. 8 с.

По Таджикистану. Творческая группа художников-акварелистов Советского Союза. Март–апрель, 1972 г. / вступ. статья Б.А. Маркевич. Душанбе, 1972.

*Попов В.* Глазами художника // Комсомолец Татарии. 1964. № 10–11 (2813–2814). 24 янв.

*Соколов-Скаля П.* Изобразительное искусство татарского народа. По итогам декадной выставки Татарской АССР // Советская Татария. 1957. № 144 (11492). 20 июня.

*Файнберг А.* «Богатырская симфония» художника. С выставки работ Владимира Попова // Советская Татария. 1974. № 253 (16829). 27 окт.

Художники Татарии – КамАЗу / вступ. статья Д.К. Валеевой. Казань, 1974.



***Донина Лариса Николаевна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 746.2

***А.Ф. Борһанова***

# НЫРТЫ ЧЕЛТӘР БӘЙЛӘҮ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЯҢАДАН ТОРГЫЗУ

Данная статья посвящена вопросу возникновения, развития ныртинского кружевоплетения и возрождения традиций плетения на территории Республики Татарстан А.П. Обрезковой. В статье описывается современные попытки возрождения и сохранения данного декоративно-прикладного искусства через освоение технологии плетения кружева и проектную деятельность студентов-дизайнеров.

**Ключевые слова:** с. Нырты, кружевоплетение, кружевницы, Ныртинское кружевоплетение, А.П. Обрезкова.

This article is devoted to the emergence, development of Nyrta lace-making and the revival of the traditions of weaving in the territory of the Republic of Tatarstan by A. Obrezkova. The article describes modern attempts to revive and preserve this decorative and applied art through the development of lace weaving technology and the project activities of design students.

**Keywords:** Nyrty village, lace making, lace makers, Nyrta lace making, A.P. Obrezkova.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә гамәли-бизәлеш сәнгатен саклау һәм үстерү проблемасы шактый актуаль булып кала.

Билгеле ки, 1990 еллар ахырына Татарстан Республикасында халык кәсепчелеге һәм гамәли-бизәлеш сәнгатенең хәле шактый кискенләшә. Халык сәнгатенең күп кенә традицион төрләре юкка чыгу чигендә булып, XIX гасырда гамәли-бизәлеш сәнгатенең шактый алга киткән челтәр бәйләү кәсепчелеге дә шулар исәбендә була. Җитештерүнең әлеге кәсепчелек белән бәйле сәнгати-стиль һәм технологик үзенчәлекләре юкка чыгып бара дияргә мөмкин. Бу исә, республика халкы мәдәни үсешенең тарихи аспектында каралып, хәзерге вакытта челтәр бәйләү традицияләрен торгызу зарурлыгын ассызыклый.

Татар энциклопедиясе мәгълүматларына караганда, челтәр бәйләү – кул яки машина белән җепләрне катнаштырып үреп, бизәкләр ясап, текстиль эшләнмәсе җитештерү, гамәли-бизәлеш сәнгатенең бер төре. Челтәр башлыча өй эчендәге тукыма эшләнмәләрне һәм кием-салымны бизәү өчен кулланыла. Җияк (махсус агач таякчыклар) белән, энә белән тегеп, кечкенә ыргак яки бишинәнең берсе ярдәмендә кулдан башкарыла [Татар энциклопедиясе. 6 т. 1 кис.: Тә–Ч, б. 540].

Россиядә челтәр бәйләүне өйрәнү белән күп кенә тикшеренүчеләр шөгыльләнде: В.А. Фалеева [Фалеева, 1983], С.А. Давыдова [Давыдова, 1913], Н.Т. Климова [Климова, 1991], М.А. Сорокина [Сорокина,

2001], И.Е. Белозёрова и Л.И. Блинова [Белозёрова, Блинова, 2005], Н.Н. Бертяева [Бертяева, 2010] һ.б., әмма Татарстан Республикасы челтәр бәйләү сәнгатен өйрәнүчеләр бармак белән генә санарлык: Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова [Валеева-Сулейманова, 1995, с. 30, 33; Татарская энциклопедия, с. 468–470], А.П. Обрезкова [Обрезкова, 2002; 2006], Л.С. Токсубаева [Токсубаева, 2014] , Е.Н. Менгден (Тимофеева) [Менгден (Тимофеева), 2018] һ.б.

Татарстан территориясендә челтәр бәйләү кәсепчелеге XVI гасырның икенче яртысында барлыкка килә. Челтәр бәйләү рус халкына хас һөнәрчелек төре була һәм русларны Новгород һәм Рязань җирләреннән Урта Иделгә, ә атап әйткәндә, Лаеш һәм Мамадыш өязләренә – Нырты, Балык Бистәсе, Каймар, Анатыш, Полянка, Троицк-Урай, Горица авылларына күчереп утырту барышында таралыш ала. Нәфис тукыманың бу төре Россиядә XIX гасырның икенче яртысында иң югары үсешкә ирешә [Татар энциклопедиясе; б. 540]. Бирегә нәфис кәсепчелекнең төп ике үзәге (Лаеш өязе һәм Мамадыш өязенең Нырты авыллары) барлыкка килә.

Шулай ук башка авыллардагы челтәр бәйләү осталары да билгеле: мәсәлән, Бөреледә (16 оста), Спас өязенең Бездна авылында (20 оста), Питрәч, Арча авылларында; керәшен татарларның Байморза һәм Янсуар авылларында; Кукмарада (чама белән 30 оста) [Тимофеева, б. 94–95]. Димәк, челтәр бәйләү кәсепчелегенең географиясе шактый киң булган. Һәр үзәк бизәк төшерү һәм композициядә үзенчәлекле традицияләре, үзгә техник алымнары белән тарихка кергән.

Традиция буенча челтәр үзе җитештерелгән урын исеме белән аталган. Шуңа күрә Мамадыш өязенең Нырты авылында бәйләнгән челтәрләрне Нырты челтәрләре дип йөрткәннәр. «Татарстан Республикасының торак пунктлары» дигән кыскача белешмәлектә түбәндәге юллар бар: «Мамадыш өязендә бер-берсенә якын урнашкан 2 авыл булган: Олы Нырты, ул челтәр бәйләү кәсепчелеге (XIX гасыр), кырчылык, терлекчелек, умартачылык белән дан алган һәм Нырты Заводы – Мишәнең югары агымында урнашкан авыл. Ул бакыр кою заводы (1749–1874) һәм кырчылык белән танылган [Татарстан Республикасының торак пунктлары; б. 234]. Чыганактан күренгәнчә, ике авыл да бер-берсеннән 1 км ераклыкта урнашкан. 1874 елда завод янган, аны яңадан торгыза алмаганнар, утар җимерелгән. Бирәчәк бурыч буенча ул Түбән Новгород-Самара җир банкына күчкән һәм 3 ел аның милкендә калган [Обрезкова, 2002, с. 9]. Ир-атлар, бернәрсәсез калып, артельләргә берләшкәннәр һәм читкә акча эшләргә киткәннәр. Өйдә челтәр үрүче хатын-кызлар гына калган.

Эшләнмәләрне алар Әбде авылында, Әбде мәхәлләсенә караган күрше авылларда (Ташлыяр, Туктамыш, Кече Кибәче, Олы Кибәче, Өчнарат һ.б.) яки Иске Икшермә авылында (атна саен чәршәмбе базарларында) сатканнар яки башка әйбергә алыштырганнар. Ныртыда челтәр бәйләү күп кенә гаиләләр өчен күпмедер вакыт бердәнбер көн

күрү ысулы булып калган. Осталарның эшләнмәләре нәфислеге һәм җыйнаклыгы белән аерылып торган һәм катлаулы югары сәнгать техникасында, ягъни бизәкнең аерым өлешләре ыргак белән беркетеп башкарылган.

Орнамент еш кына үсемлек мотивларыннан (яфраклар, чәчәкләр, агачлар һ.б.) торган. Нырты сөлгеләренең башлары киң челтәрле итеп эшләнгән. А.П. Обрезкова раславынча, челтәр Балык Бистәсенекеннән купшылыгы белән аерылып торган, аның бизәге эре фигуралардан, шул исәптән «тормыш агачы»ннан гыйбарәт булган. Моннан тыш, өстәмә «үрмә бизәк» кулланылган [Обрезкова, 2006, с. 19]. Бу кәсепчелекнең югары сәнгати үсешкә ирешүе һәм аның территориаль индивидуальлеге турында сөйли.

1899 елның 29 сентябрендә земство идарәсе карары белән Нырты авылында «Челтәр бәйләү мәктәбе» ачыла. Ул Мамадыш земствосы идарәсе һәм өлешчә иганәләр хисабына эшләгән [Обрезкова, 2002; с. 9]. «Мамадыш земство идарәсенең акча хисапларында 1900, 1901, 1902 елларда Челтәр бәйләү мәктәбенең чыгымнарын күрсәткән саннар теркәлгән» – ул ел саен 700 сум тәшкил иткән. Шуның 135 сум 31 тиене – укытучыга хезмәт хакы түләүгә киткән [Обрезкова, 2013, с. 79]. Мәктәп 1912 елга кадәр яшәгән. Һәм 200 йортның һәрберсендә хатыннар да, кызлар да челтәр бәйләгән, осталарның саны 280 гә җиткән.

Челтәр бәйләү мәктәбенең аз булса да кереме булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Челтәр һәм җепләр сатудан 1901 елда 143 сум 61 тиен, 1902 елда 162 сум 8 тиен акча кергән [Обрезкова, 2002, с. 10].

Мәктәптә техник рәсемнәрнең булганнары төзәтелгән һәм яңалары кертелгән, челтәр бәйләү-үрүнең төрле ысуллары өйрәнелгән, бу кәсепчелеккә бер урында таптанмаска мөмкинлек биргән. Мәктәптә әзерләнгән квалификацияле кадрлар югары осталыкка ирешергә һәм челтәр үрүнең иң яхшы милли традицияләрен сакларга ярдәм иткән.

Р.Р. Солтанова билгеләп үткәнчә, «моннан тыш, биредә челтәрләрнең башка төрләрен дә: славян, рус, испан, инглиз, америка челтәрләрен дә үрергә өйрәнәләр. Шулай ук драпировка өчен калын җепләрдән гардина челтәрләре, ныклы киҗе-мамык җепләрдән тюль челтәрләре үрү ысуллары белән танышалар. Кыйммәтлерәк һәм сирәк очрый торган әйберләрдән – аз гына аксыл-сары төскә буялган ефәк җепләрдән челтәрләр; антимаккасарлар (шәмдәлләр астына куела торган квадратлар); аксыл-сары төстәге ефәктән хатын-кызлар өчен якалар һ.б. бик күп нәрсәләр эшлиләр» [Султанова, с. 317].

Әмма күп нәрсә үсеш-үзгәреш кичерә һәм базар мөнәсәбәтләре урнашу нәтиҗәсендә сәнгатьнең коммерцияләшүе сәнгати зәвыкның җимерелүенә китерә. 1930 еллардан соң Татарстанда челтәр бәйләү кәсепчелеге сүлпәнәя, бу эшләнмәләрне экспортка чыгару туктатылу һәм эчке базарда ихтыяҗ киму белән аңлатыла [Тимофеева, с. 96]. Кулдан эшләнгән нәфис эшләнмәләргә алмашка күпләп сатуга

исәпләнгән түбән сыйфатлы продукция тәкъдим ителә башлый. Асылда, псевдосәнгать туа, ул халыкның «эстетик наданлыгы» шартларында гаять киң таралырга мөмкин. Нәкъ менә шуңа күрә без гамәли-бизәлеш сәнгать төрләрен үстерү һәм саклау, ә кайбер очракларда яңадан тудыру проблемасын күтәрүнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңлыйбыз. Аның бер төрен тәшкил иткән һәм әле күптән түгел генә югары үсеш кичергән челтәр бәйләү кәсепчелегенең Татарстан территориясендә дәвамчылары булырга тиеш. Челтәр бәйләү остасы, ТРның һөнәрчелек һәм халык кәсепчелеге палатасы әгъзасы А.П. Обрезкова да бу фикерне хуплаган. Нырты челтәр бәйләү традицияләре 1980 елда яңадан торгызылган. Ул «Родиноведение» этнографик берләшмәсендә катнашучылар белән Әбде авылына экспедиция оештыра, анда Нырты челтәр бизәкләре үрнәкләре өйрәнелә. А.П. Обрезкова җирле халыкның ярдәме белән челтәр бәйләү остасы Е. Молчанованы эзләп таба. Ул 1990 еллар ахырында ук инде Киров өлкәсенең Нократ Аланы шәһәрендә яшәгән [Тимофеева, с. 96]. Җыелган мәгълүматлар Татарстан челтәрләренең Россиянең башка челтәр бәйләү үзәкләре белән тыгыз бәйләнешен эзлекле рәвештә өйрәнергә ярдәм итә. Шунысы хак, Нырты челтәрләре Вологда һәм Нократ (Киров) челтәрләренә стилистик яктан бик якын (аерым алганда, җиякнең характеры буенча).

XXI гасыр башыннан Татарстанда челтәр бәйләү рәссамнар һәм осталар эшчәнлегендә яңадан торгызыла. А.П. Обрезкова өлкәннәр өчен күпсанлы мастер-класслар, курслар үткәрә, төбәкнең мәдәни мирасын саклый. 2007 елдан башлап сакланган үрнәкләр буенча торгызылган Нырты челтәрләре ел саен халык сәнгать кәсепчелекләре эшләнмәләре номинациясендә Татарстанның иң яхшы товарлары исемлегенә кертелә [Тимофеева; с. 98].

Шул вакыттан алып Казан дәүләт мәдәният институтында уку-укыту программасы кысаларында А.П. Обрезкова җитәкчелегендә челтәр бәйләү буенча дәресләр уздырыла башлый.

Бүгенге көндә бу һөнәргә Гуськова Ольга Викторовна өйрәтә. Студентлар әлеге техникада гадәти булмаган дизайнер панносы иҗат итәләр, төрле дәрәҗәдәге конкурс һәм күргәзмәләрдә катнашалар.

2014 уку елыннан Казан федераль университетындагы Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының рәсем сәнгате һәм дизайн кафедрасында студентлар һәм укытучылар инициативасы белән челтәр бәйләү остаханәсе оештырылган иде, анда студентлар һөнәрчелек палатасы остасы А.П. Обрезкова җитәкчелегендә Нырты челтәр бәйләү технологиясен үзләштерде [Бурганова, с. 113].

Алга таба югары уку йортында, халык традицияләрендәге Нырты челтәр бәйләү технологияләрен өйрәнү һәм саклау эшен дәвам итү максатыннан, Р.И. Сәләхова җитәкчелегендә Tatar-style иҗат остаханәсе эшли. 2014–2018 елларда анда фәнни-тикшеренү һәм иҗат эше белән шөгыльләнәләр: остаханәдә Нырты челтәрләре элемент-

лары кергән кием-салым коллекцияләре һәм аксессуарлар («Төбәк моңы» стильләштерелгән коллекциясе (2016) – авторы Борһанова Алсу Фәһим кызы), Казан федераль университеты кунаклары өчен сувенир эшләнмәләр линиясе әзерләнә. 2018 елда Закирова Рания Рәшид кызы (икенче ел магистратурада укый) тарафыннан, гаджетлар файдаланып, Нырты челтәр бәйләү техникасында декоратив аксессуарларның дизайн-комплекты эшләнә.

Хәзерге вакытта Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Әхмәтшина Гөлназ Радик кызы[1] җитәкчелегендә челтәр бәйләү буенча иҗат остаханәсе эшләвен дәвам итә, ул Нырты челтәр бәйләү техникасына өйрәтү дәресләре үткәрә һәм студентлар белән бергә күчмә мастер-класслар уздыра, челтәр буенча иҗат эшләре күргәзмәләрендә катнаша. В 2019–2020 уку елында аның студенткасы Гайнетдинова Энҗе гамәли-бизәлеш сәнгате чаралары (Нырты челтәр бәйләве) ярдәмендә студентларның эстетик зәвыкларын үстерүгә юнәлтелгән тикшеренү эшен дәвам итеп, чыгарылыш квалификация эшенең практик өлешендә панно – триптих эшләде.

Шунысын да билгеләп үтәсе килә: бүгенге көндә кибетләрдә машина ысулы белән әзерләнгән челтәрләрнең ниндиләре генә юк: еш кына бизәкле футболкалар, кардиганнар, я булмаса тулаем челтәрдән генә торган күлмәкләр, итәкләр, перчаткалар һ.б. сатып алырга мөмкин. Тик менә аларның барысын да машина бәйләгән. Җияк белән үрелгән челтәрләрнең артында зур тарихи «багаж» гына түгел, ә бәйләү осталарының нәтиҗәле хезмәте, күңел җылысы, осталыгы һәм һәр эшләнмәгә индивидуаль якын килүе бар.

Бәхеткә, күпчелек хәзерге заман дизайнерларының хезмәтләрендә милли сәнгатьнең кыйммәте торган саен күтәрелә бара, ул үзенең уникальлеге белән бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып тора. Мәсәлән, Дарья Разумихина pret-a-porte коллекцияләрен иҗат итә. Алар бары тик безнең илдә җитештерелгән тукымалардан, рус җитене, тасмалар, кыйммәтле Вологда челтәрләреннән генә әзерләнә. Ә ул вакытта әле КФУ студенткасы һәм Tatar-style иҗат остаханәсе укучысы булган А.Ф. Борһанованың «Төбәк моңы» этник коллекциясе (2016) нәкъ менә Нырты челтәрләрен куллануга ачык мисал була ала.

Шулай итеп, челтәр бәйләү формалары барлыкка килү һәм аның алымнарын саклау традицияләрен яшәтү белән беррәттән, әлеге һөнәр осталарының автор эшләнмәләре булдыруга омтылышы, һәм әлеге кәсепчелекне хәзерге заманда да дәвам итү өчен, гамәли-бизәлеш сәнгатенең яңа һәм үтә нык «кыю» чараларын куллануның аеруча мөһим булуы аңлашыла.

[1] Өлкән укытучы, КФУ / Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты / Г. Тукай исем. милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе / Дизайн һәм милли сәнгатьләр кафедрасы.

Нәтиҗә ясап, тагын бер кат шуны билгеләп үтәсе килә: хәзерге вакытта төбәкнең мәдәни мирасын торгызу һәм аны актуальләштерүгә булышу бик тә әһәмиятле, чөнки Татарстан Республикасы һөнәрчелек сәнгатен үстерүнең хәзерге тенденцияләре буенча, Нырты челтәрләре – милли мәдәниятләрнең киләчәге, милли бердәйлекне саклап калу, толерантлык һәм үзара аңлашу тәрбияләү нигезе.

### Әдәбият


*Белозёрова И.Е., Блинова Л.И.* Русское кружево. Школа плетения на коклюшках / вступ. ст. Э.Г. Истоминой. М: РИПОЛ классик, 2005. 320 с.

*Бертяева, Наталья Николаевна.* Русское сцепное кружево конца XVIII – начала XX в.: дис. ... канд. искусствоведения: 17.00.04 / [Место защиты: Моск. гос. худож.-пром. ун-т им. С.Г. Строганова]. М., 2010. 276 с.: ил. Русское сцепное кружево конца XVIII – начала XX вв.

*Бурганова А.Ф.* История, развитие и сохранение ныртинского кружевного промысла Казанской губернии XIX века // Традиционная культура народов Поволжья: Материалы III Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. В 2-х частях. 2016. С. 110–115.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусство Татарстана. Казань: Фән, 1995. С. 30, 33.

*Давыдова С.А.* Очерк кружевной промышленности в России // Кустарные промыслы России. Женские промыслы в очерках С.А. Давыдовой, Е.Н. Половцовой, К.И. Беренс, Е.О. Свидерской. СПб.: типо-лит. Якорь, 1913. С. 3–182.

*Климова Н.Т.* Народный орнамент в композиции художественных изделий. Цветное коклюшечное кружево: учеб. пособие. М.: Изобраз. искусство, 1991. 224 с., ил.

Кружево // Татарская энциклопедия: в 6-ти т. / гл. ред. М.Х. Хасанов. Казань: Институт татарской энциклопедии, 2006. Т. 3. С. 468–470.

*Менгден (Тимофеева) Е.Н.* История художественных ремёсел Татарстана: вторая половина XIX – начало XXI в.: дис. ... канд. ист. наук: 24.00.01 / [Место защиты: Казан. гос. ун-т культуры и искусств]. Казань, 2018. 194 с.

Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник / гл. ред. М.Х. Хасанов Казань: Институт Татарской энциклопедии Академии наук Республики Татарстан, 1997. 390 с.

*Обрезкова А.П.* История развития кружевоплетения в Казанской губернии (XIX–XXI вв.). Этнохудожественные традиции и язык символов. Казань: Астория, 2006. 28 с.

*Обрезкова А.П.* Кружение кружева: мировые и региональные традиции в развитии кружевоплетения // Сохранение и развитие народных художественных промыслов в едином культурно-образовательном пространстве. Материалы докладов и выступлений участников Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. Казань: 2013. 303 с.

*Обрезкова А.П.* Ныртинское плетеное кружево. Казань: Унипресс, 2002. 24 с.

*Сорокина М.А.* Кружева России. Вологодское кружево: [альбом]. М.: Интербук-бизнес, 2001. 127 с.: ил. (Шедевры народного искусства России).

*Султанова Р.Р.* Неиссякаемый источник вдохновения // Милли-мәдәни мирасыбыз: Кукмара. Казан, 2016. Б. 255–396.

Татар энциклопедиясе. 6 т. 1 кис.: Тә–Ч. Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019. 612 б.

*Тимофеева Е.К.* К вопросу сохранения традиций декоративно-прикладного творчества в начале XXI века (на примере Рыбнослободской и Ныртинской традиции кружевоплетения) // Сохранение и развитие народных художественных промыслов в едином культурно-образовательном пространстве. Материалы докладов и выступлений участников Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. Казань: 2013. 303 с.

*Токсубаева Л.С.* Русское народное искусство Казанского Поволжья XIX–XX веков: деревянная домовая резьба, вышивка, бранное ткачество, кружево. Казань: Центр инновационных технологий, 2014. 140 с.

*Фалеева В.А.* Русское плетеное кружево. Л.: Художник РСФСР, 1983. – 326 с., ил.

***Борһанова Алсу Фәһим кызы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 7.047

***Н.М. Горюнова***

*«ТАТАРСТАННЫҢ НЕФТЬ ТӨБӘГЕ ПЕЙЗАЖЫ» СЕРИЯСЕННӘН*

## ТАЛАНТЛЫ ОСТАЛАРНЫҢ ӨЧ БУЫНЫ

Статья из серии «Пейзаж нефтяного региона Татарстана» знакомит с творчеством ярких представителей разных поколений, объединенных одной школой, – художественно-графическим отделением Лениногорского педагогического училища. На примере искусствоведческого анализа произведений художников М. Закирова, Р. Гумерова и Н. Петрова рассматривается индивидуальный подход авторов к решению образов природы региона.

**Ключевые слова:** пейзаж городской, деревенский, индустриальный; художники юго-востока Татарстана; М. Закиров, Р. Гумеров, Н. Петров, Лениногорское педагогическое училище, традиции, индивидуальная живописная манера художников.

An article from the series «Landscape of the oil region of Tatarstan» introduces the art of the outstanding representatives of different generations, united by one school – the graphic arts department of the Leninogorsk pedagogical college. By example of art history analysis of the works of artists M. Zakirov, R. Gumerov and N. Petrov, we consider the individual approach of the authors to solving the images of nature in our region.

**Keywords:** landscape urban, rural, industrial; artists of southeast Tatarstan; Leninogorsk pedagogical college, traditions, individual painting style.

Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге сәнгате 1950 еллар ахыры – 1960 еллар башында үсә башлый, бу Россиядә милли сәнгать мәктәпләренең артуы күзәтелгән чорга туры килә. Нефть сәнәгате белән бәйле интенсив икътисади тормыш үсү нәтиҗәсендә Татарстан бу исемлектә аерым урын алып тора, бу табигый инфраструктура һәм мәдәниятнең үсешенә китерә. Лениногорск шәһәрендә музыка-сәнгать педагогия училищесы ачылу (1961), ә Бөгелмә шәһәрендә Татарстан АССР сәнгать фондының филиалын оештыру (1958) төбәкнең сәнгать тормышын үстерүгә этәргеч биргән мөһим фактор булып санала. Соңрак бер-бер артлы Әлмәттә (1975) һәм Лениногорскида (1977) күргәзмә заллары ачыла, алар үз чиратында республиканың хәзерге заман тасвирый сәнгатен популярлаштыруда зур роль уйныйлар. Бу вакыттагы әлеге төбәк рәссамнарының күбесе – КСУны тәмамлаучылар. Алар Казаннан Лениногорск педучилищесына укытырга, яңа шәһәрләрне сәнгатьчә бизәү, аларны эстетик элементлар белән баету өчен киләләр. Сәнгать белгече Р.Р. Солтанова сүзләренә караганда, «...шәһәр үзенең индустриаль урбанизация процессында төбәктә сәнгатьнең барлыкка килү һәм үсү шарты булып тора. Икенче яктан, сәнгать үзе бу индустриаль процессның рухи ягын чагылдыра» [Султанова, с. 32–38, 80, 86–87]. Лениногорскиның беренче

профессиональ рәссамы М.Х. Хәертдинов төбәк табигатенә соклана һәм биредә Татарстан рәссамнары өчен «нефть Барбизоны» оештырырга хыяллана [Альметьевская картинная..., с. 7–8, 49, 50]. Аның хыялы тормышка аша: Беренче Республика сәнгать Пленэры Лениногорскида 2015 елда шәһәрнең 60 еллык юбилее уңаеннан Мәснәви Хәертдиновка багышлап оештырыла.

Хәзерге вакытта республикабызның көньяк-көнчыгышында пейзажчы рәссамнарның тулы бер плеядасы эшли. Тәүге язмада бу жанрның күренекле өч вәкиле иҗатына тукталып үтик. Алар барысы да Лениногорск музыка-сәнгать педагогия училищесын тәмамлаган, яшьләре ягыннан гына аерылалар: Мансур Закиров (1937 елгы, педагогы М.Х. Хәертдинов), Ришат Гомәров (1960 елгы, педагогы В.С. Гецев), Николай Петров (1980 елгы, педагогы О.А. Кульпин), һәркайсы – реалистик сәнгать тарафдары һәм туган якларына чиксез гашыйк зат. Әлеге рәссамнарның һәрберсе актив иҗат эшчәнлеге процессында үзенең яраткан предметын сайлый һәм табигатькә үзгә карашын, аны рәсемгә төшерү манерасын булдыра. Аларның әсәрләре 2017–2020 елларда зур шәхси күргәзмәләрдә аеруча уңышлы чагылыш таба.

Мансур Закиров (Шөгер авылында яши) Татарстан табигатенең лирик образлары контрасты йогынтысында, Шушма елгасының тын ярлары – Ангуэм тундрасының монументаль-романтик картиналары, Ерак Көнчыгыш кыялары, Чукотка табигатенең куәтле горур бөеклеге тәэсире белән формалашкан пейзажчы рәссам. Аны Рокуэл Кент һәм Джек Лондон образлары илһамландыра. Ул радист буларак катнашкан геологик экспедицияләр аңа борынгылыкны саклаган әлеге гаҗәеп урыннарны төрле яклап ачкан. Рәссам еш кына тундрага чыгып китеп, кыска таңнарны каршылап, ак төннәрнең буяуларына сокланып, чукот поселокларында зарисовкалар һәм этюдлар ясаган һәм, ахыр килеп, бу гүзәл якны чын-чынлап яраткан. Ивылтин районының Озерный бистәсендә яшәүчеләр аны «Чукотка җире җырчысы» дип атаган. Әкренләп рәссамның рәсем ясау осталыгы арткан, дөньяга, кешенең дөньядагы урынына үз карашы формалашкан. Барлык композицияләр дә диярлек авторның Чукотканың төрле почмакларына походлары, сәфәр, очышлары нәтиҗәсендә туган. Монда Врангель утравыннан пейзажлар да, Ангуэм тундрасы да, Тамватней буровойлары да, төньяк диңгезнең салкын киңлекләре һәм тауларның карлы түбәләре дә бар. Авторның манерасы җылы төсләр гаммасы белән аерылып тора. Әлеге гамманы төньякның җирән туфрагы да бирә. «Навигация» (1980), «Төньяк метеостанциясе» (1980), «Төньяк поселогы» (1982) картиналары табигатьнең борынгылыкны саклаган мәһабәт гүзәллеген көндәлек эшләр белән мәшгуль кешеләр яшәгән сирәк авылларга каршы куя. «Ванкарем балыкчылары» (1985) һәм «Төньяк сулышы» (1989) картиналарын Мансур Закиров иҗатында эталон дип атарга мөмкин. Эчтәлекләре белән алар Төньяк яшәешенең үзенчәлеген тулысынча чагылдыралар: кырыс мәһабәт киңлек, кар баскан түбәләр, салкын су көзгеләре һәм көндәлек профессиональ һәм көнкүреш мәшәкатьләренә

чумган гади кеше тормышы арасындагы контраст. Эшләрнең колориты төсләрдәге җылы гамма төсмерләре кушылмасы белән аерылып тора, аңа төньякның җирән туфрагын һәм һава киңлекләрендә «сфумато» томанын сурәтләп ирешелә. Рәссам күләмнәрне аерым һәм йомшак итеп әвәләүгә төсләрдән төсмерләргә күчешле буяу аша ирешә. Һәм рәссамның иң яхшы әсәрләренә чыннан да әсир итүчән тулы колорит хас [Горюнова, 2020, с. 5–18]. Иҗат шәхесе һәм аның дөньядагы урыны темасы аның нәкышендә аерым бер юнәлешне тәшкил итә. Мансур Закировның күп кенә картиналары рәссамның табигать белән икәүдән-икәү генә калуы турында сөйли. Шәхеснең рухи-иҗади тормышының үзкыйммәтен раслау, көчле хисләрне, күтәренке рухлы һәм савыктыргыч табигатьне сурәтләү – Закиров иҗатының мөһим үзенчәлеге. «Тема эзләгәндә», «Илһам» кебек картиналарында һ. б. рәссам образы һәм аңа ачылган гаять зур гүзәл дөньяның сокландыргыч бергә кушылуын күрәбез. Туган ягына кайткач та, Закировның иҗат эшчәнлеге дәвам итә, ә соңгы дистә еллар дәвамында аеруча нәтиҗәле була. Рәссам өчен туган Татарстаны табигатенең яраткан мотивлары, Шөгернең йөрәккә якын пейзажлары хәзер рәссам өчен сурәтләү предметына әверелә. Рәссамның картиналарыннан безгә болан көтүче якутлар белән янәшә авылдашлары, якташлары карап тора: «Көз. Томан», 2011; «Кышкы авыл», 2010; «Язгы кар», 2011. Аның пейзажларында яңадан монохром, нәфис төсләр гаммасы пәйда була, ул энҗекөмешсыман төсмерләре һәм импрессионистик алымнары белән әсир итә: «Сыкы. Салкын иртә» (2011); «Мәчетле пейзаж» (2012); «Кышкы мотив», (2013). Туган җиребезнең кышкы пейзажлары аеруча матур [Горюнова, 2016, с. 58]. Автор Төньякның гаҗәеп мавыктыргыч образларыннан да аерылмый, аның дистәләгән этюдлары үзләренең романтик матурлыгы белән таң калдырган зур полотноларга әйләнә: «Балыкчы алачыгы» (2000); «Чукотка. Көтү» (2006); «Соңгы үткел» (2001); «Җәйге һава торышы» (2006) һ.б.

Ришат Гомәров сәнгать училищесында укыган вакытта ук Татарстанда танылган рәссамнарның тулы бер плеядасын тәрбияләгән талантлы педагоглар җитәкчелегендә иҗат итә башлый. Ул педагоглар В. Гецев, О. Кульпин, Татарстанның күренекле пейзажчысы А. Прокопьев нәкыше белән кызыксына. Алга таба да нәкыш осталары һәм хезмәттәшләре белән аралашу аңа иҗади потенциалын ачкан пейзаж белән мавыгырга ярдәм итә. Гомәров XX гасырның бөтендөнья реалистик рәсем сәнгате традицияләренә тугрылыклы кала: картиналарында табигатьтәге төсләрне саклый, әмма ул аларны безнең хәзерге шәһәрләр, поселоклар һәм авыллар тормышының конкрет мотивлары белән баета, әйләнә-тирә дөньяның барлык күренешләрен һәм халәтен яратып сурәтли, – рәссамның һәр полотносында нәкъ менә шул сыйфат ярылып ята. 1995 елдан Гомәров төрле күргәзмәләрдә актив катнаша башлый, бу аңа берөзлексез һәм тайпылышсыз һөнәри яктан үсәргә ярдәм итә. 2000 еллардагы күргәзмәләрдә без үзенчәлекле таныш манерага ия һәм чынбарлыкка үз карашы булган тулысынча

формалашкан рәссам белән очрашабыз. Рәссамның эшләре оптимизм, гадәти булмаган, еш кына югары фикерле, уйланылган, зәвыклы композицияләре белән аерылып тора. Алар авторның югары нәкыш техникасына ия булуын күрсәтеп тора: «Вандовка. Әбиләр чуагы» (2005) яки «Салкын иртә» (2006), «Язгы ташу» пейзажларындагы кебек пумала һәм мастихин белән үзенчәлекле динамик буялыш – штрихлар төшерә [Альметьевская картинная..., с. 7–8, 49, 50]. Р. Гомәров үзен лирик пейзаж жанрында аеруча ачык күрсәтте. Ул табигатьнең таныш күренешләрендә күтелмәгән матурлыкны ассызыкларга тырыша: әле йорт түбәсен һәм яңгырдан соң якты кояш нурларына күмелгән агачларны, әле авыл өенең гап-гади болдыры белән ап-ак чәчәккә күмелгән купшы шомырт куагы арасындагы контрастны күрсәтә («Шомырт чәчәк ата», 2000). Кискен контраст төсләр һәм бай фактура тулы көзге һәм кышкы пейзажлар сәнгати-образлы тәэсирлелек ягыннан аеруча отышлы. Соңгы елларга караган эшләре рәссамның осталыгы арту һәм пейзажга яңа караш формалашу турында сөйли. Ул монументаль, эпик һәм халык тормышыннан, хезмәтеннән аерылгысыз була бара. Картиналар композициясе горизонталь буйлап сузыла һәм, туган җирнең матурлыгын һәм байлыгын данлап, гомумиләштерелгән синтетик характерга ия була («Җәйге иртә», 2019). Рәссамның төрле күргәзмәләрдә катнашкан җете төсләргә бай картиналары тамашачыларда зур кызыксыну тудыра [Горюнова, 2018, с. 82–85]. 2019 елда Р. Гомәровның юбилее уңаеннан оештырылган соңгы күргәзмәсе аның талантын төрле яклап ачты: ул – пейзажчы да, башкаларга охшамаган портретчы да, матур натюрмортлар авторы да.

Николай Петровның җитлеккән нәкыш стиле 2000 елларда барлыкка килә. Бу вакытта язылган пейзаж, портрет һәм натюрмортлары төсләрнең җиңеллеге, импрессионистлык һәм аңа хас композиция һәм пространстволы-пластик чишелеш үзенчәлекләре белән аерылып тора [Епишин, с. 50–53]. Әлмәтнең Реклама һәм шәһәрне бизәү департаментында эшләү аңа хәзерге заман шәһәр мохитен барлыкка китерергә ярдәм иткән төрле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. Параллель рәвештә көннән-көн ул сөекле шәһәрендәге тормышны, аның үсешен, кәефләр, ел фасыллары үзгәрүне тирәнтен уйланып һәм яратып күзәтә. Әһәмиятле зарурият, хәзерге шәһәр киңлегенең тышкы күренешен кайгырту, функцияләр төрлелеге һәм яраткан жанрына – шәһәр һәм авыл пейзажына ихлас бирелгәнлек аның профессиясендәербөтен тәшкил итә. Акрынлап рәссам Татарстанның Көньяк-Көнчыгыш төбәге сәнгатендә үзенә шактый зур урын алуга ирешә. Бер генә эре күргәзмә дә аның катнашыннан башка узмый [Горюнова, 2018, с. 82–85]. Ул күбесенчә лирик пейзаж, натюрморт һәм сирәк кенә тематик картина остасы буларак чыгыш ясый. Соңгы елларда ул табигатьнең төрледән-төрле күренешләре: бала чагыннан ук яраткан авыл мотивлары, үзе озак еллар гомер кичергән шәһәрләрнең төрләре һәм, ниһаять, республиканың көньяк-көнчыгышында, рәссамның туган җирендә нефть чыгару белән бәйле индустриаль пейзаж

өстендә мавыгып эшли. Пленэрлыкны рәссам үз иҗат методының нигезенә сала, барлык пейзажларын ул натурадан яза. «Көз» (2010), «Ритм» (2013), «Алтын көз» (2015) кебек эшләре фронталь тыныч композиция, йомшак, зәвыклы колорит һәм җиңел язу манерасы белән аерылып тора. Аларның сюжетлары М.В. Нестеров, Б.Ф. Домашников картиналарын хәтерләтә, алар шулай ук реалистик, ләкин шул ук вакытта гомумиләштерү көченә дә ия. 2015 елда язылган «Алтын көз» картинасын рәссамның программ полотносы буларак ассызыклап күрсәтергә мөмкин. Ул Петровны һәм рәссам, һәм зур шәхес буларак характерлаучы эчтәлекле һәм матур сыйфатларны үзенә туплаган. Анда төсләрнең сафлыгы һәм чисталыгы, чынбарлыкны тоюда лириклык, шулай ук картинаның формаль-пластик элементларында иллюзоркиңлек, декоратив һәм эмоциональ-тәэсирле башлангычны табу омтылышы тантана итә. Бу сыйфатлар табигатьнең үзендә яшеренгән: алтынсу сары төскә кергән каеннарның җиңел силуэтында, күк йөзенең үтә күренмәле нәфис зәңгәрлегендә һәм авыл корылмаларының көмешсыман төсмерендә. Соңгы вакытта ул шәһәр пейзажын мавыгып сурәтли: эре нефть үзәге булган Әлмәт шәһәренең якты образын тудыра. 2016–2018 елларга караган пейзажларында төсләрнең көче арта, буялыш куера, гайрәтлерәк була бара һәм аның рәсем сәнгатендә роле дә сизелерлек күтәрелә. Эчтәлек башлангычы конкретлаша һәм аңлаешлы-билгеле төс ала. Табигатьтәге төсләр байлыгы рәссам өчен чын-чынлап ләззәт чыганагына әверелә. Нәкъ менә этюд нәтиҗәдә төгәлләнгән «продукт»ны тәшкил итә, ә этюдлардан тәэсирләнү мозаикасыннан акрынлап тулаем бер шәһәр образы барлыкка килә. Петров Әлмәткә гашыйк кеше. Аның пейзажларында без киң урамнар, мәйданнарны гына түгел, ә паркларны да, ишегалларындагы аулак почмакларны да, хәтта архитектура элементларын да (тәрәзәләр, тәрәзә йөзлекләре, ян капкалар, эскәмияләр) күрәбез. Скульптура һәйкәлләре, истәлекле тарихи биналар белән янәшә яңа төзелешләр, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен дә сурәтли ул. Рәссам шәһәр атмосферасын, аның пульсын, тормыш ритмын бирергә омтыла. «Алсу йорт» (2016), «Әлмәттәге ишегалды» (2018) исемле кечкенә этюдларында ул уянып килүче язгы шәһәр атмосферасын бик оста тотып ала, төсләр дә уңышлы сайланган. Шәһәрнең төп магистрале – Ленин урамы күренешләрен биргән пейзажлар аерым игътибарга лаек. Аңа төрле эчтәлекле дистәләгән полотно багышлана: «Әлмәт. Ленин мәйданы» (2017), «Әлмәт. Ленин урамы. Көз» (2017). Алар арасында соңгысы оригиналь панорама композициясе (70 см га 200 см) белән аерылып тора. Полотнода яңгырдан соң кибәргә дә өлгермәгән юл һәм йортлары белән (аларга кояш нурлары сибелгән) кинәт эчкә кереп киткән урамның фронталь кисеме ачык күренә. Көзге агачлар, юеш күпергә коелып һәм йортларның, фонарьларның, узып баручы машиналарның чагылышы белән кушылып, үзләренең алтын төсләрен акрынлап җуя баралар. Рәссамның динамик нәкыш манерасы, өслекләр юнәлеше һәм тирәлектәге төсләр төрлелеге бу тыныч

күзге пейзажны дулкынландыргыч итә. Петров пейзажларының тулы бер сериясе яңа төзелешләр шигъриятенә багышланган: «Яңа квартал» (2017), «Шәһәр төзелә», «Яңа микрорайон» (2017) һ.б. «Нефть темасы» Татарстанның совет һәм хәзерге заман сәнгатенең үзәк темаларының берсе. Ул Николай Петров өчен дә якын: «Буровой» (2016) кебек кечкенә этюдлар, аннан зуррак «Артык тирән» (2012), «Яңа скважина» (2017) «Буровойның көченүе» (2017) картинасының берничә варианты. Петровның индустриаль пейзажлары сериясе хезмәт казанышларының героик романтикасы, яңа эзләнүләр белән тулы. Дәртле яңгыраш, җете төсләр гаммасының сафлыгы, аның якты кояш нурларына күмелгәнлеге, кыска кискен буялыш һәм гомуми нәкыш рәтенең декоратив бөтенлеге – бу картиналарның үзенчәлекләре менә шунда [Горюнова, 2018, с. 115–127].

Үзләренең иҗади үсеш процессында рәссамнар Закиров, Гомәров һәм Петров төрле жанрларга мөрәҗәгать итәләр, өйрәнәләр һәм үзләрен төрле сәнгать алымнарында һәм материалларда сыныйлар. Әмма аларны нинди генә мотивлар илһамландырмасын: шәһәр яки авыл пейзажымы, архитектура һәйкәлләре яки нефть төбәгенә хас билгеләрме, индустриаль мотивлармы – нәкыштә барысы өчен дә уртак бер сыйфат бар: лиризм, дөнья матурлыгына гашыйклык һәм аның күптөрлелеге. Илебез пейзаж мәктәбенең иң яхшы традицияләрен үстереп, Мансур Закиров табигатьнең романтик-фәлсәфи образларын тудыра, Ришат Гомәров үзәкләргә үтеп керә торган лирикага тартыла, Николай Петров шәһәр тормышының тетрәндергеч дәртлелеген һәм динамикасын бирә, ә барысы бергә алар Туган җирнең бай табигатенә дан җырлый.

**Әдәбият**


Альметьевская картинная галерея. Живопись. Графика. Музей-галерея «Новый эрмитаж – один». М., 2005.

*Горюнова Н., Саярова Э.* Маснави Хаертдинов. Казань, Рухият, 2009.

*Горюнова Н.* Новости Юго-Востока. Осень – 2015 // Вестник. 2016. № 2. С. 58.

*Горюнова Нина.* Хроника художественной жизни города Лениногорска // Искусствоведение Татарстана: альманах. Вып. 1. Теория, история, современная художественная практика / авт.-сост. Р.Р. Султанова. Казань, 2017. С. 263 – 269.

*Горюнова Н.М.* Николай Петров // Альметьевск любимый, жемчужина края. Казань: Заман, 2018. С. 118–127.

*Горюнова Нина.* Художники юго-востока Татарстана: простота и искренность // Казань. 2018. № 1. С. 82–85

*Горюнова Нина.* Мансур Закиров – художник, очарованный Чукоткой // Закиров Мансур. Казань: Фолиант, 2020. С. 5–18.

*Епишин А.С.* Удачный дебют // Русская галерея – 21 век. 2013. № 4. С. 50–53.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990 гг.). Казань, 2001.

Члены Союзов художников в Республике Татарстан // Искусствоведение Татарстана: альманах. Вып. 1. Теория, история, современная художественная практика / авт.-сост. Р.Р. Султанова. Казань, 2017. С. 294, 298.



***Горюнова Нина Михайловна,***
*сәнгать белгече, РСФСР Халык мәгарифе отличнигы*

УДК 930.271

***В.М. Усманов***

## КӨНЬЯК УРАЛ ТАШЪЯЗМАЛАРЫ:
## Оренбург өлкәсе Мостафа авылындагы эпиграфик һәйкәлләр

Статья посвящена изучению эпиграфических памятников села Мустафино Оренбургского края второй половины XVIII–XX вв., собранных учеными во время экспедиции, проведенной в 2019 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова по татарским деревням. Исследование актуально с точки зрения определения роли татарского народа в истории края. Представленные в статье фактические материалы по эпиграфике позволяют оценить сохранившееся наследие татарской культуры в памятниках и увидеть уникальность искусства того времени.

**Ключевые слова:** экспедиция, эпиграфика, эпиграфические памятники, культурное наследие, Оренбургский край, село Мустафино.

The article is devoted to the study of the epigraphic monuments of the Mustafino village of the Orenburg region of the second half of the 18th–20th centuries, collected by researchers during an expedition conducted in 2019 by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov on the Tatar villages. The study is relevant for determining the role of the Tatar people in the history of the region. The factual materials on epigraphy presented in the article make it possible to evaluate the preserved heritage of Tatar culture in monuments and see the uniqueness of the art of that time.

**Keywords:** expedition, epigraphy, epigraphic monuments, cultural heritage, Orenburg region, Mustafino village.

Россия империясендә Оренбург татарлары – беренчеләрдән булып, Петербург белән Урта Азия арасындагы кәрван юлларын яңадан җайга салган халык. Ул маршрут («Мәскәү юлы») Казан – Оренбург шәһәрләре аша үткән. Шушы юл буйларында тукталу өчен *«почта ям»нары* дип аталган Биккол, Йөзәй, Мостафа, Сарманай, Дүсмәт, Нәүрәз, Котлымбәт, Якуп, Абдулла, Тирес-Усман, Чаганлы, Габдрахман, Иске Шалты авыллары барлыкка килгән. Анда мосафирларның юл ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм дәүләт вазифаларын башкару, сәүдәгәрләр өчен бөтен кирәк-ярак, инфраструктура булдырыла: тукталу йортлары – кунакханәләр белән бергә, келәт, абзар кебек корылмалар төзелә [ГАОО, ф. 6, д. 3074, 7082]. Шулай итеп, элеккеге Нугай Урдасы биләмәләрендә яңа сәяси һәм икътисади максатларны тормышка ашыру өчен, башка халыклар белән бергә, Идел буе татарлары да күпләп бирегә җәлеп ителә.

XVII–XIX йөз башларында Оренбург каласы (һәм Шәһре Каргалы) татар халкы мәдәни үзәкләренең берсенә әверелә. Биредә, сәүдә эше белән бергә, сәнәгатьчелек югары баскычка күтәрелә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, сәләтле химаяче-меценатлар пәйда була. «Авыл үзәгендәге бай йорт утарлар шәһәр җирендәгечә икешәр катлы итеп

салынганнар, мәчет һәм кибетләр, өйләрнең аскы өлешләре зур-зур итеп тау ташыннан күтәрелгәннәр һәм каладагы биналардан аларның һич кенә ким урыннары юк. Күккә ашкан мәчет манаралары да шәһәр күренешен хәтерләтә» [Рәхимкулова, Хәмидуллин, с. 78–79].

1747 елгы ревизия материаллары буенча, 1744 елда Нит елгасы буенда (башка татар авылларыннан әллә ни аерылмаган) Мостафа авылы барлыкка килә. (Архив чыганакларында биредә ир-атлардан 92 кеше яшәгәнлеге күрсәтелгән.)

Бу торак пункт, юл өстендә урнашуы аркасында, Е. Пугачев фетнәсенә бәйле вакыйгалардан да читтә кала алмаган [Искандаров, с. 256]. Бу төбәктә булган хәлләр А. Пушкинның «*Истории Пугачева*» («*История Пугачёвского бунта*») дип исемләнгән тарихи китабының өченче бүлемендә телгә алына [Пушкин, с. 628].

2019 елның июнь аенда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ хезмәткәрләре халкыбызның Оренбург төбәгенең тарихын һәм мәдәни мирасын барлау-өйрәнү максаты белән, аерым алганда, аларның сөйләш үзенчәлекләрен, тормышын, мәдәният-сәнгатен, ташъязма һәм кульязма истәлекләрен барлау җәһәтеннән фәнни экспедициягә чыкты.

Гомумән, сакланып калган ташъязма мирасны кичекмәстән эзләп табу, барлау һәм каталоглар төзеп бер урынга туплау татар эпиграфистларының зур бурычы булып тора. Борынгы ташъязмаларны өйрәнү, фотога төшерү, рәсем-эстампажлар ясау, оттиск-күчермәләр алу, текстларны кәгазьгә беркетү шактый күләмдә башкарылган булса да, бу өлкәдә эшлиселәр әле бик күп.

Фәнни сәфәрнең төп максаты татар ташъязмаларын өйрәнү юнәлешендә, беренчедән, (сыйфатлы, ягъни яхшы «укылышлы» фоторәсемнәрдән башка) эпиграфик һәйкәлләрнең төгәл үлчәмнәрен һәм координатларын алу иде. Икенчесе – аларны хронологик яктан тәртипкә китереп, укылышларын биреп, билгеле бер системага салып, каталоглар төзү.

Әлеге экспедициядә сиксәннән артык каберташ өйрәнелде: Оренбург шәһәрендә – 4 фрагмент; Сакмар районы: Татар Каргалысында – 1; Октябрьский районы: Беренче Иманколда – 56, Бикколда – 17; Шарлык районы: Йөзәйдә – 24, Мостафада – 38 ташъязма документ дәфтәргә теркәлде. Исәпкә алынган ядкярләрнең иң әүвәлгеләре XVIII йөзгә, ә иң соңгылары XX йөзгә (1948 елга) карый, әмма шунысы әһәмиятле: бу төбәктә кабер ташларын кую гадәте Дәште Кыпчак дәүләте һәм Нугай Урдасы заманнарыннан ук килә[1]. Кызганычка

[1] «Около Уйской линии, как на киргизской, так и на башкирской стороне реки Уя, в разных местах находятся развалины каменных строений, из коих некоторые поныне еще в целости. О сих из живущих в Исетской провинции татар один престарелый человек подполковнику Ренненкампфу по преданию предков своих объявлял, якобы в древние времена жившие в сих местах народы отошли в Китайское государство. Оные доныне видимые строения ничто иное, как знатных их людей кладбища, в которых они погребены» [Рычков, С. 134–135].

каршы, ул чорлардагы эпитафия һәйкәлләре сакланып калмаган. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу яклардагы җирләр Россиягә кушылган дәвердә барлыкка килгән «таш архив» мәгълүматларының иң әүвәлгеләре Каргалы һәм Оренбург кятибләре («таш язгучы»лары) тарафыннан башкарылган. Ә кабер ташларының күбесе, урындагы гади авыл кешеләренең кулы белән ясалган.

Беренче Иманкол ташъязмалары түбәндәгеләрне әйтеп була: биредәге ядкярләр бик калку булмаган, классик нәсех язуы үрнәкләреннән аерылып торган, гади хәрефләр белән башкарылган һәм алар, шул үзенчәлекләре һәм палеографик нечкәлекләре белән башка профессиональ хаттатларның (каллиграфларның) эшләренә бөтенләй охшамаган, аларның саны – чама белән 100–200. Иманкол ташлары янәшәдәге күл буенда урнашкан тау кыры карьерларыннан алынган. Шул ук уңайлы йомшак материал авылда бина-корылмалар төзүдә дә кулланылган.

Биккол ташъязмалары хакында шунысын әйтеп үтәсе килә: авыл зираты ике өлештән тора, каберстан биләмәсенең уртасыннан борынгы «Әби патша» юлы үтә, ул әлеге көндә дә халыкка игелекле хезмәт күрсәтә. Эпитафияләрнең саны шактый булса да, аларның күбесе (ташларның сыйфатсыз булуы нәтиҗәсендә) начар хәлдә. Күрәсең, мондагы кабер ташлары «өлгермәгән» йомшак материалдан ясалган.

Тирә-як авылларда (шулай ук төзелеш эшендә) урындагы комташлар да кулланышта булган. Кайбер кабер ташларын ясаганда, читтән (мәсәлән, Каргалы тарафындагы Гребенни тавыннан [Рычков, с. 128]) китерелгән известьташ та кулланылган.

Йөзәй авылы зиратындагы ядкярләр арачында да Каргалы осталарының берничә эше бар, мәсәлән, мулла Хәйрулла Госмановныкы (1866–1915). Оренбург өлкәсенә сәфәр нәтиҗәсендә, Оренбургтан – Шәриф, Бикколдан – Габделлатыйф, Иманколдан – Ришад Туганов кебек безгә мәгълүм булмаган осталар язган ташлар булу да ачыкланды.

Ташлардагы текстларның күбесен Коръән аятләре һәм хәдисләр тәшкил итә. Беренче Иманкол ташъязмаларында төрки тамгалар да очрый. Әлбәттә, бу күренеш борынгы чорлардан калган күчмә кыпчакларның (һәм Нугай Урдасы татарларының) гореф-гадәтләре чагылыш табуны аңлата.

Кайбер эпитафияләрдә биләгән исем-вазифа яисә һөнәр, мәсәлән, *сәүдәгәр, ахунд, мулла (менла), хәлфә, мөдәррис* атамалары күренә.

Игътибарга лаек күренешләрдән: бу як авыллардагы каберстаннарда, читтән китерелгән мәрмәр, гранит кебек кыйммәтле ташлардан ясалган (мәсәлән, «чалмалы» сигез кырлы таш багана рәвешендәге монументаль) һәйкәлләр очрамады. Гомумән, Идел-Урал төбәгендә күп очракта известьташ кулланылган һәм шунысы кызык: хаттат-каллиграфларыбыз өчен ул элек-электән иң уңайлы материалларның берсе булып саналган.

Ата-бабаларыбыз безгә гаять бай мирас калдырганнар. Ул ташъязма хәзинә ни кызганыч кырыс һава шартларында үзеннән-үзе җуелып-җимерелеп юкка чыга бара. Безнең максат – шуларны яхшылап өйрәнү, кәгазгә теркәү, китап-каталоглар рәвешендә матбугатта нәшер итү.

### *Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылының кайбер ташъязма истәлекләре*



***Беренче ташбилге.*** Иман бине Заит каберенә куелган таш. XVIII йөзнең икенче яртысы – XIX йөз башы. Палеографик үзенчәлекләре (хәрефләрнең пычак белән капма-каршы авыштырып кисү осулы белән тирән канаучык рәвешендә язылып, классик нәсех язуы шәкелендә башкарылуы) буенча эпитафиянең авторы исеме билгесез Каргалы кятибе булган дип фараз итәбез. Моның ише үрнәкләр Сәгыйть бистәсе зиратында еш очрый.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| امان بن ظايط | Иман бине Заит |

Үлчәмнәре: 12,5×30×62 см.
N 52°49'46"
E 54°46'34"



***Икенче ташбилге.*** Зөләйха Арыслан кызы каберенә куелган эпитафия, 1815 ел. Материал – кызгылт-көрән төстәге йомшак комташ. Авторы билгеле түгел.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ... ليحا بنت ارسلان وفات اولدى ١٨١٥ | [Зө]ләйха бинте Арыслан вафат улды 1815 |

Үлчәмнәре: 20–23×22×60 см.
N 52°49'50"
E 54°46'36"



***Өченче ташбилге.*** Рәхмәтулла Исхак угылы каберенә куелган эпитафия, 1826 ел. Материал – кызгылт-көрән төстәге йомшак эшкәртелмәгән комташ. Палеографик үзенчәлекләре (текстның гади нәсех язуында башкарылуы) буенча эпитафиянең авторы шушы авыл кятибе булган дип фараз итәбез.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ۱۸۲۶ سنه وفات بولدى | 1826 сәнә вафат |
| رحمتوالله اسحاق اوعلى | булды Рәхмәтулла |
| | Исхак угылы |

Үлчәмнәре: 12–18×22×56 см.
N 52°49'45"
E 54°46'33"



***Дүртенче ташбилге.*** Гыймадеддин бине Исмәгыйль каберенә куелган эпитафия, 1873 ел. Материал – известьташ. Палеографик үзенчәлекләре («бозык нәсех» рәвешендә башкарылуы) буенча эпитафиянең авторы исеме мәгълүм булмаган Яшерган авылы кятибе булуы мөмкин, моңа охшаш ядкярләр шул якларда еш очрый.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| اعوذ بالله | Әгузе билляһи |
| من الشيطان الرجيم | минәш-шәйтан ир-раҗим[1] |
| بسم الله الرحمن الرحيم | Бисмилляһир ир-рахман ир-рахим[2] |
| لا اله الا الله محمد | Ля иляһә илля Аллаһ Мөхәммәд |
| رسول الله يَا وقفًا | рәсүл Аллаһ[3], йа вакыйфән |
| بقبرى متفكراً فى امرى | би-кабри мөтәфәккирән фи-әмри |
| بالامسى غداً تصير مثلى | бил-әмси күнтү гадән тәсайир мисли[4] |

---

[1] *Әгузе билляһи минәш-шәйтан ир-раҗим* – таш белән куылган шайтаннан качып, Аллаһка сыгынам.

[2] *Бисмилляһир ир-рахман ир-рахим* – рәхимле, шәфкатьле Аллаһның исеме белән.

[3] *Ля иляһә илля Аллаһ Мөхәммәд рәсүл Аллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.

[4] *йа вакыйфән би-кабри мөтәфәккирән фи-әмри бил-әмси күнтү гадән тәсайир мисли* – әй каберем янына килеп басучы, минем хәлне фикерлә; бүген шул хәлеңдә булсаң, иртәгә минем кебек булырсың.

| | |
|---|---|
| حی الدنیا سجن الموءمن | хәййе әд-дөнйа сиҗнүн ли-мөэмин |
| وجنت الکفر الدنیا ساعت | вә җәннәт әл-кяфир[1], әд-дөнйа сәгатүн |
| فاجعلها طاعت دا | фә-әҗгальһа тагатән[2] да- |
| رالفنادان دارالبقا | -релфәнадән дарелбәка- |
| یه رحلت اولدی ۱۸۷۳ | -йә рихләт улды 1873 |
| یلده ماینںک ۲۹ یومنده | йылда майның 29 йәүмендә |
| قاری حافظ کلام ربانی | карый хафиз кәлям раббани[3] |
| داملا عمادالدین بن | дамулла Гыймадеддин [бине] |
| داملا اسماعیل و امَّهُ ببی | дамулла Исмәгыйль вә өммәһү биби |
| عیشة | Гайшә[4] |

***Бишенче ташбилге.*** Зөбәйдә Әхмәджан кызы каберенә куелган эпитафия, 1891 ел. Материал – известьташ. Палеографик үзенчәлекләре (профессиональ нәсех төрендә башкарылуы, өске һәм аскы яссылыкларда хәреф элементларының нечкә сызыклардан киңәеп тасма сыман сузылып кабатлануы, тирән булмаган уеп-кисү алымы белән каурый каләм язуы рәвешенә охшатылуы) буенча эпитафиянең авторы исеме мәгълүм булмаган профессиональ таш язу остасы икәнлеге күренеп тора.



Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ... من | ... мин |
| دارالفناء الی دار | дарелфәнаи әли дар- |
| البقأ زبیده | -ел бәкаи[5] Зөбәйдә |
| بنت احمدجان | бинте Әхмәджан |
| فی سنة ۱۸۹۱ | фи сәнәти[6] 1891 |
| ... | ... |

Үлчәмнәре: 10×26×93 см.
N 52°49'47"
E 54°46'32"

---

[1] *Хәййе әд-дөнйа сиҗнүн ли-мөэмин вә җәннәт әл-кяфир* – дөнья – иманлылар өчен зиндан, кяферләргә – җәннәт.

[2] *Әд-дөнйа сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән* – дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр.

[3] Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән Коръән китабын яттан белүче.

[4] *Биби Гайшә* мәрхүмнең әнкәсе булган дип аңларга кирәк.

[5] *Вакытлы дөньядан мәңгелек дөньяга [күчте].*

[6] *Сәнә* – ел.



***Алтынчы ташбилге.*** Мулла Әхмәдҗан бине Сәлим Рәмиев каберенә куелган эпитафия, 1892 ел. Материал – известьташ. Эпитафиянең авторы мәгълүм түгел.

Алгы ягында: (уйма язулы):

قد ارتحل من دارالفناء الى دارالبقاى... جعل مثواه
فى... احمدجان بن سليم ... فى سنة ١٨٩٢

... Әхмәдҗан бине Сәлим ... фи
сәнәти 1892

Үлчәмнәре: 16×29×103 см.
N 52°49'50"
E 54°46'40"

***Җиденче ташбилге.*** Миңлеҗәмал бинте Нигъмәтулла каберенә куелган эпитафия, 1900 ел. Материал – известьташ. Палеографик үзенчәлекләре (нәсех язуының «дөрес» язылуы) буенча эпитафиянең авторы – профессиональ таш язу остасы, исем-шәрифләре билгеле түгел.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| قد ارتحلت من | кадд иртихаләт[1] мин |
| دارالفنا الى دار | дарелфәнаи әле дар- |
| البقأ منكلى جمال | -елбәкаи Миңлеҗәмал |
| بنت نعمة الله | бинте Нигъмәтулла |
| رحمهما الله تعالى | рәхәмәһума Аллаһы Тәгалә |
| رحمة واسعة فى | рәхмәтән васигатән фи |
| سنة ١٩٠٠ | сәнәти 1900 |

Үлчәмнәре: 10×31×85 см.
N 52°49'45"
E 54°46'33"

***Сигезенче ташбилге.*** Әхмәдҗан Хәсән угылы каберенә куелган эпитафия, 1904 ел. Материал – известьташ. Палеографик сыйфатлары (урта куллы нәсех язуында башкарылуы) буенча эпитафиянең авторы – шушы авылның (исеме билгесез) таш язу остасыдыр.

[3] *Иртихал* – дөньядан күчү.

Алгы ягында: (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| احمد جان حسن اوعلی وفات بولدی ۱۹۰۴ نچی یلده ۲۹ مایده | Әхмәдҗан Хөсәен углы вафат булды 1904 нче йылда 29 нчы майда |

Үлчәмнәре: 11×28×63 см.
N 52°49'49"
E 54°46'43"

Аңлашыла ки, бу төбәктәге авылларда кабер ташы язмаларының саклануы ул, беренчедән, борынгыдан халкыбызның дәүләтчелеге һәм элек-электән язма культурасы булуын күрсәтә. Икенчедән, милләтебез, тормыш кыенлыкларына карамастан, даладагы ерак авылларда булса да, борынгыдан килгән ташъязу сәнгате традицияләрен сакларга омтылган. Мостафа авылындагы кабер ташлары да – шуңа дәлил. Бу язма чыганаклар Оренбург төбәгенең тарихын ачыклау өчен дә кыйммәтле материал булып хезмәт итәрләр дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**


ГАОО.Ф. 6. Д. 3074, 7082.

ГАОО. Ф. 98. Д. 3. Оп. 2. Л. 123–133.

*Искандаров Р.Ш.* Оренбургские татары: историко-энциклопедический очерк. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 271 с.

*Рәми И., Даутов Р.* Әдәби сүзлек: (элекке татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

Крестьянская война в России 1773–1775 годов. Восстание Пугачёва. Т. II / отв. ред. В.В. Мавродин. Л.: Изд-во ЛГУ, 1966. 512 с.

*Марджани Шигабутдин.* Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казань ва Булгар: (Источники по истории Казани и Булгара) / Шигабутдин Марджани; [Вступ. ст. Я.Г. Абдуллина, А.Н. Хайруллина, с. 5–37]; АН СССР, Казан. фил., Ин-т яз., лит. и истории им. Г. Ибрагимова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 414 б.

*Пушкин А.С.* Полное собрание сочинений, 1837–1937: в 16 т. Т. IX: История Пугачева. М.; Л. 1940.

*Рәхимкулова М., Хәмидуллин Л.* «Хөсәения» мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. Казан, 1992. Б. 78–79.

*Рычков П.И.* Топография Оренбургской губернии. Уфа: Китап, 1999. 312 с.: ил.



***Усманов Венер Мөдәррис улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 561.23

***С.Ф. Шәйхелова,***
***Г.Ф. Фахруллина,***
***Л.Р. Нигәмәтҗанова,***
***Р.Ф. Фахруллин***

# КАРАМАЙ ТАРКАТУЧЫ *ALCANIVORAX BORKUMENSIS* БАКТЕРИЯЛӘРЕ ҺӘМ *TURBATRIX ACETI* СУАЛЧАННАРЫНЫҢ «ХУҖА – МИКРОФЛОРА» СИСТЕМАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Разливы нефтепродуктов представляют серьёзную экологическую угрозу для водных и наземных экосистем. Биоремедиация, основанная на использовании нефтеразлагающих бактерий, является многообещающим способом очистки почв, загрязнённых углеводородами нефти. Было обнаружено, что свободноживущие нематоды *Turbatrix aceti* выживают в среде с сырой нефтью без бактериальной пищи, хотя развитие животных замедляется на 48 часов. В организме нематод нефть локализуется исключительно в кишечнике, не оказывая негативное воздействие на процесс дефекации. В роли колонизаторов кишечника нематод выступали углеводородокисляющие бактерии *Alcanivorax borkumensis.* Бактерии-нефтедеструкторы эффективно колонизируют кишечник, и нематоды демонстрируют те же показатели развития и фертильности, что и нематоды, которых культивировали с использованием стандартной бактериальной пищи *Escherichia coli*. Эффективность колонизации *A. borkumensis* (23 КОЕ/нематода) была почти в три раза выше, чем для *E. coli* (23 КОЕ/нематода). Важно отметить, что плодовитость нематод *T. aceti*, которые питались бактериями *A. borkumensis*, была почти такой же, как и у животных, которых кормили E. coli (~ 15 яиц/нематода). Вероятно, что нефтеокисляющие бактерии, колонизирующие кишечник, способствуют разложению проглоченной нефти, тем самым повышая шансы нематод на выживание в неблагоприятных условиях окружающей среды. Искусственная колонизация нематод *Turbatrix aceti* углеводородокисляющими микроорганизмами будет способствовать распространению бактерий в контаминированных нефтью почвах, что в свою очередь может стать потенциальным способом ликвидации разливов нефти.

**Ключевые слова**: бактерии-нефтедеструкторы, *Alcanivorax borkumensis*, нематоды, *Turbatrix aceti*, хозяин-микрофлора, биоремедиация.

The environmental hazards of oil spills are among the most serious environmental threats. Bioremediation based on using oil-degrading bacteria is a promising approach to tackle oil spills in soil. We found that *Turbatrix aceti* survive on pure crude oil diet, although the development of the animals is retarded for 48 h. Oil was detected exclusively within the intestines, without any adverse effects of defecation. We used of *Alcanivorax borkumensis* hydrocarbonoclastic bacteria for colonisation of *T. aceti* nematodes intestines.

Oil-degrading bacteria effectively colonise the intestines of the nematodes, which demonstrate the same development and fertility rates, as those fed with Escherichia

coli, a normal bacterial food. Colonisation efficiency for *A. borkumensis* (23 CFU per worm) was almost three times higher that for *E. coli* (23 CFU per worm). Importantly, the fertility in the T. aceti worms fed with *A. borkumensis* was nearly the same as in animals fed with *E. coli (~ 15 eggs per worm).* It is likely that the hydrocarbonoclastic bacteria colonising the intestines facilitate the ingested oil degradation, thus providing the nematodes better chances to survive in harsh environment. Artificial colonisation of *Turbatrix aceti* nematodes with oil-degrading microorganisms will promote microbial distribution in contaminated soils, thus finding potential applications for oil spills remediation.

**Keywords**: oil-degrading bacteria, *Alcanivorax borkumensis*, nematodes, *Turbatrix aceti*, host-microflora, bioremediation

Карамай зур әһәмияткә ия чимал һәм энергия чыганагы булуы белән беррәттән, әйләнә-тирә һәм андагы тереклек ияләренә куркыныч та тудыра. Туфрак тирәлеге карамай һәм карамай продуктлары белән пычранган вакытта, табигый биоценозлар бозыла, туфракның агрохимик һәм агрофизик үзлекләре начарая, шулай ук аның микробиологик сыйфатнамәләре дә үзгәрә. Моннан тыш, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең уңышы да кими, чөнки туфрак пычрануларны җыеп, сеңдереп барырга сәләтле [Третьякова, 2018].

Карамай һәм карамай продуктлары белән пычранган тирәлекләрне физик һәм химик ысуллар ярдәмендә чистарту бик күп этаплардан тора, андый ысулларның чыгымнары да шактый югары була. Шуңа күрә бу очракта биологик чистартуның биотехнология ысуллары иң өметле ысуллардан санала. Әлеге ысуллар бердәнбер энергия чыганагы буларак һидрокарбоннарны кулланучы микробларның актив катнашуына нигезләнгән. *Alcanivorax borkumensis* исемле бактерияләр һидрокарбоннарны таркатучы микробларның әһәмиятле төркемен тәшкил итәләр. Карамай белән пычранган диңгез тирәлекләрендә әлеге бактерияләр иң күп күләмдә очрыйлар [Golyshin *et al.,* 2003].

Бүгенге көндә карамай белән пычранган тирәлекләрне биоремедиацияләүне тагын да нәтиҗәлерәк итү максатыннан, карамай таркатырга сәләтле микроблар һәм азык чылбырында югарырак урынны алып торучы организмнан торган өлге системалар булдырыла [Cuny *et al.,* 2007]. Бу очракта суалчаннар нәкъ шушы организм сыйфатында кулланыла ала: беренчедән, алар карамай белән пычранган тирәлектәге микробларның үрчүенә булышлык итә, икенчедән, суалчаннар туфрак тирәлегенә хас булган микроб берләшмәләренең төрлелеген көйләүдә зур әһәмияткә ия [Zhou *et al.,* 2019]. Югарыда тасвирланган өлге система әйләнә-тирәне торгызу барышын тизләтүче биотехнология стратегиясенә әйләнергә мөмкин. Тәҗрибәләр барышында кулланылган *A. borkumensis* диңгез бактерияләре һәм туфракта тереклек итүче *Turbatrix aceti* суалчаннары арасындагы табигый булмаган бәйләнеш моңа кадәр өйрәнелмәгән иде, шуңа күрә әлеге фәнни эшнең максаты булып *A. borkumensis* бактерияләренең *T. aceti* суалчаннарының физиологиясенә

ясаган тәэсирен «хуҗа – микрофлора» системасы нигезендә өйрәнү билгеләнде.

Яшьләре бертөрле булган суалчаннарны үрчетү түбәндәгечә башкарылды: бер төркем суалчаннар, азык чыганагы сыйфатында *A. borkumensis* бактерияләрен кулланып, – *Nematode Growth Medium* туклыклы тирәлегендә, (1 нче номерлы тирәлек), икенче төркем – карамайлы тирәлектә (2 нче номерлы тирәлек), өченче төркем суалчаннар карамай таркатырга сәләтле бактерияләр кушылган карамайлы тирәлектә (3 нче номерлы тирәлек) үрчетелделәр (1 нче рәсем).




1 нче рәсем. Өч төрле тирәлектә үрчетелгән суалчаннарның оптик микросурәтләре:
а) *A. borkumensis* бактерияләре кушылган тирәлек (№ 1),
б) бактерияләрсез карамайлы тирәлек (№ 2),
в) *A. borkumensis* бактерияләре кушылган карамайлы тирәлек (№ 3)

Суалчаннарның тирә-юньдәге химик сигналларны сизеп, аларга карата гади хемосизгер нейроннар системасы аша тормышка ашырылучы хемотаксислы үзтотышлары барлыгы билгеле [Hu *et al.*, 2015]. Алар хемотаксисны, ягъни химик ярсыткыч тәэсирендә башкарылучы юнәлешле хәрәкәтне парларын, шулай ук бактерияләр җыелмасын эзләгәндә дә кулланалар. Хемотаксис нәтиҗәләре буенча *A. borkumensis* бактерияләренең *T. aceti* суалчаннары өчен репеллент булмавы, һәм әлеге суалчаннарның контроль бактерияләргә дә (*Escherichia coli,* 52%), тәҗрибәи бактерияләргә карата да (48%) якынча бертөрле илтифат итүләре ачыкланды. Өстәмә рәвештә хемотаксис индексын санау да башкарылды. Тикшеренү барышында алынган хемотаксис индексы (-0,2) суалчаннарның ике төр бактериягә карата да бертөсле илтифат итүен раслый. Димәк, суалчаннар *A. borkumensis* бактерияләреннән качмыйлар, һәм тирәлектә бирелгән бактерияләр генә булган очракта, суалчаннар актив рәвештә әлеге бактерияләр белән тукланачаклар.

*T. aceti* суалчаннарын бактерияләрсез карамайлы тирәлектә үрчеткән вакытта (2 нче рәсем) суалчаннарның өлкән чорга җитә алмаулары яисә альтернатив дауэр корты чорына күчүләре күзәтелде (дауэр корты чоры суалчаннарга тирә-юньдәге уңайсыз шартларны кичерергә ярдәм итә). Карамайлы тирәлектә суалчаннарның үрчүе 48 сәгатькә кимесә дә, әлеге суалчаннар, барлык корт чорларын узып, үрчетүнең алтынчы көненә өлгереп, йөкле чорга җиттеләр. Димәк, суалчаннар үрчү өчен мөһим барлык кирәкле матдәләрне дә ала алганнар дигән сүз.




2 нче рәсем. 72 сәгать дәвамында бактериялрсез карамайлы тирәлектә үрчетелгән *T. aceti* суалчанының а) караңгы кыр һәм б) оптик микросурәте

*A. borkumensis* бактерияләре кушылган карамайлы тирәлектә суалчаннар 96 сәгать эчендә өлгерәләр (*A. borkumensis* бактерияләре баетылган стандарт туклыклы тирәлектә дә шулай ук). *A. borkumensis* бактерияләре белән үрчетү, *E. coli* бактерияләре белән үрчетү төсле үк (бер суалчанга 15 ± 4 йомырка туры килә), суалчаннарның үрчемлелегенә тәэсир итми (бер суалчанга 14 ± 3 йомырка туры килә, 3 нче рәсем).




3 нче рәсем. а) *E. coli* яисә б) *A. borkumensis* бактерияләре белән тукланган *T. aceti* суалчаннарының аналыкларындагы йомыркалар; в) өч көн дәвамында *E. coli* яисә *A. borkumensis* бактерияләре белән тукланган суалчаннарда йомыркаларның бүленеше

Тикшеренү барышында суалчаннар эчәклегенең бактериаль колонизациясен бәяләү буенча тәҗрибәләр дә уздырылды. Йоткылыкның терминаль бүлбүсендә урнашкан ваклаучы аппарат гадәттә бактерияләрне таркатып бетерә [Cho, Bandyopadhyay, 2012]. L1 чорында булган суалчаннар 72 сәгать дәвамында *E. coli* бактерияләре белән тукланган вакытта, суалчаннарның эчәклегендә таркатылмаган бактерияләр күзәтелмәде. Хәлбуки *A. borkumensis* белән тукланганнан соң, суалчаннарның ашкайнату тракты бактерияләр белән тулы булуы ачыкланды (4 нче рәсем).




4 нче рәсем. 72 сәгать дәвамында бактерияләр белән тукланган суалчаннарның эчәклек колонизациясен үз эченә алган микросурәтләр (А – *E. coli*, Б – *A. borkumensis*). Бактерияләр CFSE (карбоксифлуоресцеин сукцинимидиллы эфир) флуоресцент буягычы белән билгеләнгәннәр

Эчәклек колонизациясе һәм суалчаннарның үлеме арасында бәйләнеш булуга карамастан, әлеге күрсәткечләр һәрвакытта да суалчаннарның үлеменә китерми. Мәсәлән, *Enterococcus faecium* бактерияләре дә эчәклектә күп күләмдә тупланырга мөмкин, әмма бу вакытта өлгергән суалчаннар үлми, кабатланып торучы инфекция барышы да күзәтелми [Garsin *et al*., 2001].

Тикшеренү барышында күзәтелгән карамай таркатучы бактерияләрнең туплану күренеше даими түгел: *T. aceti* суалчаннарын *E. coli* бактерияләре белән азыкландырган вакытта, *A. borkumensis* бактерияләре ашкайнату тракты буйлап узып, бер сәгать эчендә тышкы тирәлеккә чыгарылалар. Эчәклек колонизациясенең дәрәҗәсен билгеләү өчен исә *T. aceti* эчәклегеннән алынган *E. coli* һәм *A. borkumensis* бактерияләренең колония барлыкка китерүче берәмлекләре (КББ; рус. КОЕ – колониеобразующая единица) саналды (5 нче рәсем).



5 нче рәсем. Суалчаннарның эчәклегендә *E. coli* (а) һәм *A. borkumensis* (б) бактерияләренең тупланышы

*E. coli* белән тукланган суалчаннарның эчәклегеннән алынган бактерия популяцияләренең күләме күп түгел (бер суалчанга 8 КББ туры килә). Бу күрсәткеч бактерияләрнең күп өлеше эчәклектә ашкайнатылып бетүен раслый. *A. borkumensis* бактерияләре белән үрчетелгән суалчаннарда ашкайнатылмаган бактерияләр саны күбрәк (бер суалчанга 23 КББ туры килә), бу исә суалчаннар эчәклегенең колонизацияләнүен күрсәтә, шулай итеп, *A. borkumensis* белән тукланган суалчаннарда билгеләнгән КББ саны *E. coli* кушылган тирәлектә үрчетелгән суалчаннарныкына караганда 2,9 тапкыр күбрәк.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: *A. borkumensis* бактерияләре белән тукланган суалчаннарның дефекация (эчәклектәге азык калдыкларын чыгару) барышы бозылмавы ачыкланды. Бу үз чиратында карамай таркатырга сәләтле бактерияләрне тирәлек буйлап таратуда югары нәтиҗәгә ия булырга мөмкин: суалчаннар тирәлек буйлап һәрдаим хәрәкәт итеп торалар, эшкәртелмәгән, үрчергә сәләтле бактерияләр дә тарала бара, бу исә биоремедиация барышын тагын да тизрәк һәм нәтиҗәлерәк итәргә мөмкин. Димәк, бик югары булмаган эчәклек колонизациясенә карамастан, дефекация барышының бозылмавы эшкәртелмәгән бактерияләрнең тышкы тирәлеккә чыга алуы күрсәткече булып тора.

Шулай итеп, *A. borkumensis* бактерияләренең эчәклек микрофлорасына ярашуын тикшерү нәтиҗәсендә, карамай таркатучы

*A. borkumensis* бактерияләренең *T. aceti* суалчаннары тарафыннан бердәнбер азык чыганагы буларак үзләштерелә алуы һәм әлеге бактерияләрнең суалчаннарның физиологиясенә зарар китермәве ачыкланды. *T. aceti* суалчаннары һәм *A. borkumensis* бактерияләренең «хуҗа – микрофлора» системасындагы үзара мөнәсәбәтләрен тикшерү барышында алынган нәтиҗәләр карамай белән пычранган тирәлекләрне чистартуга юнәлтелгән системалар булдыру һәм аларның нәтиҗәсен арттыру өчен нигез булып тора.

**Әдәбият**

*Третьякова М. С.* Перспективы использования эндо- и ризосферных микроорганизмов для восстановления загрязненных нефтью почв // дис. … канд. биол. наук: 03.02.08. Иркут. гос. ун-т. Иркутск. 2018. С. 121.

*Cho J. H., Bandyopadhyay J.* Animal Models for *Salmonella* pathogenesis: studies on the virulence properties using *Caenorhabditis elegans* as a model host // Salmonella. A Diversified Superbug / ed. by Y. Kumar. 2012. P. 434–448.

*Cuny P., Miralles G., Cornet-Barthaux V., Acquaviva M., Stora G., Grossi V., Gilbert F.* Influence of bioturbation by the polychaete *Nereis diversicolor* on the structure of bacterial communities in oil contaminated coastal sediments // MarPollutBull. 2007. V. 54. P. 452–459.

*Garsin D.A., Sifri D.S.D., Mylonakis E., Qin X., Singh K.V., Murray B.E., Calderwood S. B., Ausubel F. M.* A simple model host for identifying Gram-positive virulence factors // Proc Natl Acad Sci U S A. 2001. V. 9. P. 10892–10897.

*Golyshin P.V. A. Martins Dos Santos , Kaiser O., Ferrer M., Sabirova Y., Lünsdorf H., Chernikova T., Golyshina O., Yakimov M., Pühler A., Timmis K.* Genome sequence completed of *Alcanivorax borkumensis*, a hydrocarbon-degrading bacterium that plays a global role in oil removal from marine system // J Biotechnol. 2003. V. 106. P. 215–220.

*Hu L., Ye J., Tan H., Ge A., Tang L., Feng X., Du W., Liu B.* Quantitative analysis of *Caenorhabditis elegans* chemotaxis using a microfluidic device // Anal. Chim. Acta. 2015. V. 887. P. 155–162.

*Zhou J., Chen D., Huang R., Huang G., Yuan Y., Fan H.* Effects of bacterial-feeding nematodes on soil microbial activity and the microbial community in oil-contaminated soil // J Environ Manage. 2019. V. 234. P. 424–430.

*Тикшеренү эше Россия Федерациясе президентының фәннәр докторы булган яшь галимнәргә булышлык итүгә юнәлтелгән МД-2153.2020.3 номерлы гранты ярдәмендә тормышка ашырылды*

***Фахруллин Равил Фәрид улы,***
*биология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Фундаменталь медицина һәм биология институты баш гыйльми хезмәткәре*

***Шәйхелова Сәрбиназ Фәнис кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты бакалавры, Фундаменталь медицина һәм биология институты лаборанты*

***Фахруллина Гөлнур Илдар кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты аспиранты, Фундаменталь медицина һәм биология институты гыйльми хезмәткәре*

***Нигъмәтҗанова Ләйсән Рәфис кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты, Фундаменталь медицина һәм биология институты гыйльми хезмәткәре*

УДК 801.82

*Мостафа Чокай углы*

## «МИЛЛИ ЮЛ»

Статья под таким названием была напечатана на французском языке на страницах журнала «Promethee» («Прометей») № 35 за 1929 год, издаваемого в Париже с 1926 по 1938 год. Автор статьи – известный общественный и политический деятель Казахстана, юрист, журналист, член организации «Прометей» Мустафа Чокайоглы (Чокаев, 1890 – 1941). Данная статья посвящена выходу в свет журнала «Милли юл» («Национальный путь»), главным редактором и основным автором которого являлся выдающийся татарский писатель, общественный деятель, драматург, публицист Гаяз Исхаки (1878 – 1954).
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, М. Чокайоглы, М. Худяков, «Идель-Урал», «Милли юл», «Кызыл Татарстан».

An article under this title was published in French on the pages of the «Promethee» magazine (Prometheus) No. 35 for 1929, published in Paris from 1926 to 1938. The author of the article is a well-known public and political figure of Kazakhstan, a lawyer, a journalist, a member of the «Prometheus» organization Mustafa Chokayogly (Chokaev, 1890 – 1941). This article is devoted to the publication of the magazine «Milli Yul» («The National Way»), whose editor-in-chief and main author was an outstanding Tatar writer, public figure, playwright, and publicist Gayaz Iskhaki (1878 – 1954).
**Keywords:** G. Iskhaki, M. Chokayoglu, M. Khudyakov, Idel-Ural, Milli Yul, Kyzyl Tatarstan.

Нәкъ менә шушы атама белән ел ахырыннан башлап Берлинда айга ике тапкыр татар телендә басма чыга башлый (Казан татарлары телендә). Әлеге журнал «Идел-Урал» сәяси оешмасы органы булып тора. Аның максаты – Идел буе һәм Урал төбәгендә яшәүче төрки-татар халыкларының милли бәйсезлек көрәшен дәвам иттерү. Кызыклы мәкаләләр сериясендә татарларның күренекле лидеры, язучы һәм драматург Гаяз Исхакый-бәй Идел буе татарларының соңгы илле елда милли бәйсезлек һәм сәяси хокуклары өчен көрәшен тасвирлый[1]. Башка мәкаләләр Россия, Украина, Кавказ, Кырым һәм Төркестан арасындагы мөнәсәбәтләр тарихына багышлана. Бу мәкаләләрдә әллә ни яңалык булмаса да, мәгълүматны тәкъдим итү, аны тыгыз формада укучыга җиткерү язмаларга игътибарны җәлеп итә һәм яңа дәлилләр ышанычлырак яңгырый. Без үз-үзебезгә каршы киләчәкбез, әгәр бу мәкаләләрне Гаяз Исхакый-бәйнең иң яхшы әсәрләреннән санамасак.

Казан татарлары өчен Октябрь революциясенең иң билгеле җиңүләре арасында, һичшиксез, милли әдәбиятның стиль һәм телен бозу тора. Безгә рус һәм татар сүзләре чиратлаштырылып бастырылган татар газеталарындагы мәкаләләр һәм фельетоннар белән

танышырга мөмкинчелек туды. Мәскәүлеләрнең кызыл лагерена күчеп, чамалы гына укый-яза белгән яисә бөтенләй белемсез татар большевиклары милли хәзинәләргә карата белдерелгән битарафлыкта үзенә күрә бер «революцион шок»ны күрәләр. Шулай да соңрак революция алдыннан милли әдәбиятның матурлыгын сиземли башлаган шул ук татар яшьләре арасында телне бозуга каршы протест белдерүгә теләктәшлек күрсәтүләре күзәтелә. Шуңа да Мәскәүгә буйсынуда Гаяз Исхакый-бәй исеме татарларны вәсвәвәгә сала. Татарстан Совет автономияле республикасында «Милли юл»ның барлыкка килүе нинди кызыксыну һәм, шуннан чыгып, яшерен шатлык уятуын аңлар өчен, Казанда чыгып килгән «Кызыл Татарстан» газетасының быелгы 22–24 май саннары белән танышып чыгу да җитә кала: «Гаяз журнал чыгара икән, дигәч, кайберәүләрнең әдәби нәрсәләр яза торгандыр дип уйлаулары ихтимал, – дип яза "Кызыл Татарстан", – безнең татарлар, һичшиксез, басма битләрендә әлеге күренекле язучының әдәби әсәрен күрергә өметләнгәндер». Һичшиксез, Гаяз Исхакый-бәй тарафыннан бастырылган сәяси темалар һәм сәяси мәсьәләләрнең чишелеше «Кызыл Татарстан» редакциясендә шатлык хисе уятмый. Әлбәттә, большевиклар газетасына язылучылардан тыш башка укучылар да бар. Мәскәүгә каршы тенденцияләрнең үсеше белән сугарылган тирән милләтчелек хисе, ерак һәм якын тарихка карата үсә барган мәхәббәт хисе белән берлектә, ниһаять, Исхакый-бәйнең каләме белән язылган «Милли юл»ның «контрреволюцион» мәкаләләре ихлас укучысын тапмый калмый. Әлеге мәкаләләрдә, сәяси темалардан тыш, пролетар әдәбияты исеме астында урнаштырылган һәртөрле чүп-чардан кала, татар укучысы туган теленең сафлыгын һәм тәмен тоя ала.

* * *

Казан татарлары тарихында рус дәүләтенә буйсынып яшәү дәвере кайгылы чор буларак билгеле. «Җирле халык» татарлар башкаларга караганда күбрәк Мәскәү империализмына буйсынып яшәргә мәҗбүр ителә. Әлеге мәкалә кысалары миңа русларның татарлардан өстенлек итү мәсьәләсенә тукталырга мөмкинчелек бирми. Әлбәттә, шаккатырлык империализм һәм милли төшенкелек чагылышы булып халыкны үз милли территориясеннән куып чыгару тора. Империализмның әлеге рәхимсез ягын бигрәк тә Казан татарлары тоялар. Һәм Россия үз планын тулаем тормышка ашыра алмаган икән, димәк татарлар тарафыннан көчле каршылык күрсәтелгән...

М. Худяковның 1923 елда Казанда басылып чыккан «Очерки по истории Казанского ханства» китабында түбәндәгеләр язылган: 1 б.: «Хәзерге заман картасын борынгы авыл урыннары белән чагыштырып карасак, күрәбез: 1) татарлар Казан тирәсендәге территорияне югалталар, бередән алар рус колонизациясенең көчле ташкыны белән кысрыклап чыгарыла; хәзерге вакытта Казанга 45 чакрым якынлыкта урнашкан татар авыллары юк, шуңа да карамастан, рус авыл һәм

салаларының атамаларында татар сүзләре еш очрый; борынгы Болгар территориясе – кара туфраклы Спасс өязе дә бушап кала, бирегә дә рус күченеп килүчеләре дулкыны бәреп керә; мөселманнар шулай ук ханлыкның көнбатыш чикләреннән – Сура һәм Зөя елгасы арасындагы территорияләрдән дә кысрыклап чыгарыла».

Биредә без М. Худяков әфәнденең китабыннан кыска, ләкин шул ук вакытта Россиядәге колониаль сәясәтнең ничек барганын күрсәтү максатыннан гыйбрәтле цитатаны китердек. Үз милли дәүләтенең башкаласыннан 45 чакрым ераклыкка репрессияләнгән халыкның газапларын күз алдына китерү авыр түгел...

Спасс өязен алсак, М. Худяков әфәнденең аңлатмасында ул кайчандыр «татар территориясенең үзәге» булып та татар халкы тарафыннан тулаем ташланган, дип аңлатыла.

Татарларга карата алып барылган Россия сәясәтенең икенче ягы да бар. Без аны Гаяз Исхакый-бәйнең Варшава «Прометей» клубында укылган «Идел-Урал республикасының сәяси көрәш тарихына күзәтү» дип исемләнгән кызыклы хисабында табабыз:

«Дәүләт белән идарә итүдә техник әзерлек турында сүз алып барсак, аның революциягә кадәр тиешле дәрәҗәдә булмавын танырга тиешбез. Россия хөкүмәте төрки-татар халыкларын илнең идарә итү эшләреннән тыеп килә; һәм җирле идарә органнарында аларның саны бик аз, 1/5 нән дә азрагын тәшкил итә».

Татарларның рус дәүләте эчендә өч гасыр ярым яшәвен исәпкә алсак, әлеге «аларның техник әзерлеге тиешле дәрәҗәдә булмавы» гыйбарәсенең ни чаклы трагик яңгыравын аңлавы авыр түгел.

Җирне тартып алу һәм халыкны дәүләт төзүдән мәхрүм итү Идел буе төрки-татарларына гына түгел, хәтта Кавказ һәм Төркестан халыкларына карата алып барылган сәясәтнең иң табигый алымнары булып тора. Әлеге мөнәсәбәт аталып киткән халыкларның сәяси бәйсезлек өчен алып барган көрәшенә барып тоташа.

Революциянең азатлык алып килү принципларына тулаем ышанып, 1917 елның революцион март ае дәвамында татар сәясәтчеләренең күбесе үз таләпләрен бары тик милли-мәдәни автономия белән чиклиләр. Бу, әлбәттә, Керенский хакимияте бәреп төшерелгәннән соң табигый күренә, һәм милли парламент Уфага чакыртыла.

Милли-мәдәни автономия төзү өчен кирәкле реформаларны тормышка ашыру белән беррәттән, татар сәясәтчеләре алга таба Россиянең тигез хокуклы бер өлеше булган Идел-Урал штатын булдыру максатыннан, Учредительное собрание чакырылышын әзерләү буенча эш алып баралар. Шуннан соң ике проект тәкъдим ителә: аларның беренчесе элеккеге төрки-татарлар яшәгән территорияне нигез итеп алса, ягъни Сура елгасыннан алып Идел һәм Урал буендагы аралык, Түбән Новгород, Әстерхан һәм Каспий буйлары, икенчесе исә фактик яктан татарлар күпләп яшәгән территорияне берләштерүне күздә тота, ягъни бирегә Самара, Сарытау һәм Әстерхан керми. Икенче проектта

Идел-Урал штатына Казан, Уфа, Оренбург һәм өлешчә Пермь һәм Нократ өязләре кертелә.

Шул арада Октябрь революциясе башлана һәм бөтен проектлар, шул исәптән татар милли парламенты да, большевизмның «азатлык һөҗүме» тарафыннан юкка чыгарыла...

Шул рәвешле совет хакимияте Идел-Урал дәүләте идеясен җимерә һәм «совет автономияле республикаларын» барлыкка китерә. 1919 елның 20 мартында Указ белән башкортларның автономияле республикасы; 1920 елның 25 июнендә халкы 2 812 000 кешедән торган Татар Совет Автономияле Республикасы төзелә. Әлеге республикалар турында язганда, Гаяз Исхакый-бәй алда аталып үткән докладта түбәндәгеләрне яза:

«Әлеге “милли республикалар” территориаль яктан шулай төзелә ки, алардагы төрки-татар халкының яртысыннан артыграгы читтә урнашкан була. Моннан да бигрәк, татарлар Татарстан Республикасында төп халыкның 51% ын тәшкил итсәләр дә, әлеге 51% Идел буенда яшәүче татар халкының бары тик якынча 35% ыннан тора. Татарлар белән бүгенге хәл менә шулайрак.

Берничә ел дәвамында эчке яктан әзерлек кичергәннән соң, Идел-Урал сәяси оешмасы янәдән барлыкка китерелә. Татар халкының эчке көчләре белән тыгыз элемтәдә торган элеккеге конституция проекты әлеге оешмада яңадан күтәрелә. Ул инде элекке Россия эчендәге дәүләт түгел, ә мөстәкыйль сәяси берәмлек буларак оеша.

Редактор искәрмәсе. «Promethee» редакциясе «Милли юл» басмасына үзенең иң ихлас котлауларын җиткерә һәм төрки-татарларга Мәскәү золымыннан котылу көрәшендә һәртөрле уңышлар тели.

**Искәрмәләр**

[1] Мәҗмуганың икенче директоры, ягъни аны җитәкләп барган кеше – доктор Ләбиб *(М. Чокай углы искәрмәсе).* Доктор Ләбиб Каран (1887 – 1964) – җәмәгать эшлеклесе, галим, табиб. Берара «Милли юл» журналының Берлиндагы идарәсен җитәкли.

*Мәкалә басмага Татарстан Республикасы яшьләр гранты кысаларында әзерләнде. Проект номеры: 17-100-ч Г 2019.*

*Текстны басмага әзерләүче, искәрмәне язучы*
***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## «МИРГАЗИЗ УКМАСЫЙ. ӘСӘРЛӘР, МӘКАЛӘЛӘР, ИСТӘЛЕКЛӘР» (ТӨЗҮЧЕ З. РӘМИЕВ) КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

Татар әдәбиятында, узган гасырның 20–30 нчы еллар сәясәте нигезендә рәхимсез репрессия корбаннары булып, иҗатлары читтә кала килгән шәхесләребезнең исемнәрен кайтару, әсәрләрен дөньяга чыгару, иҗатларын өйрәнү эше бүгенге көнгә кадәр актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала килә. Туксанынчы елларда башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, хаксызга гаепләнгән әдипләребезне өйрәнү эшендә күпмедер дәрәҗәдә алга китеш булса да, бу өлкәдә эшләүче галимнәр бик аз булу сәбәплеме, татар әдәбиятында өйрәнүчеләрен көтеп ятучы язучылар әле шактый. Шуларның берсе – Миргазиз Укмасый иде...

Ниһаять, безнең кулыбызга бу күренекле татар шагыйренең иҗат мирасын туплаган саллы китап килеп керде. Ул «Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» дип исемләнгән. Аны дөньяга чыгаручы – филология фәннәре докторы, профессор, тәҗрибәле әдәбиятчы-текстолог Зөфәр Рәмиев. Китап – шагыйрь М. Укмасыйның (1884–1948) иҗат мирасын тулаем колачлаган беренче җыентык. Кызганычка каршы, XX гасыр башында классик әдипләребез Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев Н. Думави һ.б. белән беррәттән иҗат иткән, татар поэзиясе яңарышы юлында сизелерлек роль уйнаган бу шагыйрьнең шигъри мирасы, хикәя һәм мәкаләләре, истәлек язмалары игътибардан читтә калып килде. Әлегә кадәр укучы шагыйрьнең аерым әсәрләре белән 1958 елда М. Гайнуллинның «Миргазиз Укмасый» исемле кереш сүзе белән дә әзерләнгән «Сайланма әсәрләре»е (51 шигыре, 2 истәлек), 1956 елда басылып чыккан «Татар поэзиясе антологиясе»(12 шигырь), 2004 елда дөнья күргән «Татар шигърияте: XX гасыр башы»(16 шигырь) аша гына таныша ала алды. Бу иҗатның татар әдәбияты тарихындагы урынын ачыклау юнәлешендә дә әлләни җитди эшләр күренми әлегә. Сигез томлы татар әдәбиятының соңгы елларда гына чыккан 4 нче томында да (2016) аның исеме берничә урында гына телгә алынган. Ә инде XX гасыр башы поэзиясен махсус тикшергән бүлектә М. Укмасый дигән шагыйрь язганнарга таянып бер генә фикер дә әйтелми.

Шагыйрьнең аеруча актив иҗат иткән вакыты революциягә кадәрге чорга, төгәлрәк әйтсәк, 1904–1913 елларга туры килә. «Алданма кызыл алмага» (1907; 1910), «Миргазиз Укмасый шигырьләре (1909), «Өмид йолдызым (1912) исемле шигъри җыентыклары да дөнья күргән. М. Укмасый заманында татар вакытлы матбугатында да актив язышкан. Мәсләкләре җәһәтеннән бер-берсеннән шактый гына аерылып торган татар газета-журналларыннан «Казан мөхбире», «Азат», «Бәянелхак», «Әлислах», «Әхбар», «Йолдыз», «Сүз», «Идел», «Яшен», «Сөембикә»ләрдә әсәрләре әледән-әле чыгып торган. Күбесе – шигъри әсәрләр. Аларда автор күбесенчә татар халкының яңа вазгыятьтә үз урынын табарга, мәгърифәтле булырга, милли йөзебезне югалтмаска, тарихтан гыйбрәт алып иҗтиһад итәргә чакыра. Ул прозаик буларак та

чыгыш ясаган. Аның «Зыя», «Ачлык берлә катнашкан хәсрәтләр, яки Зөһрә туташ» хикәяләре хәзерге укучы өчен дә кызыклы.

М. Укмасый совет чорында да иҗат эшеннән читләшмәгән. Әмма ул елларда хөкем сөргән сәясәт аны да урап узмаган. Батрак тоткан, революциягә кадәр жандармнарга революционерларны саткан, М. Солтангалиев белән дә бәйләнештә булган, башка имеш-мимешләргә таянып аны кулга алганнар һәм сигез елга концлагерьга ябарга дигән карар чыгарганнар (бераз вакыттан шартлы хөкем белән алмаштырылган). М. Укмасый 1948 елда картлар йортында вафат була.

Билгеле ки, язучының язма мирасы гарәп графикасында басылган материаллардан гыйбарәт (автографлы кулъязмалары сакланмаган диярлек). Димәк, кириллица белән генә эш йөрткән бүгенге укучы алар белән таныша алмый. Шуңа күрә дә язучыларыбызның иҗатларын барлаучы, ягъни төрле китапханәләрдә таралып яткан газета-журналлардан, архивлардан эзләп табып, әсәрләренең текстларын укучы аңларлык рәвешкә китереп, очраган гарәп-фарсы алынмаларының сүзлекләрен төзеп, укучыга тәкъдим итү зур җаваплылык сорый. Әйтергә кирәк, китапны төзүче З. Рәмиев бу эшкә бик җитди караган. Кыскасы, «Миргазиз Укмасый. Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» җыентыгы барлык текстологик таләпләргә туры китерелеп, фәнни басма буларак төзелгән.

Китап төзүченең «Мәгърифәтчел шигърият иясе, Тукайлар замандашы» исемле саллы гына кереш мәкаләсе белән ачыла. Анда З. Рәмиев М. Укмасый иҗатының өйрәнелү торышын яктырта, биографиясен, әсәрләренең тематикасын ачыклап, иҗатына кыскача бәя дә бирергә омтыла. Мәкалә авторы Дәүләт иминлеге комитеты архивларында эзләнүләр алып барып, тормыш юлына караган кайбер моментларны киңрәк ачу ягыннан күзәтүләре белән дә таныштыра.

Әсәрләр жанр ягыннан аерым бүлекләргә бүленеп, хронологик тәртиптә урнаштырылган: 1) шигъри әсәрләр (167 шигырь); 2) хикәяләр (3 хикәя); 3) мәкаләләр (6 мәкалә); 4) «Көйләр тарихы вә җырлар» (4 көйнең тарихы китерелә); 5) Истәлекләр (6 истәлек һәм 1 хат). Әлеге бүлектә М. Укмасыйның алты язмасы урнаштырылган. Аларда авторның К. Насыйри, Г. Тукай, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, М. Гафури белән очрашулары яктыртыла. Китапның ахырындагы «Искәрмәләр һәм аңлатмалар»да һәр текстның чыганагы, имзасы күрсәтелгән, басылу тарихына караган кыскача мәгълүмат китерелгән.

XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкиле Миргазиз Укмасыйның иҗат мирасын туплаган әлеге китап татар дөньясында күптән көтелгән хезмәт иде. Киләчәктә язучының иҗатын нәзари яктан җентекләп өйрәнүче галимнәр дә табылыр, аның иҗаты татар әдәбияты тарихын чагылдырган фәнни хезмәтләрдә үзенә лаек урынны алыр дигән өметтә калабыз.

***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 78.071.2

*А.Р. Салихова*

# ГАЗИЗ ӘЛМӨХӘММӘДОВ ҺӘМ АНЫҢ МИЛЛИ МУЗЫКА СӘНГАТЕН ҮСТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ

Творческая деятельность певца, композитора, фольклориста, педагога и общественного деятеля Газиза Альмухамедова сыграла важную роль в становлении татарского и башкирского музыкального искусства. Его непревзойдённый певческий талант и трепетное отношение к бесценному фольклорному наследию послужили сохранению, изучению и распространению произведений народного музыкального творчества. Газиз Альмухамедов стал одним из авторов первых татарских опер «Сания» и «Эшче». Он принимал самое активное участие в подготовке профессиональных кадров для национального музыкального искусства на этапе его становления.

**Ключевые слова:** Газиз Альмухамедов, певец, композитор, общественный деятель, фольклор, музыка, опера.

The creative activity of the singer, composer, folklorist, teacher and public figure Gaziz Almukhamedov played an important role in the development of Tatar and Bashkir musical art. His unsurpassed singing talent and reverent attitude to the invaluable folklore heritage served to preserve, study and disseminate the works of folk music. Gaziz Almukhamedov became one of the authors of the first Tatar operas «Sania» and «Eshche». He took an active part in training professional personnel for the national musical art at the stage of its formation.

**Key words:** Gaziz Almukhamedov, singer, composer, public figure, folklore, music, opera.

Милли театр һәм музыка сәнгате өлкәсендә тикшеренүләр белән шөгыльләнгәндә, үз эшендә башлап яңалык ачучы күренекле мәдәният эшлеклеләрен, ярсулы энергиясе һәм үз халкына тирән мәхәббәт белән зур казанышларга һәм прогрессив үзгәртеп коруларга этәргән фидакяр затларны һәм энтузиастларны игътибарсыз калдырып булмый. Алар арасында талантлы җырчы, композитор, җәмәгать эшлеклесе Газиз Әлмөхәммәдовның кабатланмас шәхесе аерым урын алып тора. Аңа быел 125 яшь тулган булыр иде.

Газиз Салих улы Әлмөхәммәдов 1895 елда Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе Моратап авылында туган. Ярлы крестьян гаиләсендә төпчек малай булып тугангамы, ул кечкенәдән үк үзе эшләп ашарга өйрәнгән. Кышын, барча яшьтәшләре кебек үк, мәдрәсәдә укыган, ә җәй көне көтү көткән. Шул вакытта ук ул халык көйләренә гашыйк булган, өлкәннәрдән ишеткән борынгы көйләрне сәгатьләр буе курайда уйнап юанган.

1909 елда, Газизгә ундүрт яшь тулгач, олы абыйсы Габдрахман аны үзе белән Ташкентка алып китә: сәүдә эшенә өйрәтмәкче була. Ләкин аннан приказчик чыкмый. Газизнең әнисеннән күчкән

музыкага сәләте бар нәрсәдән өстен чыга һәм аның язмышын бөтенләй үзгәртә дә куя. Ул вакытта Ташкентта татар яшьләре клубы эшләп килә, анда шигъри-музыкаль кичәләр үткәрелә. 1913 елда Газиз Әлмөхәммәдов беренче тапкыр әлеге клуб сәхнәсендә чыгыш ясый, ә бер елдан соң үзен тулысынча концерт эшчәнлегенә багышлый.

Аның ялгыз башкаруга корылган гастрольләре Россия империясенең бөтен территориясен – Урта Азия һәм Себерне, Урал һәм Идел буйларын, Мәскәү һәм башка зур шәһәрләрне колачлый һәм зур уңыш белән бара. Өстәвенә артист халык алдында чыгыш ясау белән генә чикләнми – кайда гына барса да, аның гореф-гадәтләрен өйрәнә, фольклор үрнәкләрен язып ала, акрынлап үзенең репертуарын баетканнан баета һәм төрләндерә. Шуның белән «тамашачыларга яңа заман сулышын тоярга мөмкинлек бирә. Чөнки татар халкының үзаңы уяну процессында сәнгатьнең әһәмияте бермә-бер арта» [Газиев, с. 17].

Егерменче еллар башында Әлмөхәммәдов иң популяр башкаручыларның берсенә әверелә. Ул еллардагы матбугат, җырчының уңыш казануын билгеләп, аның халык җырларына аеруча кайгыртучан мөнәсәбәтен ассызыклый. Ул үз репертуарына татар һәм башкорт фольклорының «энҗеләре» булып саналган әсәрләрне кертә: «Гөлнәзирә», «Сакмар», «Ак каен», «Зөлхиҗә» һ.б. Шул ук вакытта ул аларны ничектер «яхшыртырга» – ритм, сүз, мотивларын үзгәртергә омтылмый. Киресенчә, ул тыңлаучыга борынгы башкару традицияләрен җиткерергә тырыша. 1928 елда «Яңалиф» журналында Сафа Борһан болай дип яза: «СССРда Газиз Әлмөхәммәдовны белмәгән кеше сирәк. Татарлар һәм башкортлар булган барлык шәһәрләрдә аның концертлары зур уңыш белән уза. Мондый уңышның сәбәбе нәрсәдә? Газиз халык җырларын башкару стилен нечкә тоемлый. Ул, күп кенә концерт җырчылары кебек, халык җырларын бозмый һәм «культуралаштырмый». Ул җырлаганда борынгы легенда геройлары күз алдына килә, үзеңнең концерт залында утыруыңны, тәрәзәләр артындагы трамвай һәм машина тавышларын онытасың. Аның тавышына ияреп, уйлар башкорт далаларының зәңгәр офыкларына барып тоташа, биек булып үскән үләннәр чайкалуы күз алдына килә, дала буйлап таралучы курай тавышы ишетелә» [Бурхан, с. 6].

Аның уникаль җырчылык таланты турында хәзерге заман тикшеренүчесе М.И. Идрисова болай дип яза: «Әлмөхәммәдов – тумыштан зур талантка ия башкорт җырчыларының берсе, аңарга, озын көйләрне башкару осталыгына ирешү өчен, табигатьтән барысы да бирелгән: үзәкләргә үтеп керә торган гаҗәеп матур тембр, барлык регистрларда да зур һәм тигез диапазон, сулыш киңлеге, орнамент сәнгатеннән виртуозларча файдалану, форманы эчке тоемлау, искиткеч зәвык. Аның башкаруында озын көй җыр гына түгел, ә фәлсәфи гомумиләштерүләр югарылыгына күтәрелгән вәхи булып яңгырый. Аның җырлавы сокландыра, тетрәндерә. Аның сәнгатенең гипнозлау көче шулкадәр зур ки, кешеләр җырчының теге яки бу шәһәргә килүе

турында ишетеп, аны тагын бер генә тапкыр ишетү өчен дә әллә ничәшәр чакрым араларны үтәләр...» [Идрисова, с. 22].

Газиз Әлмөхәммәдовның беренче композиторлык тәҗрибәләре дә егерменче еллар башына туры килә. Башкортстанга сәфәре вакытында күргәннәреннән (ачлык, җимереклек, халыкның авылы-авылы белән тифтан кырылуы) бик нык тәэсирләнеп, ул, үзенең борчылуларын, кайгылы кичерешләрен бәян итүне сорап, Заһидә Байчуринага мөрәҗәгать итә. «Дәһшәтле җил» вокаль балладасы шул рәвешле туа. Тормыштагы вакыйгаларның берсен дә игътибарсыз калдырмыйча, ул «Маяковский үлеменә» җыр-поэмасын яза (сүзләре үзенеке). Халык арасында аның лирик җырлары бик популяр була – «Көймәләр», «Җырлар язам», «Агыйдел ярында» һ.б.

Беренче татар милли операсын булдыру инициаторы да нәкъ менә Газиз Әлмөхәммәдов үзе була. Җырчыга Гозәир Хаҗибәковның музыкаль комедияләре зур йогынты ясый. Ул Хаҗибәков белән 1921 елда Бакудагы гастрольләре вакытында танышкан була. Тикшеренүче Л. Атанова җырчының концертларда азәрбайҗан артистлары белән уртак чыгышлары турында искә ала [Атанова, с. 11]. Солтан Габәши үзенең «Татар сәхнәсендә музыка» дигән мәкаләсендә Кавказда опера постановкаларында катнашуы турында яза [Габаши, с. 107].

Ташкентка әйләнеп кайткач, Газиз Әлмөхәммәдов фикердәшләрен таба, либретто яза, аның өчен халык көйләрен сайлап ала һәм «Сания» спектаклен сәхнәгә куярга әзерли. Аның премьерасы 1922 елда була. Тамашаны халык җылы каршылый, әмма чын операга җитәргә аңа әле, әлбәттә, ерак була. Ул вакытта Ташкентта яшәгән татар мәдәнияте әһелләре авторга, ярдәм сорап, Солтан Габәшигә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәләр. 1922 елның көзендә Газиз Әлмөхәммәдов композитор белән очрашу өчен Казанга китә.

Солтан Габәши бу эшнең уңышлы чыгуына бик тә шикләнеп карый. Газиз Әлмөхәммәдовка аны бу зур эшкә алынырга күндерү өчен бер ел буе үгетләргә туры килә. Үҗәтлеге аркасында барыбер җиңеп чыга. Көйләрне гармонияләштерүдә һәм оркестровкаларын эшләүдә рус композиторы В. Виноградовның ярдәме зур була. Ике елдан соң инде беренче татар операсы «Сания» бөтен төрки дөньяда яңгырый, анда Г. Әлмөхәммәдов зур партияләрнең берсен башкара.

Әлеге авторлар коллективы шулай ук киң иҗтимагый резонанс алган икенче милли операны – «Эшче»не дә яза. Премьерасы 1930 елның 22 һәм 27 февральләрендә Татар дәүләт театры сәхнәсендә була. Шул ук елны опера Мәскәүдә СССР халыклары театрлары һәм сәнгатьләре бөтенсоюз олимпиадасында күрсәтелә. Операның уңыш казануында эшче Нигъмәт ролен башкарган Газиз Әлмөхәммәдовның да тырышлыгы зур була.

Газиз Әлмөхәммәдов бик күп концертлар куя, пластинкалар да яздырырга өлгерә, туган ягына – Башкортстанга кайта, анда аны шатланып каршы алалар. 1929 елда Башкорт республикасы хөкүмә-

те Газиз Әлмөхәммәдовка халык артисты дигән мактаулы исем бирә. Тиздән аңа Уфадан Башкортстандагы «музыкаль төзелешкә» булышлык күрсәтергә рәсми чакыру килә, һәм 1931 елда Газиз Әлмөхәммәдов Казаннан китә.

Башкортстанда ул чыгышларын дәвам итә, республика районнары буйлап күп йөри, башкорт җырларын һәм көйләрен туплый, яздыра, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә. Уфа музыка училищесында милли сыйныфлар оештырыла. Газиз Әлмөхәммәдов фәнни һәм методик әдәбиятны, уку планнары һәм программалары төзүне кайгырта, ярдәм сорап, рус һәм татар композиторларына мөрәҗәгать итә. Ул композитор Солтан Габәшине Казаннан Уфага чакырту турында хөкүмәт карарын чыгартуга ирешә. Алар Башкортстанның ерак районнарына фольклор экспедицияләренә һәм озак сроклы командировкаларга бергәләп чыгалар.

1932 елда Газиз Әлмөхәммәдов Мәскәү консерваториясе каршында башкорт опера студиясен оештыруда актив катнаша. Ат арбаларында да, җәяүләп тә ул бөтен Башкортстанны йөреп чыга, әллә кайдагы авылларга барып җитә, сораштыра, талантлы башкорт яшьләрен тыңлый. Ул зур игътибар һәм җаваплылык белән студиягә 25 кеше сайлап ала. Алар Башкорт дәүләт опера һәм балет театры опера труппасының нигезен тәшкил итәләр, ә соңыннан данлыклы осталарга әйләнәләр. Алар арасында РСФСРның һәм БАССРның халык артисты, профессор Бану Вәлиева; БАССРның халык артисты һәм РСФСРның атказанган артисты Габдрахман Хәбибуллин; РСФСРның һәм БАССРның атказанган артисты Хәбир Галимов; БАССРның атказанган артисты Әсма Шәйморатова, БАССРның атказанган артисты, БАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Салих Хөснияров; шулай ук танылган композиторлар Заһир Исмәгыйлев, Хөсәен Әхмәтов, Рәүф Мортазин бар.

Әлмөхәммәдов булачак опера театры өчен алдан ук милли репертуар әзерли. Ул С. Габәшигә, А. Ключаревка яңа опералар язарга заказ бирә. Чимарозаның «Яшерен никах» һәм Паизиеллоның «Гүзәл тегермәнче хатын» дигән итальян опералары башкорт теленә тәрҗемә ителә.

1933 елда Газиз Әлмөхәммәдов «Башкорт музыка культурасы өчен көрәш» дигән китап чыгара, анда ул милли музыка үсешенә үз карашларын бәян итә. Бөтендөнья сәнгать мирасын үзләштерү зарурлыгын таныган хәлдә, ул һәрвакыт музыка сәнгатенең борынгы, традицион, милли чыганакларын барлап-кайгыртып яши.

1936 елда Газиз Әлмөхәммәдов концерт бригадасы оештыра, аның составында җырчы Диана Нурмөхәммәтова, биюче Заһидә Бәхтиярова, музыкант Исмәгыйль Илялов, пианистка Ковалевская була... Газиз Салих улының үз чыгышларын тамашачы аеруча җылы каршылый. Алар кич белән сәхнәгә әйләнгән йөк машинасында пианиноны да үзләре белән йөртәләр. Бу бригада, асылда, Башкорт филармониясенең прообразы була.

Ул арада илдә сәяси хәл торган саен катлаулана бара. Репрессияләр башлана. Матбугат битләрендә Газиз Әлмөхәммәдовны «буржуаз милләтче» һәм «кулаклар җырчысы» дип игълан иткән гаепләүләр күренә башлый. 1936 елда Газиз Әлмөхәммәдов үзенең иҗат юлы башланып киткән Ташкентта зур гастрольләр оештыра. Ә бер елдан соң, 1937 елның 12 декабрендә аны кулга алалар. 1938 елның 10 июлендә аңа үлем карары чыгарыла һәм ул шул ук көнне атып үтерелә.

Туган мәдәниятенә фидакярләрчә хезмәт иткән, үзеннән соң бай иҗади мирас калдырган Газиз Әлмөхәммәдов безнең күңелләрдә мәңге сакланырга тиеш, ә иҗаты, һичшиксез, җентекләп өйрәнүгә лаек.

**Әдәбият**

*Атанова Л.П.* Жизнь как песня: Творческий портрет Газиза Альмухаметова. Уфа, 1973.

*Бурхан С.* Газиз Альмухаметов // Яналиф. 1928. № 11.

*Габәши С.* Татар сәхнәсендә музыка // Татар театры (1906–1926). Казан, 1926.

*Идрисова М.А.* Газиз Альмухаметов и башкирская музыкальная культура // Газиз Альмухаметов. Статьи. Воспоминания. Документы. Уфа: Китап, 2008.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 82,09

***З.З. Рәмиев***

# КҮРЕНЕКЛЕ ӘДӘБИЯТЧЫ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ

***(Хәсән Хәйринең тууына 110 ел)***

Данная статья приурочена к 110-летию со дня рождения видного татарского литературоведа и критика, заслуженного деятеля науки ТАССР Хасана Хайри. В ней представлены краткое описание жизни и деятельности ученого, а также его научные достижения.

**Ключевые слова:** Хасан Хайри, ученый, литературовед, татарская литература, критика.

This article is dedicated to the 110th birthday of a prominent Tatar literary critic, Honored Worker of Science of the TASSR, Khassan Khairi. It provides a brief description of the scholar's life and work, as well as his scientific achievements.

**Keywords:** Khassan Khairi, scholar, literary critic, Tatar literature, criticism.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 80 еллык эшчәнлегендә, аның кайсы гына чорына күз салсак та, татар әдәбияты фәне проблемаларын тикшерүгә һәрдаим зур әһәмият бирелгәнлеге күренә. Татарстан АССР хөкүмәте карары белән 1939 елда оештырылган әлеге институт галимнәренең хезмәтләре йөзләрчә китап-монографияләрдә, меңләгән мәкаләләрдә, күпсанлы тематик җыентыкларда, фәнни конференцияләр материалларында урын алды. Соңгы 50–60 елда дөнья күргән китаплар арасында ике саллы басманы – Татарстан китап нәшриятында 1984–2001 елларда нәшер ителгән алты томлы (баш редакторы Н. Юзиев) һәм 2014 елда басыла башлаган сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы»н (җиде томы дөнья күрде; редколлегия башлыгы К. Миңнуллин) аерып күрсәтергә мөмкин. Бу фундаменталь хезмәтләр, табигый ки, әүвәлрәк эш алып барган берничә буын татар әдәбиятчы галимнәренең тикшеренүләренә таянып та, кайчак алар белән бәхәскә кереп тә язылган (чын фәнни хезмәт шулай тудырылырга тиеш тә). Шулар арасында Институтта озак еллар эшләп бакый дөньяга күчкән, әмма хәзер дә игътибарга алырлык китап-монографияләр, җитди мәкаләләр авторлары – Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев, Гали Халит, Мөхәммәт Гайнуллин кебек беренче буын әдәбиятчыларны күрәбез. Күренекле әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри дә – алар рәтендә. Хәсән Хәйри (Хәсән Фәхретдин улы Хәйруллин) хәзерге Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 1942 елда әдәбият бүлеге мөдире буларак эшли башлый һәм биредә утыз елдан артык хезмәт куя. Быел аның тууына 110 ел була.


Хәсән Хәйри

Хәсән Хәйри тумышы белән Татарстан Республикасыннан шактый еракта урнашкан төбәктән. Ул хәзерге Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең Чапаев поселогында (элек Лбищенск исемле өяз үзәге) 1910 елның 5 февралендә туа (әтисе башта батрак, бераздан – приказчик). Гражданнар сугышы чорында, дөресрәге, 1918 елда – әнисе, 1919 елда әтисе кинәттән вафат булулары сәбәпле, тома ятим калган Хәсән 1924 елгача Җаек (Уральск) шәһәрендәге балалар йортында тәрбияләнә. Башлангыч белем алгач, 1925–1927 елларда ул авыл хуҗалыгы техникумының әзерлек курсларында укып йөри, аннан Омск шәһәренә барып чыга һәм рабфакка керә. Шул вакытларда аның хезмәт биографиясе башлана да. Ул Новониколаевск шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән «Азат Себер» газетасында җаваплы секретарь, Новокузнецк шәһәрендәге «История Кузнецкстроя» редакциясендә оештыручы секретарь, «За большевистскую сталь» газетасында әдәби секретарь булып эшли – журналистикада беренче адымнарын ясый. Бу елларда ул Себер җирендә башланып киткән зур төзелешләрдә туган хезмәт пафосын шигырь телендә, хикәяләрдә, очеркларда чагылдырырга омтылыш ясый. 1934 елда шуларны эченә алган ике китабы басылып та чыга: «Тавышлы таң» – Казанда (Татгосиздатта), «Зур Кузбасс өчен» – Новосибирскида (хәер, монысы 1932 елда ук нәшриятка тапшырылган була).

Х. Хәйри 1934 елда Казанга күченеп килә, 1939 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлегенә ия була, «Совет мәктәбе» журналының җаваплы секретаре (1936–1939), Татарстан китап нәшриятында редактор (1939–1942) хезмәтен башкара. 1936 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгән Х. Хәйринең татар әдәбияты классиклары һәм замандаш әдипләр турындагы мәкаләләре, бәяләмә-рецензияләре газета-журнал битләрендә еш басыла башлый. Ул әдәби мирас китапларына, мәсәлән, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Т. Шевченко әсәрләре җыентыкларына кереш сүзләр дә яза. Г. Тукай турында сүз алып, аның татар балалар әдәбияты үсешенә керткән өлеше хакында да үз фикерен әйтә. Шунысы мөһим, татар мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы өчен төзегән «Әдәбият» дәреслегендә Тукай иҗаты турында ул язган бүлекләр зур урын били, «Әдәбияттан хрестоматия»сендә Тукайның 13 әсәре тексты китерелә. Әлеге дәреслекләр озак вакытлар – 1970 еллар ахырына кадәр мәктәпләрдә кулланылышта булды.

Хәрби хезмәткә яраксыз дип табылганлыктан, Х. Хәйри Ватан сугышы елларында фронтка җибәрелми, тылдагы эшләрне башкара:

сугышның беренче елында Татарстандагы хәрби-оборона төзелешләрендә катнашучы 500 кешелек Бауман районы колоннасын җитәкли, Татарстанга күчеп килгән Мәскәү язучыларына яшәү шартлары булдыру эшенә актив катнаша (А. Фадеев, А. Толстой, Анна Зегерслар белән аралаша), 1943 елда фронтка командировкага барып, татарча чыга торган «Совет сугышчысы» газетасы редакциясендә эшли [Салехова, с. 207] һ.б.

1941 елда партия сафларына да кабул ителгән Х. Хәйри, 1942 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы мөдире итеп билгеләнсә дә, бу юлы әле аңа анда озак эшләргә туры килми, тиздән партиянең Татарстан өлкә комитетына (пропаганда һәм агитация бүлегенә) инструктор итеп алына (бу вазифаны 1947 елга кадәр үти).

1950 елда Х. Хәйри, партиянең Татарстан өлкә комитеты юлламасы белән Мәскәүгә барып, ВКП(б) Үзәк Комитеты каршында яңарак кына ачылган Иҗтимагый фәннәр академиясенең аспирантурасына укырга керә һәм аны 1953 елда «Татар әдәбиятында социалистик реализм үсеше өчен көрәш» исемле темага язылган кандидатлык диссертациясе яклап тәмамлый. Билгеле ки, бу хезмәттә татар әдәбиятының совет чорындагы яшәеше картинасын бөтен катлаулыгында нечкәләп тикшерү мөмкин булмый, аерым алганда, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Х. Туфан һ.б. репрессияләнгән әдипләрнең әдәби процесстагы хакыйкый урыннары күрсәтергә ярамый.

Хәсән Хәйри гомеренең иң нәтиҗәле фәнни иҗат еллары Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында уза. Казанга әйләнеп кайткач, 1953 елның 21 сентябрендә аңа Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры вазифасы йөкләнә. Сталинның шәхес культы белән яшәгән ил тормышында яңарыш заманы башланган чор. Халык, ниһаять, иркенрәк сулу ала. Моңа кадәр берничә мәртәбә идеологик ялгышларда фаш ителгән Институт хезмәткәрләре дә фәнни эзләнүләрендә кыюрак була башлый.

Репрессия корбаннары аклана башлау әдәби мирасны тулырак күзалларга мөмкинлек тудыра. 1950 еллар ахырында басылган «Татар совет әдәбияты тарихы» исемле 820 битле хезмәт үзе генә ни тора! Бу елларда классикларның Институт галимнәре катнашында әзерләнгән тулырак басмалары укучылар кулына барып ирешә. Менә шушы заманнарда Институтны җитәкләгән Х. Хәйри үзе дә елларның беркадәр «җылынуын» тойгандыр.

1959 елдан Х. Хәйри институтның әдәбият секторы өлкән фәнни хезмәткәре, 1966–1973 елларда исә әлеге бүлекнең мөдире вазифасын башкара. Әйтергә кирәк, Институт төзелүнең беренче елларында ук мең еллык данлы үткәне булган татар әдәбияты тарихын язу мәсьәләсе алга килеп баскан булса да, озак вакыт бу эшкә тотынылмый тора. Нәкъ менә Х. Хәйри әдәбиятчыларны җитәкләгән вакытта бу фундаменталь эшкә ныклап керешәләр. Шәхсән үзем, 1967 елда аспирантурага кабул ителеп, Хәсән Хәйри җитәкчелегендә диссертация яза башлаган вакытларда әдәбиятчыларның бер төркеме фактик

материалны, чыганакларны барлау, аларны җентекләп өйрәнү белән мәшгуль иде. Шушы чорда XX гасыр башы татар вакытлы матбугатын (36 исемдәге татар журналын, 60 исемдәге татар газетасын) карап чыгып, андагы әдәби материалның аннотацияле библиографиясе (кулъязма картотекада 30 меңләп карточкада) төзелде [ТӘһСИнең ЯһММҮ...]. Х. Хәйри булачак күптомлы «Татар әдәбияты тарихы»-ның структурасы, концепциясе турында гомуми фикер туплап, аны яза башлаганчы, бу фундаменталь хезмәтнең план-проспектын булдырырга кирәклеген аңлап, коллективны шушы эшкә юнәлдерде. Бу, чын мәгънәсендә, дөрес эш булды. Хәсән ага шактый күләмле булып оешкан бу проспектны, кулъязма хокукында гына булса да, бастырып тарату җаен тапты. 1972–1973 елларда бу проспектны тикшерү СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы конференц-залында киң әдәби-фәнни җәмәгатьчелек, шул исәптән, башкорт әдәбиятчылары катнашында (Уфадан Әхнәф Харисов, Вафа Әхмәдиев һ.б.) уздырылды. Җанлы фикер алышу нәтиҗәле һәм файдалы булды. Бераздан, 1973 елда Хәсән Хәйри сәламәтлеге какшау сәбәпле мөдирлектән китеп барса да, алты томлы татар әдәбияты тарихы (баш редакторы Нил Юзиев) буенча эш уңышлы гына дәвам итттерелде.

Күренекле әдәбиятчы галим һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри үз гомерендә уннан артык китап, тематик җыентыкларда, журналларда, газеталарда йөзләрчә мәкалә, замандаш әдипләре турында тәнкыйди язмалар бастыра (аларның тулы булмаган исемлеге галимнең шәхси архивында саклана). Болар, билгеле ки, төрле иҗтимагый-сәяси шартларда – Сталин диктатурасы чорында, «җепшеклек» дип аталган елларда, башкалары Брежнев вакытларында – торгынлык чорында басылып чыга («Эзләнүләр», 1941; «Һади Такташ», 1949; 1984; «Современная татарская литература», 1957; «Язучы һәм тормыш», 1979 һ.б.) Билгеле ки, бу китап-монографияләрдә, мәкаләләрдә XX гасырның 40–70 нче елларында катгый алга сөрелгән социалистик реализм өйрәтмәләре чагылыш таба. Әмма шунысы да мөһим: коры схематик фикерләүгә генә корылмыйча, аларда сыйнфый караш янәшәсендә әдәби әсәрләрнең эчке матурлыгын күрү, этик-эстетик кыйммәтен анализлау, тормыш реалийларын чагылдырудагы, образларны тудырудагы уңышлы һәм уңышсыз якларны күрү дә бар. Мине бигрәк тә Хәсән Хәйринең Тукай турындагы мәкаләләре кызыксындырды. Аларның саны – 7. Ул, беренчеләрдән булып, 1939 елда ук Тукайның татар балалар әдәбияты тудырудагы роле турында язып чыкты, гомумән, бу мирасны җентекләп, инәсеннән җебенә кадәр өйрәнергә чакырды. Галимнең «Әдәби мирас – халык хәзинәсе» дигән мәкаләсендә [Хәйри, 1975], мәсәлән, Институт текстологларын бүген дә нык уйланырга мәҗбүр итә торган фәнни проблемалар бик дөрес күрсәтелгән: эшне планлы алып бару, академик басмалар төзү зарурияте, тулылык, текстларны бозмыйча эшкәртү, архивларны туплау һ.б.

Хәсән Хәйринең үзе белән якыннан аралаша башлаганчы, ул язган яисә аның катнашында әзерләнгән китаплар белән «эш итәргә»

туры килде. Аның урта мәктәпнең югары сыйныф укучылары өчен татар әдәбияты дәреслекләре һәм хрестоматияләре безнең куллар-да булды, алар аша серле әдәбият дөньясын аңларга өйрәндек. Мин 1967 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, шул елның октябрендә Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы аспиранты булдым. Фәнни җитәкчем булып бүлек мөдире Хәсән Хәйри расланды. 1973 елда диссертацияне яклауга чыгаруда аның да өлеше зур дип саныйм мин. Бүген дә фәнни җитәкчем, галим Хәсән Хәйрине һәм аннан соң сектор (алга таба бүлек) мөдире булып эшләгән Нил Юзиев, шулай ук Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халитләрне сагынып искә алам. Алар белән аралашкан еллар онытылмый, якты хатирәләр булып яши.

Хәсән Хәйри 1994 елда вафат булды.

### Әдәбият

*Салехова Л.Л.* Жизнь и творчество татарского литературоведа Хасана Хайри // Творческое наследие просветителей тюркского мира: материалы научно-практической конференции, посв. 190-летию ... К. Насыйри и 170-летию Абая Кунанбаева... Казань: Отечество, 2015. С. 207.

ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 129, тасв. 1, сакл. бер. 169.

*Хәйри Х.* Әдәби мирас – халык хәзинәсе // Хәйри Х. Иҗат чишмәләре: тәнкыйть мәкаләләре, әдәби очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 246 б.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2020 елның 1–8 августында** Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында II «TAMGA» режиссерлар лабораториясе эшләде. Агымдагы елда татар халык һәм автор әкиятләре әлеге лабораториянең төп темасы буларак билгеләнде.

Берничә көн дәвамында Россиянең төрле төбәкләреннән чакырылган яшь режиссерлар актерлар белән берлектә театр эскизлары әзерләделәр. Тамашачылар, тәнкыйтьчеләр һәм журналистлар игътибарына Казаннан Регина Саттарова «Кисекбаш» (Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәре нигезендә), Томскидан Павел Зобнин (татар халык әкияте «Падишаһ һәм Алтынчәч»), Мәскәүдән Марфа Горвиц (татар халык әкияте «Камыр батыр»), шулай ук Г. Кариев театры режиссеры Эльдар Гатауллин («Бүре башлы кыз») тарафыннан сәхнә эскизлары тәкъдим ителде.

Иң яхшы эскизларны киләчәктә театрлар репертуарына кертү күздә тотыла.

**2020 елның 14 августында** Алабуга шәһәренең «Адымнар-Алабуга» яңа полилингваль комплексында Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсе узды. Киңәшмә «XXI гасыр мәгарифе: киләчәк өчен бүгенгесе» темасына багышланган иде. Утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия Федерациясе мәгариф министры урынбасары Виктор Басюк, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль районнар башлыклары, мәгариф белән идарә итү муниципаль органнары җитәкчеләре, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре ректорлары, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре, мәктәп директорлары катнашты.

Киңәшмә барышында «Мәгариф» милли проектын гамәлгә ашыруга йомгак ясалды, мәктәпкәчә һәм гомуми урта белемнең сыйфатын күтәрү, һөнәри белем бирү, өстәмә белем һәм тәрбия өлкәләренә кагылышлы актуаль мәсьәләләр каралды, 2020/2021 уку елына бурычлар билгеләнде.

**2020 елның 21–22 августында** Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан «Тәрҗемәчеләр ассоциациясе бизнес-бюросы» чарасының даими оештыручы белән берлектә «Translation Forum Russia» XI Халыкара тәрҗемәчелек конференциясе үткәрелде.

Чара тәрҗемәчелек индустриясен үстерүче һәм бу юнәлештә белем бирүче чит ил һәм Россия оешмалары вәкилләре катнашында онлайн-форматта узды. Конференция программасында, спикерларның чыгышларыннан тыш, дискуссияләр, воркшоплар, мастер-класслар, панель дискуссияләр, түгәрәк өстәлләр дә урын алды. Дәүләт структуралары, тәрҗемәчелек бюролары һәм тәрҗемә бүлекләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, укытучылар тәрҗемәчелек тармагында яңа технологияләр, тәрҗемә итү процесслары белән идарә итү системалары

эше, төрле тармакларда эшләү үзенчәлекләре, шулай ук милли телдән тәрҗемә итүдәге кыенлыклар турында фикер алыштылар. Чарада милли телләрне үстерү, татар халкының милли үзенчәлеген татар теле аша саклау, чит илләрдәге бизнес һәм хакимият вәкилләре белән элемтәләр урнаштыру мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.

**2019 елның 24–30 августында** Казанда Татарстан киносы көннәре үткәрелде. Ул ТАССРның 100 еллыгына багышланды һәм XVI Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең «Милли конкурс» номинациясенә кергән фильмнарны үз эченә алган иде.

Татарстан киносы көннәрендә тамашачы игътибарына Салават Юзеевның «История одной фотографии», Рәшит Маликов һәм Рамил Фазлыевның «Сөмбел» фильмнары, Ренат Хәбибуллинның «Фанис Зиганшин. Разговор за сценой», Солтан Сөнгатуллинның «Танцуй в Углу» һәм башка фильмнар тәкъдим ителде. Фестиваль башкорт режиссеры Айнур Аскаровның Мостай Кәрим әсәре буенча төшерелгән «Отряд Таганок» фильмы белән тәмамланды.

**2020 елның 28–30 августында** Казанда Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында «Милләт Җыены» үткәрелде. Бөтендөнья татар конгрессы оештырган чарада Татарстан Республикасыннан, шулай ук Россия Федерациясенең 68 төбәгеннән 500 ләп вәкил катнашты, якын һәм ерак чит илләрдән вәкилләр видеоконференция режимында кушылды.

М. Җәлил исемендәге Казан опера һәм балет театрында узган пленар утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Милли шура советы рәисе Васил Шәйхразиев катнашты.

Утырыш барышында татар телен һәм милли гореф-гадәтләрне саклау юллары, яшьләрдә милли-мәдәни кыйммәтләр формалаштыру мәсьәләләре каралды, «Татар халкының үсеш стратегиясе» кабул ителде.

**2020 елның 29 августында** «Алтын хәситә» халыкара конкурсының финалы узды. Әлеге конкурс төрле халыкларның милли мәдәниятенә кызыксыну формалаштыру максатыннан үткәрелә һәм милли стильдә заманча кием дизайнерларының соңгы эшләнмәләрен күрсәтү өчен халыкара мәйданчык булып тора.

Конкурста Россия, Германия, Казакъстан, Нидерланд һәм Үзбәкстаннан иҗат коллективлары, остаханәләр, үзәкләр, һөнәрчелек йортлары һәм мода театрлары, шулай ук шәхси осталар, рәссам-модельерлар, урта һәм югары уку йортлары укучылары һәм педагоглары катнашты. Алар алты номинация буенча көч сынашты: «Реконструкцияләнгән тарихи милли костюм», «Сәхнә милли костюмы», «Заманча авторлык костюмы», «Балалар милли костюмы», «Баш

киеме һәм аксессуарлар», «Милли киемле курчак».

Конкурсны оештыручылар – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Традицион мәдәниятне үстерү республика үзәге.

**2020 елның 30 августында** ТАССР төзелүгә 100 ел тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Милли музеенда «Татарстан тарихы борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр» темасына яңа экспозиция ачылды.

Экспозициядә республика тормышының иң мөһим этаплары – республика төзелү тарихы, аның Бөек Ватан сугышында җиңүгә керткән өлеше, бүгенге көндәге казанышлары чагылыш тапкан. Биредә беренче тапкыр Чистай сәгать заводы, «Аромат», «Тасма» фабрикалары кебек зур предприятиеләр турында да материаллар тәкъдим ителде.

**2020 елның 30 августыннан 10 сентябренә кадәр** Татарстанда «100% Татарстан» онлайн-форумы узды. Гражданнар, бизнес, хакимият вәкилләрен һәм әйдәп баручы экспертларны берләштергән аралашу мәйданчыгы буларак, «100% Татарстан» форумының программасы 21 юнәлеш (IT-индустрия, мәгариф, медицина, авыл хуҗалыгы, туризм, циркуляр икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык, биотехнологияләр һ.б.) буенча 100 дән артык сессия эшен үз эченә алды. Аларда Татарстанның стратегик үсешенә бәйле төп темалар хакында фикер алышу оештырылды. Чара кысаларында панель дискуссияләр, онлайн-митаплар, фикер лидерлары һәм блогерларның эфирлары, экспертлар белән интервьюлар үткәрелде.

**2020 елның 1 сентябрендә** Казан шәһәрендә рус, татар һәм инглиз телләрен тирәнтен өйрәнүле «Адымнар – белемгә һәм татулыкка юл» беренче полилингваль белем бирү комплексы ачылды.

Белем бирү комплексы Казанның 165 нче мәктәбе базасында төзелгән. Ул 480 урынлы реконструкцияләнгән башлангыч мәктәпне, 800 урынлы билингваль мәктәпне һәм 1224 урынлы яңа полилингваль мәктәпне үз эченә ала. Моннан тыш, комплекс составына балалар бакчалары һәм ел әйләнәсендә өстәмә белем бирү үзәге керәчәк, шулай ук читтән килеп белем алучы укучылар өчен интернат эшләячәк.

«Адымнар — белемгә һәм татулыкка юл» полилингваль белем бирү комплекслары челтәрен булдыру проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе М.Ш. Шәймиев инициативасы белән гамәлгә ашырыла. Проектның максаты – балаларга рус, татар, инглиз телләрендә белем бирү һәм аларны милләтара татулык рухында тәрбияләүгә юнәлдерелгән мәгариф комплексы моделен булдыру.

2024 елга республикада алты полилингваль белем бирү комплексы ачу планлаштырыла. Үзләренең составына, мәктәпләр белән беррәттән, балалар бакчалары һәм өстәмә белем бирү үзәкләрен дә алган комплекслар Казан һәм Алабуга, Яр Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендә эшләячәк.

**2020 елның 2–6 сентябрендә** Казанда Россиянең утыздан артык төбәгеннән килгән 200 ләп делегат

катнашында «Татар яшьләре көннәре» Халыкара яшьләр форумы үткәрелде. Әлеге чара Россиянең төрле төбәкләрендә, ерак һәм якын чит илләрдә яшәүче татар яшьләрен мәдәни-милли берләштерүгә, эшлекле һәм мәдәни элемтәләрне киңәйтүгә, яшьләр сәясәте, фән, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә мәгълүмат алмашуга, төбәкләрдә татар яшьләре оешмалары алдында торган проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән.

Форум программасына татар теле, тарихы, дине, мәдәнияте һәм сәнгате дәресләре, төрле семинар-тренинглар кертелгән иде. Моннан тыш, делегатларга түгәрәк өстәлләрдә аерым темалар буенча чыгыш ясау, тәҗрибә уртаклашу өчен мөмкинлекләр тудырылды.

**2020 елның 5 сентябрендә** Казанда, Милли костюм көненә багышлап, «Мәдәниятләр мозаикасы» VI Республика этноконфессиональ фестивале узды. Фестивальнең оештыручылары – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан халыклары Ассамблеясе һәм Халыклар дуслыгы йорты, Татарстан халыклары яшьләр Ассамблеясы.

Казан шәһәренең Иске татар бистәсендә Идел буе төбәкләренең халык һөнәрләре һәм кәсепләре эшләнмәләре күргәзмәсе, «Этномаркет» ярминкәсе оештырылды, шулай ук милли ризыклар әзерләү буенча мастер-класслар, этно-стильдә модельерлардан дефиле, коуч сессия, дискуссияләр үткәрелде.

**2020 елның 25 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә ТАССР оешуга 100 ел тулу уңаеннан «Татарстан фәненең 100 еллык тарихы» темасына түгәрәк өстәл уздырылды. Чарада Татарстан Фәннәр академиясе, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге, Казан федераль университеты галимнәре, Татарстанның югары уку йортлары вәкилләре катнашты.

Түгәрәк өстәлдә Татарстан фәне формалашуда һәм аның үсешендә Казан университетының, Россия Фәннәр академиясенең роле, республикада гуманитар фәннәр, физика-математика, биология һәм фундаменталь медицина өлкәсендә фәнни мәктәпләр барлыкка килү, гамәли фәннең Татарстанда агросәнәгать өлкәсе үсешенә керткән өлеше һәм башка темаларга чыгышлар ясалды, фикер алышу оештырылды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2020. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 05.10.2020. Басылды: 19.10.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла